| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның 31 марты Балык Бистәсе штп. № 29

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында

2010 елның 27 июлендәге “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 210-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 880 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 21 июнендәге 96пи номерлы карарын исәпкә алып КАРАР БИРӘМ:

1. Раслау:

1.1. Яшел үсентеләр кисү хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1 нче кушымта);

1.2. Торак бинаны үзгәртеп коруга һәм (яки) яңадан планлаштыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта);

1.3. Муниципаль милектә булган гражданга социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (3 нче кушымта);

1.4. Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урыннарын алмаштыру буенча документларны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (№4 кушымта);

1.5. Торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган бинага күчерү (күчерүдән баш тарту) турында хәбәрнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (5 нче кушымта);

1.6. Адресларны бирү, үзгәртү, юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (6 нчы кушымта);

1.7. Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (№7 кушымта);

1.8. Элек хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (8 нче кушымта).

2. Көчен югалткан дип танырга:

2.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетының 23.01.2019 ел, № 1 карары белән расланган гражданга муниципаль милектәге торак урыны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты.

2.2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетының 23.01.2019 ел, № 1 карары белән расланган Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урыннары алмаштыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты.

2.3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетының 23.01.2019 ел, № 1 карары белән расланган элек хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты.

2.4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетының «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы 17.03.2021 ел, №17 карары.

2.5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең аерым административ регламентларын юкка чыгару һәм раслау турында»гы 28.05.2021 ел №34 карары.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе штп., Ленин урамы, 48а йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын вакытлыча башкаручы М.А. Старикова

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Балык Бистәсе шәһәр
җирлеге Башкарма комитетының
2022 елның 31 мартындагы 29
номерлы карарына
кушымта №1

**Яшел утыртмаларны кисү хокукына рөхсәтнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – административ регламент) яшел утыртмаларны кисү хокукына рөхсәтнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең (алга таба – муниципаль хезмәт) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт алуга хокукы булган затлар – физик һәм юридик затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

Гариза милекче, күчемсез мөлкәт объектыннан файдалану хокукына ия зат яисә күчемсез мөлкәт объекты милекчесе исеменнән вәкаләтле затлар тарафыннан төзелеш, реконструкция, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерү эшләрен һәм башка җир эшләрен уздыруга шартнамәләр төзүгә хокуклы зат тарафыннан бирелә (мөрәҗәгать итүче вәкиле).

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мәгълүмат бирү (хәбәр итү) тәртибе

1.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат урнаштырыла:

1) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре биналарында урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендларында;

2) муниципаль районның “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге https://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru/ рәсми сайтында;

3) Татарстан Республикасының https://uslugi.tatarstan.ru дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр Порталында (алга таба – Республика порталы);

4) http:// www.gosuslugi.ru Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләр) порталында (алга таба – Бердәм портал);

5) “Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры” дәүләт мәгълүмат системасында (http://frgu.tatar.ru) (алга таба – Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры).

1.3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча консультация (мәслихәт) бирү гамәлгә ашырыла:

1) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яисә телефон буенча;

2) Республика порталының интерактив рәвешендә;

3) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетында (алга таба – Орган):

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яисә телефон буенча;

язма рәвештә (шул исәптән электрон документлар рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә – кәгазь йөрткечтә почта аша, электрон рәвештә электрон почта аша.

1.3.3. Бердәм порталда, Республика порталында Республика реестрындагы мәгълүматлар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат гариза бирүчегә бушлай бирелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка мөрәҗәгать итүченең нинди дә булса таләпләр үтәмичә генә, шул исәптән, мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштыру гариза бирүчедән түләү алуны, теркәүне яисә авторизацияне күздә тотучы программа тәэмин ителешенең хокук иясе белән лицензияле яисә башка килешү төзүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча яисә аларга шәхси мәгълүматлар бирмичә керү мөмкинлеге гамәлгә ашырыла.

1.3.4. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яки телефон аша мөрәҗәгать иткән очракта, кергән мөрәҗәгать нигезендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, Органның урнашу урыны турында мәгълүмат бирелергә мөмкин (адрес, эш графигы, белешмә телефоннары); муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе, гаризалар бирү ысуллары һәм сроклары турында; муниципаль хезмәт күрсәтелә торган гражданнар категорияләре хакында; муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләрен җайга салучы норматив хокукый актлар турында; муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны карау өчен кирәкле документлар исемлеге, гаризаны кабул итү һәм теркәү сроклары, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы хакында; муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүматның рәсми сайтта урнаштырылу урыны турында; Органның вазыйфаи затларының (урындагы кешеләренең) гамәлләренә яки гамәл кылмауларына карата шикаять белдерү тәртибе хакында.

Язма мөрәҗәгать буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы бүлекнең вазыйфаи затлары мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен һәм регламентның әлеге пунктында күрсәтелгән мәсьәләләрне язма рәвештә аңлаталар һәм мөрәҗәгатьне теркәгәннән соң өч эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрәләр. Җаваплар мөрәҗәгать иткән телдә бирелә. Мөрәҗәгать иткән телдә җавап бирү мөмкин булмаган очракта Татарстан Республикасы дәүләт телләре кулланыла.

1.3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат муниципаль районның рәсми сайтында һәм Орган бүлмәләрендәге гариза бирүчеләр белән эшләү өчен куелган мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

“Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге муниципаль районның рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларында урнаштырылган Татарстан Республикасы Дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге Регламентның 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы үзидарәлек хезмәте турындагы мәгълүматларны, Органның урнашу урыны, белешмә телефоннары, эш вакыты, муниципаль хезмәт күрсәтүгә гаризалар кабул итү графигы турында мәгълүматны үз эченә ала.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актлар реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып

чыгару чыганакларын күрсәтеп) Бердәм порталда, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта, Республика реестрында урнаштырылган.

Гамәлдәге редакциядә административ регламент тексты Бердәм порталда, Республика реестрында, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштырылырга тиеш.

1.5. Регламентта түбәндәге атамалар (терминнар) һәм билгеләмәләр файдаланыла:

дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтү күпфункцияле үзәгенең ераклашкан эш урыны – 2012 елның 22 декабрендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтү күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләрен раслау турында” 1376 номерлы карары белән расланган дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтү күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районының шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында төзелгән дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтү күпфункцияле үзәгенең территория ягыннан аерымланган структура бүлекчәсе (офисы);

техник хата – үзидарәлек хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка кертелгән (үзидарәлек хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсенә) мәгълүматларга тәңгәл булмауга, алар нигезендә кертелгән мәгълүматларның документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китерүче ялгыш (ялгышлык белән җибәрелгән хәреф, сүз хатасы, грамматик яки арифметик хата яисә шуларга охшаш ялгышлыклар).

Электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик үзара хезмәттәшлеген (багланышын) тәэмин итүче инфраструктурада идентификацияләүнең (бердәйләштерүнең, тәңгәлләштерүнең) һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы (алга таба – ЕСИА (Единая система идентификации и аутентификации)) – дәүләт мәгълүмат системаларында һәм башка мәгълүмат системаларында булган мәгълүматны идентификацияләү һәм аутентификацияләү системасында мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучыларның санкцияләнгән файдалана алуын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы;

КФҮ – “Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге” дәүләт бюджет учреждениесе;

КФҮ нең АМС – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы.

Регламентта муниципаль (үзидарәлек) хезмәте күрсәтү турындагы гариза дигәндә (алга таба – гариза) үзидарәлек хезмәте күрсәтү турында “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 маддәсенең 3 пункты (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә бирелгән гарызнамә (рәсми таләп) аңлашыла.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

2.1. Муниципаль хезмәтнең аталышы

Яшел утыртмаларны кисү хокукына рөхсәтнамә бирү

2.2 Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарәнең башкарма-боеручы органының исеме (аталышы)
Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты

2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау

2.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып тора:

1) яшел утыртмаларны кисү хокукына рөхсәтнамә (кушымта № 1);

2) агачларның, куакларның һәлакәтлелеге турында бәяләмә белән яшел утыртмаларны тикшерү акты (кушымта № 2);

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар (кушымта № 3).

2.3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе “Электрон имза турында” 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә мөрәҗәгать итүчегә Бердәм порталның шәхси кабинетына Органның вәкаләтле вазыйфаи затының (урындагы кешесенең) (яисә Органның) көчәйтелгән квалификацияле электрон култамгасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

2.3.3. Мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе Органда яки КФҮтә кәгазьдә йөрткечтәге электрон документ нөсхәсе рәвешендә бирелә, ул тиңдәшле рәвештә Органның вәкаләтле вазыйфаи заты яисә КФҮ хезмәткәре имзасы һәм мөһер белән таныкланган була.

2.3.4. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәтне күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең гамәлдә булу срогы дәвамында алырга хокуклы.

2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы

2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты:

Яшел утыртмаларны кисүгә рөхсәтнамә алган вакытта 17 эш көненнән дә артмый.

Технологик тоташтыру (ялгау) өлешендә инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау, төзү, реконструкцияләү эшләрен башкарганда, әгәр мөрәҗәгать итүче тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле булган регламентның 2.5.3 пунктында, 2.6.1 пунктының 1 – 8 пунктчаларында күрсәтелгән документлар бирелгән очракта – өч эш көне, ә мөрәҗәгать итүче үз инициативасы буенча регламентның 2.6.1 пунктында каралган документларны тапшырмаган очракта – 8 эш көне.

Һәлакәт нәтиҗәсендәге торгызу эшләрен үткәрү зарурлыгы, яшел утыртмаларны кыру (җимерү) чиктән тыш кирәк булганда (агачның, авария хәлендәге агачларның аву куркынычын бетерү өчен) – өч эш көненнән дә артмаска тиеш.

Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты гаризаны теркәгәннән соң икенче көнне исәпләнә башлый.

2.4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

2.4.3. Электрон документ формасында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документ муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

### 2.5. Үзидарәлек хезмәте күрсәтү өчен законнар яки башка норматив хокукый актлар нигезендә гариза бирүче тапшырырга тиешле зарури документларның, шулай ук үзидарәлек хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрнең тулы исемлеге, аларны гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Мөрәҗәгать итүче, муниципаль хезмәт алу өчен мөрәҗәгать итү категориясенә һәм нигезенә карамастан, түбәндәге документларны тапшыра:

1) шәхесне таныклаучы документ (КФҮтә мөрәҗәгать иткәндә бирелә);

2) гариза:

- кәгазь йөрткечтәге документ рәвешендә КФҮтә мөрәҗәгать иткәндә (кушымта № 4);

- электрон рәвештә (тиешле мәгълүматларны гаризаның электрон рәвешенә кертү юлы белән тутырыла), ул Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә Регламентның 2.5.6 пункты таләпләре нигезендә имзалана.

3) мөрәҗәгать итүче вәкиле муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклаучы документ (физик затларның законлы вәкилләреннән гайре).

2.5.2. Яшел утыртмаларны кисү хокукына рөхсәтнамә алу өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тапшыра:

1) кырылырга тиешле яшел утыртмалар үсә торган җир кишәрлегенә милек, ия булу яки файдалану хокукын раслаучы документлар (җир кишәрлегенә хокук бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлгән очракта яки җир кишәрлеге муниципаль район яки шәһәр округы Башкарма комитеты карамагына тапшырылган очракта гына таләп ителми);

2) биналар, корылмалар, парковкалар төзегәндә (реконструкцияләгәндә) габаритларга эләгүче яшел утыртмаларны кисү, сак зонасында инженерлык коммуникацияләрен салганда, шул исәптән яңа төзелешне дә кертеп, проект документлары;

3) күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы беркетмәсе, анда күпфатирлы йорт милекчеләренең территорияне (яшел утыртмаларны кыру зарурлыгы күрсәтелеп) төзекләндерү буенча эшләрне башкаруга смета документациясе нигезендә ризалашуы яисә мондый эшләрне

башкаруга проект документлары (проект документларының аерым бүлекләре) нигезендә ризалашуы турында карар кабул ителгән;

4) торак яки торак булмаган бинада табигый яктылыкны бозу турында бәяләмә яисә күзәтчелек органнары күрсәтмәсе (торак һәм торак булмаган биналарда норматив яктылык режимын торгызу буенча эшләр башкарылган очракта);

5) территорияне төзекләндерү, яшелләндерү буенча чишелешне чагылдырып, территорияне төзекләндерү планын үз эченә алган күчерелә торган бинаны (әгәр үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру мондый бинаны торак яки торак булмаган бина буларак куллануны тәэмин итү өчен кирәк булган очракта) үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру проекты;

5) юл хәрәкәтен җайга салуның техник чараларының нормаль күренүен, транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәте иминлеген тәэмин итү кирәклеге турында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтле орган мәгълүматы яисә һава һәм тимер юл транспорты хәрәкәте иминлеге өлкәсендә вәкаләтле органның хәрәкәт иминлеген тәэмин итү өлешендә норматив документларны үтәү зарурлыгы турында мәгълүматы (юл хәрәкәтен җайга салуның техник чараларының нормаль күренүен, транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү мөмкин булмаган очракта яшел утыртмаларны кыру өчен).

2.5.3. Инженерлык-техник тәэминаты челтәрләрен ремонтлау, төзү, реконструкцияләгәндә, инженерлык челтәрләренә технологик тоташтыру (ялгау) өлешендә кисү хокукына рөхсәтнамә алу өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тапшыра:

1) закон таләпләре нигезендә төзелгән технологик тоташтыруны гамәлгә ашыру турында шартнамә;

2) линияле объектларны һәм аларның өлешләрен, капиталь төзелеш объектларын һәм аларның өлешләрен төзүгә, реконструкцияләүгә проект документлары;

3) яңадан санау ведомосте (5 нче кушымта);

4) кырылырга тиешле яшел утыртмаларны фотога төшерү материаллары.

Фотога төшерү ул башкарыла торган урындагы торак йортка, бинага бәйләп эшләнә, ә аларның урнашкан урыны технологик тоташтыру (ялгау) өлешендә инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау, төзү, реконструкцияләү эшләрен башкару урынына күрсәтә.

2.5.4. Авария-торгызу эшләрен уздыру өчен яшел утыртмаларны кисүгә рөхсәтнамә алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта яки һәлакәт нәтиҗәсендәге торгызу эшләрен үткәрү зарурлыгы, яшел утыртмаларны кыру (җимерү) чиктән тыш кирәк булганда (агачның, авария хәлендәге агачларның аву куркынычын бетерү өчен) мөрәҗәгать итүче түбәндәге документлар тапшыра:

1) инженер-техник тәэмин итү челтәреннән файдаланучы оешманың инженер-техник тәэмин итү челтәрләрендә һәлакәт, инцидент булуын раслый торган, җитәкче яисә вәкаләтле вазыйфаи зат кул куйган акты (инженер-техник тәэмин итү челтәрләрендә аварияләр, инцидентлар бетерелгән очракта);

2) кырылырга тиешле яшел утыртмаларны фотога төшерү материаллары. Фотога төшерү ул башкарыла торган урындагы торак йортка, бинага бәйләп эшләнә, ә аларның урнашкан урыны авария, инцидент урынына күрсәтә.

2.5.5. Гариза һәм теркәлеп бирелә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

1) КФҮ аша кәгазь йөрткечләрдә һәм Регламентның 2.5.6. пункты таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә;

2) Республика порталы аша электрон рәвештә.

2.5.6. Физик затлар һәм шәхси эшкуарлар гариза һәм кирәкле документларны республика порталы аша җибәргәндә гаризаны гади электрон имза белән имзалыйлар.

Гади электрон имза алу өчен гариза бирүчегә ЕСИА да теркәлү (аутентификацияләү) процедурасын узарга, шулай ук хисап язмасын расларга кирәк.

Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән юридик затлар һәм юридик затлар вәкилләре гариза һәм кирәкле документларны республика порталы аша җибәргәндә гаризаны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалыйлар.

2.5.1 пунктының 3 пунктчасында, 2.5.2 пунктында, 2.5.3 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән документларны Республика порталы аша тапшырганда мөрәҗәгать итүче “Электрон култамга турында” 06.04.2011 ел, №63-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә, мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затлар, шул исәптән нотариуслар тарафыннан көчәйтелгән квалифицияле электрон култамга белән имзаланган документларның электрон үрнәкләрен яисә электрон рәвештәге документларны тапшыра.

2.5.7. Мөрәҗәгать итүчедән таләп итү тыела:

1) муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшыру яисә гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыру яисә гамәлләр кылуны;

2) муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле һәм башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга мөрәҗәгать итү белән бәйле гамәлләрне, шул исәптән килештерүләрне гамәлгә ашыруны, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 9 маддәсенең 1 өлешендә күрсәтелгән исемлекләргә кертелгән мондый хезмәтләр (кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр) күрсәтү нәтиҗәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрне һәм документларны алудан гайре;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны башта кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәткәндә баш тартканда документларның һәм мәгълүматның булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүматны тапшыруны, түбәндәге очраклардан гайре:

а) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза башта бирелгәннән соң муниципаль хезмәт күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актлар таләпләренең үзгәрүе;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризада һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны баштагы кабул итүдән баш тартканнан соң мөрәҗәгать итүче биргән документларда яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдә элек бирелгән документлар комплектына кертелмәгән хаталар булу;

в) документларның гамәлдә булу вакыты чыгу яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән башта баш тартканнан соң яки муниципаль хезмәт күрсәтүдә мәгълүмат үзгәрү;

г) Органның вазыйфаи затының, КФҮ хезмәткәренең муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне баштагы кире какканда яисә муниципаль хезмәт күрсәткәндә хаталы яки хокукка каршы гамәл кылуының (гамәл кылмавының) документаль расланган факты (билгеләре) ачыклану, әлеге муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу очрагында Орган җитәкчесе имзасы белән язма рәвештә мөрәҗәгать итүчегә хәбәрнамә ирештерелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә;

4) электрон рәвешләре 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсендәге 1 өлешенең 7.2 пункты нигезендә элек расланган документларны һәм мәгълүматны кәгазь йөрткечтә тапшыру, мондый документларга тамга салу яисә аларны алу дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан гайре.

2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә зарур булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хаклы документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма.

2.6.1. Ведомствоара хезмәттәшлек (бagланышлар) кысаларында алына:

1) юридик зат мөрәҗәгать иткән очракта Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан Федераль салым хезмәтеннән мәгълүматлар соратып алына;

2) индивидуаль эшкуар мөрәҗәгать иткән очракта, Федераль салым хезмәтеннән Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар соратып алына;

3) күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар (күчемсез мөлкәт объектының төп сыйфатламалары һәм теркәлгән хокуклары турында мәгълүматлар) - Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте (Росреестр);

4) күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрында теркәлергә тиеш булмаган муниципаль мөлкәтне, дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү турында шартнамә турында мәгълүматлар – Орган;

5) дәүләт яки муниципаль милек җирләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә генә урнаштырырга мөмкин булган объектларны урнаштыруга рөхсәтнамә – Орган;

6) төзелешкә рөхсәтнамә (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы белән билгеләнгән очракларда)– Орган;

7) җир эшләрен башкару хокукына ордер – Орган;

8) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу турында мәгълүматлар – Федераль салым хезмәте;

9) җирле бюджет акчалары исәбеннән территорияне төзекләндерү эшләрен башкаруга муниципаль контракт яисә ишегалды территориясен төзекләндерү эшләрен башкаруга субсидияләр бирү турында килешү – торглар үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру өчен “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе рәсми сайты (http://torgi.gov.ru);

10) юл хәрәкәтен җайга салуның техник чараларын урнаштыруга һәм (яисә) эксплуатацияләүгә вәкаләтле оешма белән шартнамә (дәүләт яисә муниципаль контракт) (юл хәрәкәтен җайга салуның техник чараларын урнаштырганда һәм (яисә) эксплуатацияләгәндә) (мондый эшчәнлекне әлеге учреждениенең уставы нигезендә гамәлгә ашыручы учреждениегә гариза бирү очракларыннан тыш) – торглар үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру өчен “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе рәсми сайты (http://torgi.gov.ru);

11) җирле үзидарә органының торак урынны торак булмаган урынга яисә торак булмаганны торак булганга күчерү турындагы карары (торак урынны торак булмаган урынга яисә торак булмаганны торак булганга күчерү нәтиҗәсендә урынга (бүлмә яки бинага) адрес бирелгән очракта) – Орган;

12) гариза законлы вәкил тарафыннан бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле вәкаләтләрен раслый торган документ (Россия Федерациясе гражданлык хәле актларын теркәү органнары тарафыннан бирелгән туу турында таныклык яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә опека һәм попечительлек органнары тарафыннан бирелгән документ өлешендә) – гражданлык хәле актларын теркәүнең бердәм дәүләт реестры яки социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы;

13) ышанычнамәне бирү һәм эчтәлеге турында мәгълүматлар – нотариатның бердәм мәгълүмат системасы.

2.6.2. Мөрәҗәгать итүче Регламентның 2.6.1 пунктының 1-12 пунктчаларында күрсәтелгән документларны (мәгълүматларны) мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затларның көчәйтелгән квалификацияле култамгасы белән таныкланган электрон документлар рәвешендә гаризаны Республика порталы аша биргәндә яисә КФҮ тә кәгазь йөрткечтә тапшырырга хокуклы.

2.6.3. Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар тарафыннан документлар һәм мәгълүматларны тапшырмау (вакытында тапшырмау) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.6.4. Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән органнарның соралган һәм карамагында булган документларны яисә мәгълүматларны тапшырмаган

(үзвакытында тапшырмаган) вазыйфаи заты һәм (яисә) хезмәткәре Россия Федерациясе законнары нигезендә административ, дисциплинар яисә башка җаваплылыкка тартылырга тиеш.

2.6.5. Гариза бирүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар карамагындагы документларны һәм мәгълүматларны, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәткән өчен гариза бирүче тарафыннан түләү кертүне раслый торган мәгълүматларны таләп итү тыела.

Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалар карамагында булган мәгълүматларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырмау мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

## 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту (асылы буенча карамыйча документларны кире кайтару) өчен нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

1) регламентның 2.5.1 – 2.5.4 пунктлары нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөстәкыйль тапшырылырга тиеш булган документларны тапшырмау яисә каршылыклы мәгълүматлары булган документларны тапшыру;

2) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратылган законлы вәкилләр турында мәгълүматларның расланмавы, вәкаләтле булмаган зат исеменнән гариза (гарызнамә) бирелү;

3) документларны тиешле булмаган органга тапшыру;

4) дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы мәгълүматлар, килешенмәгән төзәтүләр, җитди зарарланулар булган документларны бирү, алар эчтәлекне бертөрле генә аңлатырга мөмкинлек бирми, үз көчләрен югалткан документлар тапшыру;

5) регламент нигезендә муниципаль хезмәт алучы булмаган затның муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүе;

6) гаризаның электрон формасында мәҗбүри кырларны дөрес тутырмау, гаризаның электрон формасында һәм тапшырылган документларда каршылыклы мәгълүматлар булу;

7) гариза (гарызнамә) һәм электрон рәвештәге башка документлар гамәлдәге законнарны бозып электрон култамга белән имзаланган;

8) электрон документлар аларны бирү форматларына куелган таләпләргә туры килми һәм (яисә) укылмый.

2.7.2. Муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге төгәл булып тора.

2.7.3. Гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү вакытында да, органның җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны (мәгълүматларны)

ведомствоара мәгълүмати багланышны файдаланып алганнан соң да, гаризаны теркәгәннән соң 7 эш көненнән дә артмаган срокта кабул ителергә мөмкин.

2.7.4. Муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, Регламентка 3 нче кушымтада билгеләнгән форма нигезендә рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә Органның вәкаләтле вазыйфаи заты (Орган) тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон култамга белән имзалана һәм гариза бирүчегә республика порталының шәхси кабинетына һәм (яки) КФҮ кә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне җибәрелә.

2.7.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда, Республика порталында бастырылган муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

## 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр күздә тотылмый.

2.8.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге:

1) кыру турындагы гаризада күрсәтелгән яшел утыртмаларның бирелгән җир кишәрлеге чикләреннән тышта үсеп китүе (инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренең сак зоналары чикләреннән тыш);

2) яшел утыртмалар санының һәм (яисә) төренең кырылырга һәм (яисә) күчереп утыртылырга тиешле яшел утыртмаларны тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган факттагы кыруның, яшел утыртмаларны күчереп утыртуның, эшләр эчтәлегенә карап, капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны, капиталь ремонтлауны гамәлгә ашыру өчен проект документларының аерым бүлекләрендә, проект документларында күрсәтелгән яшел утыртмаларның санына һәм (яисә) төренә туры килмәве яисә гаризада күрсәтелгән яшел утыртмаларны (авария хәлендәге агачларны) кыру кирәклегенең тикшерү нәтиҗәсендә расланмавы;

3) гаризада күрсәтелгән ысул белән яшел утыртмаларны тикшерү өчен мондый тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында хәбәр ителгән мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) килмәве һәм (яки) яшел утыртмаларны тикшерү актын имзалаудан баш тартуы;

4) яшел утыртмаларның компенсация бәясен түләү буенча бурычлар булу яки түләмәү;

5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар (авария-торгызу эшләрен уздыру белән бәйле яисә яшел утыртмаларны кыру өчен бик кирәк булган очраклардан тыш (агач, авария хәлендәге агачларның аву куркынычын бетерү өчен);

6) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны мөрәҗәгать итүче инициативасы белән кире алу.

2.8.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге төгәл булып тора.

2.8.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турындагы карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, Регламентка 3 нче кушымтада билгеләнгән форма нигезендә рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә Органның вәкаләтле вазыйфаи заты (Орган) тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон култамга белән имзалана һәм мөрәҗәгать итүчегә Республика порталының шәхси кабинетына һәм (яисә) КФҮ кә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне җибәрелә.

2.8.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза Бердәм порталда, Республика порталында игълан ителгән (бастырылган) муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.9. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алынучы дәүләт пошлинасы һәм бүтән түләүнең тәртибе, күләме һәм түләтү нигезе

Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында мәгълүматлар

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтүгә түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамә биргәндә, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәт күрсәтелгәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты

2.12.1. Муниципаль хезмәт алуга гариза биргәндә көтү вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.12.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең гарызнамәсен һәм хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтне теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон рәвештә

2.13.1. Гариза биргән көнне КФҮкә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүчегә гаризаның җибәрелүен раслаучы теркәлү номеры һәм электрон гаризаны бирү датасы белән КФҮ АМС ннан раслама бирелә.

2.13.2. Гаризаны Республика порталы ярдәмендә юллаганда мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Республика порталының шәхси кабинетында һәм электрон почта аша, гаризаның теркәлү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелеп, гаризаның җибәрелүен раслый торган хәбәрнамә ала.

2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, көтү залына, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамәләрне тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре һәм һәр муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге булган мәгълүмат стендларына карата, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыру һәм бизәүгә, шул исәптән әлеге объектларга инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвалидлар өчен үтү (керү) мөмкинлеген тәэмин итүгә таләпләр

2.14.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебельләр, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына каршылыксыз керүе (үтә алуы) тәэмин ителә (бина-бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм алар эчендә күчену, хәрәкәт итү).

Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

2.14.2. Инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү (үтү) максатларында түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләренең ныклы тайпылышлары булган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

2) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм алардан чыгу, транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

3) инвалидларның хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөрткечләрне аларның тереклек эшчәнлегенең чикләнгәнлеген исәпкә алып тиешенчә урнаштыру;

4) инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук өсьязуларны, билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайль рельеф-нокталы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау;

5) сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчегә рөхсәт итү;

6) озатучы-этне махсус укыту-өйрәтүне раслаучы һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының “Озатучы-этне махсус укытуны раслый торган документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында” 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән билгеләнгән рәвештә һәм тәртиптә бирелгән документы булганда рөхсәт итү.

2.14.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектлардан һәм муниципаль хезмәт күрсәткәндә кулланыла торган Регламентның 2.14.2 пунктының 1 – 4 пунктчаларында күрсәтелгән чаралардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр, алар 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизацияләнгән объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

2.15. Муниципаль хезмәтнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән муниципаль хезмәт күрсәткәндә үзара багланышлары саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләрен кулланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы күләмдә), җирле үзидарәнең башкарма-боеру органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә муниципаль хезмәт алу мөмкинлеге яисә мөмкин түгеллеге, мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча (экстерриториаль принцип), 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 маддәсендә каралган күпфункцияле үзәкләрдә берничә дәүләт һәм (яисә) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамә (комплекслы гарызнамә) ярдәмендә

2.15.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкинлеге (доступность) күрсәткечләре булып тора:

документлар кабул итү, бирү алып барыла торган бинаның җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итүне гамәлгә ашыра торган бүлмәләрнең кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, муниципаль районның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында муниципаль хезмәтне күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

инвалидларга башкалар белән бер үк дәрәҗәдә хезмәтләр алырга комачаулаучы киртәләрне җиңәргә ярдәм итү.

2.15.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләр:

1) документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;

2) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу срогын үтәү;

3) орган хезмәткәрләре тарафыннан Регламентны бозуга карата нигезле шикаятьләр булмау;

4) мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән багланышлары саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең КФҮ хезмәткәрләре белән багланышы барлык кирәкле документлар белән гариза биргәндә бер тапкыр гамәлгә ашырыла;

бер тапкыр Органда яки КФҮ тә электрон документның нөсхә рәвешендә кәгазь йөрткечтәге муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу кирәк булган очракта.

Муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бер мәртәбә багланышының дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.

Мөрәҗәгать итүче күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын Республика порталы, терминал җайланмалары аша бәяләргә хокуклы.

2.15.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүматны мөрәҗәгать итүче Бердәм порталда яисә Республика порталында шәхси кабинетта, Органда, КФҮ тә алырга мөмкин.

2.15.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча яшәү урынына яисә фактта яшәү (булу) урынына бәйсез рәвештә Татарстан Республикасы территориясендә экстерриториаль принцип буенча.теләсә кайсы КФҮ тә гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәтне комплекслы гарызнамә составында алырга хокуклы.

## 2.16. Башка таләпләр, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча (әгәр муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә икән) муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алып, һәм электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре

2.16.1. Муниципаль хезмәт электрон рәвештә күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хаклы:

а) бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон рәвешләре 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсендәге 1 өлешенең 7.2 пункты нигезендә Республика порталыннан файдаланып таныкланган документлар һәм мәгълүмат бирүгә;

в) электрон рәвештә бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында мәгълүматлар алырга;

г) муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;

д) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә алырга;

е) Республика порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә кылынган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауларга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итүче федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Органның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, муниципаль

хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирергә.

2.16.2. Гаризаны формалаштыру Республика порталында гаризаның электрон рәвешен тутыру юлы белән нинди дә булса башка рәвештә гариза бирү зарурлыгыннан башка гамәлгә ашырыла.

2.16.3. Мөрәҗәгать итүчеләрнең КФҮ кә кабул итүгә язылуы (алга таба – язылу) Республика порталы, КФҮнең контакт-үзәге телефоны аша башкарыла.

Мөрәҗәгать итүчегә кабул итү өчен теләсә нинди буш вакытка күпфункцияле үзәкнең кабул итү графигының билгеләнгән чикләрендә язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу бу датага кадәр бер тәүлек кала тәгәлләнә.

Республика порталы ярдәмендә алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә система тарафыннан соратыла торган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилия, исем, атасының исемен (булган сурәттә);

телефон номерын;

электрон почта адресын (теләк буенча);

теләгән кабул итү датасын һәм вакытын.

Мөрәҗәгать итүче алдан язылу вакытында хәбәр иткән мәгълүматларның шәхси кабул итү вакытында гариза бирүче биргән документлардагы мәглүматларга туры килмәве очрагында алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда мөрәҗәгать итүчегә талон-раслауның распечаткасын алу мөмкинлеге бирелә.

Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын хәбәр итсә, күрсәтелгән адреска, кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда гариза бирүчегә мәҗбүри рәвештә, билгеләнгән кабул итү вакытына килмәгән очракта кабул итү вакытыннан 15 минут узгач, алдан язылу гамәлдән чыгарылуы турында хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүчедән, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан гайре, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен броньларга кирәк булган вакытлыча интервал дәвамлылыгын исәпләү өчен зарури мәгълүматлар бирүдән башка гамәлләр кылуны таләп итү тыела.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәтләр күрсәткәндәге гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау

3.1.13.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә (гариза бирүчегә) консультация (мәслихәт) бирү;

2) мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар комплектын (тупламын) кабул итү һәм карау;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара гарызнамәләр җибәрү;

4) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;

5) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

3.2. Гариза бирүче (мөрәҗәгать итүче) белән консультацияләр үткәрү (мәслихәт бирү)

3.2.1. Административ процедураны үтәүне башлауның нигезе – мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгате.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы урындагы кеше (хезмәткәр) булып тора:

-мөрәҗәгать итүче КФҮ кә мөрәҗәгать иткәндә – КФҮ хезмәткәре;

мөрәҗәгать итүченең Органга мөрәҗәгатендә – Органның әйдәүче белгече (алга таба – консультация (мәслихәт) бирү өчен җаваплы урындагы кеше).

3.2.2. Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында консультация сорап КФҮ тә шәхсән һәм телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә консультация бирә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тапшырыла торган документациянең составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча.

Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүматны КФҮ нең http://mfc16.tatarstan.ru сайтыннан ирекле файдалану юлы белән алырга мөмкин.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелә торган документациянең составы, формасы һәм муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча консультация.

3.2.3. Мөрәҗәгать итүче телефон һәм электрон почта аша Органга мөрәҗәгать итәргә, шулай ук Республика порталында, Органның муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында сайтында консультация алырга хокуклы, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тапшырыла торган документациянең составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча.

Консультация бирү өчен җаваплы вазыйфаи зат Регламентның 1.3.4 пункты таләпләре нигезендә мөрәҗәгать итүчегә мәгълүмат бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать кергән көннән алып өч эш көне эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелә торган документациянең составы, формасы һәм муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча консультацияләр.

3.3. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар комплектын (тупламын) кабул итү һәм карау

3.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документларны КФҮ яки КФҮнең ераклашкан эш урыны аша кабул итү.

3.3.1.1. Мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамә белән КФҮкә мөрәҗәгать итә һәм Регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны тапшыра.

3.3.1.2. Гаризаларны кабул итүче КФҮ хезмәткәре:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый;

мөрәҗәгать предметын билгели;

документлар бирүче затның вәкаләтләрен тикшерә;

документларның Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен тикшерә;

КФҮнең АМС на гаризаның электрон формасын тутыра;

Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар кәгазь йөрткечтә тапшырылганда, тапшырылган документларны сканерлауны гамәлгә ашыра;

КФҮ нең АМС нан  гаризаның распечаткасын ала;

мөрәҗәгать итүчегә тикшерүгә һәм кул куюга тапшыра;

имза салганнан соң кул куелган гаризаны КФҮ нең АМС нда сканерлый;

электрон формада яки электрон рәвештәге сканерланган тәкъдим ителгән документларны КФҮ нең АМС на кертә (йөкли), электрон дело (эш) формалаштыра;

имзаланган гаризаны һәм кәгазь документларның төп нөсхәләрен кире кайтара;

мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү хакында раслама бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: җибәрергә әзер гариза һәм документлар пакеты.

3.3.1.3. КФҮ хезмәткәре мөрәҗәгать итүчедән кабул ителгән документлар пакетын (электрон эшләр пакетлары составында) КФҮ нең структур бүлекчәсенә мөрәҗәгать иткән көннән бер эш көне эчендә электрон формада Органга җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: электрон багланыш системасы ярдәмендә Органга җибәрелгән гариза һәм документлар пакеты (электрон эш).

3.3.2. Республика порталы аша муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәтү өчен документлар кабул итү.

3.3.2.1. Гаризаны Республика порталы аша электрон рәвештә бирү өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

авторизацияне башкара;

электрон гариза формасын (рәвешен) ача;

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган мәгълүматларны үз эченә алган электрон гариза рәвешен тутыра;

документларны электрон формада яисә электрон документлар образларын электрон гариза формасына беркетә (зарурлык булганда);

электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтүнең шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамганы билгели);

хәбәр ителгән мәгълүматларның дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамганы билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасында тиешле төймәгә баса);

электрон гариза Регламентның 2.5.3 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаны җибәрү турында хәбәрнамә ала.

Әлеге пункт белән билгеләнгән административ процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә Органга юнәлтелгән электрон эш тора.

3.3.3. Орган тарафыннан документлар тупламын карау.

Административ процедураны үтәүне башлауга нигез булып муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм башка документлар килеп ирешү тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы урындагы кеше (хезмәткәр) – әйдәүче белгеч (алга таба – документларны кабул итү өчен җаваплы урындагы кеше).

Документлар кабул итү өчен җаваплы урындагы кеше, мөрәҗәгать итүченең Органга гаризасы белән мөрәҗәгать иткән очракта:

гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә номер һәм “Документларны тикшерү” статусы бирә;

килеп ирешкән электрон эшләрне, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан кушымта итеп бирелгән электрон формадагы документларны һәм документларның электрон рәвешләрен (образларын) өйрәнә;

документларның комплектлылыгын (тупланганлыгын), документларның электрон образларының (рәвешләренең) укылышын тикшерә;

Бердәм порталга мөрәҗәгать итү юлы белән электрон култамганың чын (дөрес) булу шартларының үтәлүен тикшерә (гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон култамга белән имзаланган электрон документлар рәвешләре тапшырылган очракта).

Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булганда, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын әзерли.

Көчәйтелгән квалификацияле электрон култамганы тикшерү нәтиҗәсендә аның чын булу шартларын үтәмәү ачыкланган очракта, баш тарту турындагы карар проектында аны кабул итүгә нигез булган 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 маддәсе пунктлары булырга тиеш.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проекты, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп (әгәр дә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуның нигезләре мондый документларга карата билгеләнгән таләпләрне бозу белән бәйле булса, документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрдә дөрес

булмаган һәм (яки) каршылыклы белешмәләр булган, билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән алдан тәкъдим ителмәгән документлар (мәгълүмат, белешмәләр) исеме турында мәгълүмат булырга тиеш), Регламентка 5 нче кушымта нигезендә форма буенча рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә электрон документ әйләнеше системасы аша килештерүгә җибәрелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проектын килештерү Регламентның 3.5.3 пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат, гариза кергән көннән алып бер эш көне эчендә гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә гаризаның теркәү номеры, гаризаны алу датасы, файлларның исемнәре, аңа тәкъдим ителгән документлар исемлеге, муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу датасы булган гариза килеп ирешү турында хәбәрнамә җибәрә.

3.3.3.2. Регламентның 3.3.3.1 пунктында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

3.3.3.3. Регламентның 3.3.3 пункты белән билгеләнә торган процедуралар гариза карауга кергән көннән бер эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: карауга кабул ителгән документлар тупламы яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты.

### 3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара гарызнамәләр юллау

3.4.1. Административ процедураны үтәүне башлау өчен нигез булып мөрәҗәгать итүчедән алынган документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи заттан (хезмәткәрдән) административ процедураны башкаруга вәкаләтле вазыйфаи затның (хезмәткәрнең) алуы тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы урындагы кеше (хезмәткәр) булып җитәкче урынбасары тора (алга таба – ведомствоара гарызнамәләр җибәрү өчен җаваплы урындагы кеше).

3.4.2. Ведомствоара гарызнамәләр җибәрү өчен җаваплы урындагы кеше ведомствоара электрон багланышлар системасы аша (техник мөмкинлек булмаганда – башка ысуллар белән) электрон рәвештә Регламентның 2.6.1 пунктында каралган документларны һәм мәгълүматларны тапшыруга гарызнамәләр формалаштыра һәм җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар карау өчен гариза кабул ителгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: хакимият органнарына һәм (яки) хакимият органнарына буйсынган оешмаларга юлланган гарызнамәләр.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан Регламентның 2.6.1 пунктының 1 - 8 бүлекләрендә күрсәтелгән документлар бирелгән очракта, шулай ук авария-

торгызу эшләрен уздыру өчен яисә яшел утыртмаларны кыру өчен (агачның, авария хәлендәге агачларның төшү-аву куркынычын бетерү өчен) рөхсәтнамә алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләрен технологик тоташтыру (ялгау) өлешендә ремонтлау, төзү, реконструкцияләү эшләрен башкарганда, ведомствоара гарызнамәләр җибәрү гамәлгә ашырылмый.

3.4.3. Белешмәләр белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре, ведомствоара электрон багланыш системасы аша кергән гарызнамәләр нигезендә, соратыла торган документларны (мәгълүматны) тапшыралар яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмау турында хәбәрнамәләр юллыйлар (алга таба – кире кагу турында хәбәрнамә).

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнгән процедуралар түбәндәге срокларда башкарыла:

Росреестр белгечләре тарафыннан җибәрелә торган документлар (мәгълүматлар) буенча өч эш көненнән артык түгел;

җирле үзидарә органнары һәм аларга буйсынучы оешмалар карамагындагы документлар (мәгълүматлар) буенча - өч эш көненнән артык түгел;

калган тәэминатчылар буенча – документ һәм мәгълүмат бирүче органга яки оешмага ведомствоара гарызнамә кергән көннән биш көн эчендә, әгәр ведомствоара гарызнамәгә җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актларында һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнмәгән булса.

Процедураларның нәтиҗәсе: муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар (мәгълүматлар) яисә ведомствоара гарызнамәләр җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелгән баш тарту турында хәбәрнамә.

3.4.4. Ведомствоара гарызнамәләр җибәрү өчен җаваплы урындагы кеше:

ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар (мәгълүматлар) яисә документ һәм (яисә) мәгълүмат булмаганда баш тарту турында хәбәрнамә ала;

регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булганда, ведомствоара гарызнамәләр җибәрелгән көннән биш эш көне узгач, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты әзерли.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проекты, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп (әгәр дә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуның нигезләре мондый документларга карата билгеләнгән таләпләрне бозу белән бәйле булса, документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрдә дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы белешмәләр булган, билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән алдан тәкъдим ителмәгән документлар (мәгълүмат, белешмәләр) исеме турында мәгълүмат булырга тиеш) Регламентка 5 нче кушымта нигезендә форма буенча рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә электрон документ әйләнеше системасы аша килештерүгә җибәрелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проектын килештерү Регламентның 3.5.3 пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларның үтәлеш нәтиҗәләре булып тора: муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар (мәгълүматлар) комплекты.

3.4.5. Регламентның 3.4.2, 3.4.4 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын, шул исәптән гаризаны Регламентның 2.13 пункты нигезендә теркәгән мизгелдән файдаланып, автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

3.4.6. Регламентның 3.4 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны үтәүнең максималь срогы биш эш көне тәшкил итә.

3.5. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү

3.5.1. Административ процедураны үтәүне башлап җибәрүгә нигез булып ведомствоара гарызнамәләр җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи заттан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның (мәгълүматларның) килеп ирешүе тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы урындагы кеше –җитәкче урынбасары (алга таба – муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы урындагы кеше).

3.5.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы урындагы кеше:

3.5.2.1. Мөрәҗәгать итүче кисү хокукына рөхсәтнамә сорап мөрәҗәгать иткән очракта:

мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүче вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризада күрсәтелгән ысул белән яшел утыртмаларны тикшерү датасы, вакыты һәм урыны турында хәбәр итә;

эшләр башкарыла торган урынга чыга, яшел утыртмаларны карый һәм фотога төшерә;

яшел утыртмаларны тикшерү актын әзерли (2 нче кушымта);

регламентның 2.8.2 пунктында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр ачыкланганда, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын әзерли;

регламентның 2.8.2 пунктында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта:

кирәк булганда, методика нигезендә компенсация бәясен исәпләүне башкара, компенсация бәясен түләү өчен исәп-хисап формалаштыра;

тикшерү актына кул куелганнан соң бер эш көне эчендә гаризада күрсәтелгән ысул белән компенсация бәясен исәпләп мөрәҗәгать итүчегә компенсация бәясен түләү зарурлыгы турында хәбәрнамә белән тикшерү актын җибәрә, дәүләт һәм муниципаль түләүләр буенча дәүләт мәгълүмат системасына исәп-хисапны куя;

дәүләт һәм муниципаль түләүләрнең дәүләт мәгълүмат системасына түләү турындагы мәгълүматларның керүенә мониторинг ясый;

мөрәҗәгать итүчегә компенсация бәясен түләүне гамәлгә ашыру кирәклеге турында хәбәрнамә җибәргәннән соң 7 эш көне эчендә компенсация бәясен түләмәү очрагында муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын әзерли;

муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен регламентның 2.8.2 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны карау нәтиҗәләре буенча яшел утыртмаларны кисү хокукына рөхсәтнамә проектын әзерли;

әзерләнгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе проектын билгеләнгән тәртиптә электрон документ әйләнеше системасы аша килештерүгә җибәрә.

Административ процедуралар 10 эш көне дәвамында башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре: тикшерү үткәрү турында хәбәрнамә, яшел утыртмаларны тикшерү акты, компенсация бәясен түләүне гамәлгә ашыру зарурлыгы турында хәбәрнамә, компенсация бәясен түләү өчен исәп-хисап; муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты, яшел утыртмаларны кисү хокукына рөхсәтнамә проекты.

3.5.2.2. Мөрәҗәгать итүче инженер-техник тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау, төзү, реконструкцияләү эшләрен башкарганда, челтәрләргә технологик тоташтыру (ялгау) өлешендә яшел утыртмаларны кисү хокукына рөхсәтнамә сорап мөрәҗәгать иткән очракта:

регламентның 2.8.2 пунктында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр ачыкланганда, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын әзерли;

регламентның 2.8.2 пунктында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта:

кирәк булганда, янәдән санау ведомосте буенча методика нигезендә компенсация бәясен исәпләүне башкара, компенсация бәясен түләү өчен счет формалаштыра;

гаризада күрсәтелгән ысул белән компенсация бәясен исәпләүне мөрәҗәгать итүчегә компенсация бәясен түләү кирәклеге турында тикшерү актына кул куелганнан соң бер эш көне эчендә хәбәрнамә белән җибәрә, дәүләт һәм муниципаль түләүләр буенча дәүләт мәгълүмат системасына исәп-хисапны куя;

яшел утыртмаларны кисү хокукына рөхсәтнамә проектын әзерли;

әзерләнгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе проектын билгеләнгән тәртиптә электрон документ әйләнеше системасы аша килештерүгә җибәрә.

Административ процедуралар бер эш көне дәвамында башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре: компенсация бәясен түләүне гамәлгә ашыру зарурлыгы турында хәбәрнамә, компенсация бәясен түләү өчен исәп-хисап; муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты, яшел утыртмаларны кисү хокукына рөхсәтнамә проекты.

3.5.2.3. Мөрәҗәгать итүче авария-торгызу эшләрен башкарганда яки яшел утыртмаларны кыру өчен чиктән тыш зарурлык хәлендә (агачның, авария

хәлендәге агачларның аву куркынычын бетерү өчен) яшел утыртмаларны кисү хокукына рөхсәтнамә сорап мөрәҗәгать иткән очракта:

мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүче вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризада күрсәтелгән ысул белән яшел утыртмаларны тикшерү датасы, вакыты һәм урыны турында хәбәр итә;

регламентның 2.8.2 пунктында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр ачыкланганда, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын әзерли;

регламентның 2.8.2 пунктында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, агачларның, куакларның авариялелеге турында бәяләмә белән яшел утыртмаларны тикшерү актын әзерли (2 нче кушымта).

Агачларның, куакларның авариялелеге турындагы бәяләмә белән яшел утыртмаларны тикшерү акты кыска вакыт эчендә аварияле агачларны һәм (яки) куакларны кисүгә хокук бирә.

Административ процедуралар ике эш көне дәвамында башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре: тикшерү үткәрү турында хәбәрнамә, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты, агачларның, куакларның авариялелеге турында бәяләмә белән яшел утыртмаларны тикшерү акты.

3.5.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе проектын (алга таба – документлар проектлары) килештерү һәм имзалау муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе, Орган җитәкчесе урынбасары, Орган җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Искәртүләре булган карарларның әзерләнгән проектлары муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы затка кире кайтарыла.

Искәртүләрне бетергәннән соң, документлар проектлары кабат килештерү һәм кул кую өчен тапшырыла.

Орган җитәкчесе документлар проектларын имзалаганда, Регламентның административ процедураларны үтәү срокларын, аларның эзлеклелеген һәм тулылыгын, электрон документ әйләнеше системасында Органның вәкаләтле вазыйфаи затларының килешүләрен үтәүне тикшерә.

Административ процедураларны үтәү срокларын, аларның эзлеклелеген һәм тулылыгын ачыклау өлешендә тәртип бозулар ачыкланган очракта, Орган җитәкчесе регламентның 4.3 пункты нигезендә хокук бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту инициативасы белән чыга.

Административ процедуралар бер эш көне дәвамында башкарыла.

Административ процедураларның үтәлеше нәтиҗәләре булып тора: муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар, яшел утыртмаларны кисү хокукына рөхсәтнамә.

3.5.4. Регламентның 3.5.2, 3.5.3 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен

билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

3.5.5. Регламентның 3.5 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны үтәүнең максималь срогы, мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта - 11 эш көне; мөрәҗәгать итүченең челтәргә технологик тоташтыру (ялгау) өлешендә инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау, төзү, реконструкцияләү эшләрен башкарганда муниципаль хезмәт күрсәтүләр алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта - ике эш көне; мөрәҗәгать итүченең авария-торгызу эшләрен башкарганда яисә чиктән тыш кирәк булу хәлендә яшел утыртмаларны кыру өчен муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта (агач, авария хәлендәге агачларның аву куркынычын бетерү өчен) – ике эш көне.

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү (җибәрү)

3.6.1. Административ процедураны башкару өчен нигез булып административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне (кире кагуны) раслаучы документ алу тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы урындагы кеше булып җитәкче урынбасары (алга таба - документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы урындагы кеше) тора.

Документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы урындагы кеше:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен аталган автоматлаштырылган мәгълүмат системасы документациясен алып бару ярдәмче системасына муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турындагы мәгълүматларны теркәүне һәм кертүне тәэмин итә;

мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) электрон хезмәттәшлек (багланыш) ярдәмендә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында һәм КФҮтә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу мөмкинлеге турында Республика порталы аша хәбәр итә.

Процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, автомат рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү (күрсәтүне кире кагу) нәтиҗәсе булган документка Органның вәкаләтле вазыйфаи заты (Орган) кул куйган көннән алып бер эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: мәгълүмат системаларында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыру, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре һәм аны алу ысуллары турында хәбәрнамә ирештерү.

3.6.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү) тәртибе:

3.6.2.1. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт нәтиҗәсен сорап КФҮ кә мөрәҗәгать иткәндә, КФҮ хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә электрон документның кәгазь йөрткечтәге нөсхәсе рәвешендә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирә. Мөрәҗәгать итүче таләбе буенча аңа электрон документның кәгазь йөрткечтәге

нөсхәсе белән бергә аны салдырыла торган йөрткечкә яздыру юлы белән электрон документның нөсхәсе бирелә яки мөрәҗәгать итүче адресына электрон почта аша электрон документның нөсхәсе җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән административ процедуралар мөрәҗәгать итүченең КФҮ регламентында билгеләнгән срокларда килү көнендә чиратлылык тәртибендә башкарыла.

3.6.2.2. Мөрәҗәгать итүче Республика порталы аша муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен сорап мөрәҗәгать иткәндә, мөрәҗәгать итүчегә шәхси кабинетка автомат рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган, Органның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон култамгасы белән имзаланган документның электрон үрнәге җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслаучы документка Органның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан кул куелган көнне башкарыла.

Административ процедураларның үтәлеше нәтиҗәләре булып тора: гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүне раслаучы документның Республика порталыннан файдаланып җибәрү (бирү) (шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту).

### 3.7. Техник хаталарны төзәтү

3.7.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып торган документта техник хата барлыгы беленгән очракта гариза бирүче (мөрәҗәгать итүче) Органга җибәрә:

техник хатаны төзәтү турында гариза (әлеге административ регламентка 7 нче кушымта);

муниципаль хезмәт нәтиҗәсе буларак гариза бирүчегә бирелгән техник хаталы документ;

техник хата булуны дәлилләүче юридик көчкә ия булган документлар.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән мәгълүматларда техник хатаны төзәтү турында гаризаны мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) почта аркылы (шул исәптән электрон почтаны кулланып) яки Республика порталы яисә КФҮ аша бирә.

3.7.2. Документлар кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, кушымта итеп теркәлгән документлар белән гаризаны терки һәм аларны документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гаризаны теркәү датасыннан бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка карауга юнәлтелгән кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.7.3. Документлар эшкәртүгә җаваплы вазыйфаи зат документларны карый һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм төзәтелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) техник хата булган документның төп нөсхәсен  алып калып шәхсән кул куйдырып

бирә яки гариза бирүче адресына почта аша (электрон почта ярдәмендә) Органга техник хата булган документның төп нөсхәсен тапшырганда документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хатаны ачыклаганнан яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң ике эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүгә контроль тәртибе һәм формалары

4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан регламент нигезләмәләрен һәм муниципаль хезмәт күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларны үтәүгә һәм башкаруга, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүгә агымдагы контрольне гамәлгә ашыру тәртибе

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгына һәм сыйфатына контроль мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуын ачыклау һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлүенә тикшерүләр уздыруны, җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешенә контроль формалары булып торалар:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү.

2) делопроизводствоны алып баруны билгеләнгән тәртиптә уздырылучы тикшерүләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларын үтәүгә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Агымдагы контроль максатларында электрон мәгълүматлар базасында булган белешмәләр, хезмәт урыны корреспонденциясе, административ процедураларны үтәүче вазыйфаи затларның телдән һәм язма мәгълүматы, тиешле документларны исәпкә алу журналлары һәм башка мәгълүматлар файдаланыла.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм җирле үзидарә органы җитәкчесенә карарлар кабул иткәндә гамәлләрнең башкарылуын тикшереп тору өчен муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр бирелә.

Административ процедураларның срокларын, эзлеклелеген һәм эчтәлеген бозу очраклары һәм сәбәпләре турында вазыйфаи затлар кичекмәстән муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенә хәбәр итәләр, шулай ук бозуларны бетерү буенча ашыгыч чаралар күрәләр.

Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контроль муниципаль хезмәт күрсәтү эшен оештыруга җаваплы җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары, муниципаль хезмәт күрсәтү эшен оештыручы бүлек башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге җирле үзидарә органының структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфаты буенча планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне гамәлгә ашыру тәртибе һәм периодиклыгы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарә органы эшенең ярты еллык яисә еллык планнары нигезендә гамәлгә ашырылырга) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәт күрсәтүгә (комплекслы тикшерүләргә) бәйле барлык мәсьәләләр яисә мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча каралырга мөмкин.

4.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында үзләре тарафыннан кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен муниципаль хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затларының (урындагы кешеләренең) җаваплылыгы

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылган очракта гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

Җирле үзидарә органы җитәкчесе гариза-мөрәҗәгатьләрне вакытында тикшермәгән өчен җаваплы.

Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (җитәкче урынбасары) Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яисә) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә торган (гамәлгә ашырыла торган) карар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр законнарда билгеләнгән тәртиптә җаваплы булалар.

4.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне тикшереп тору тәртибенә һәм рәвешләренә таләпләрне сыйфатлаучы нигезләмәләр, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан да.

Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне тикшереп тору (контроль) муниципаль хезмәт күрсәткәндә җирле үзидарә органы эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

**5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, 2010 елның 27 июлендәге 210-**

**ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның урындагы кешеләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе**

5.1. Муниципаль хезмәт алучылар муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган хезмәткәренең, җитәкчесенең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр тәртиптә шикаять бирү хокукына ия.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 маддәсендә күрсәтелгән гарызнамәне, муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гарызнамәне теркәү срокларын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, аның хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда тапшыру яисә гамәлгә ашыру каралмаган документларны яки мәгълүматны яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гамәлләр кылуны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда баш тарту нигезләре күздә тотылмаган булуга карамастан муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, аның хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин;

6) муниципаль хезмәт күрсәтүдә гариза бирүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, муниципаль район норматив хокукый актларында күздә тотылмаган түләүне таләп итү;

7) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмалар яисә аларның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хата һәм ялгышларны төзәтүне кире кагуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, аның хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирүнең срогын яисә тәртибен бозу;

9) федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары, муниципаль районның норматив хокукый актларында муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатуга нигезләр күздә тотылмаган булуга карамастан, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату (туктатып тору);

Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, аның хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин;

10) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны баштагы кабул итүдәге кире кагуда юклыгы һәм (яки) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүматны муниципаль хезмәт күрсәтүдә, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ Федераль законның 7 маддәсе 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан гайре, мөрәҗәгать итүчедән таләп итү.

Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, аның хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин.

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазь йөрткечтә, электрон рәвештә муниципаль хезмәтне күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә яки күпфункцияле үзәкне

гамәлгә куючы тиешле дәүләт хакимияте органына (алга таба – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы), шулай ук 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларга тапшырыла. Муниципаль хезмәтне күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр югарырак органга (ул булган очракта) бирелә яки ул булмаган очракта турыдан-туры муниципаль хезмәтне күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала. Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр шушы күпфункцияле үзәк җитәкчесенә бирелә. Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәкне оештыручыга яисә Татарстан Республикасының норматив хокукый акты белән вәкаләтле вазыйфаи затка тапшырыла. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр әлеге оешмалар җитәкчеләренә бирелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аркылы, күпфункцияле үзәк аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайтыннан, Бердәм порталдан яисә республика порталыннан, судка кадәр шикаять бирү мәгълүмат системасыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәкнең, Бердәм порталның яисә Республика порталының рәсми сайтыннан, судка шикаять бирүнең мәгълүмат системасы аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1 өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, әлеге оешмаларның, Бердәм порталның яисә Республика порталының рәсми сайтларыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесе һәм (яисә) хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның җитәкчеләре һәм (яисә) хезмәткәрләренең исемнәрен (аталышларын);

2) мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), гариза бирүченең – физик затның яшәү урыны турында мәгълүматлар, гариза бирүченең – юридик затның урнашу урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта

адресы (булган очракта) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы (булганда);

3) муниципаль хезмәтне күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүче алар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешми торган дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аның дәлилләрен раслаучы документлар (булганда) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.4. Килеп ирешкән шикаять кергән көннән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш.

5.5 Муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларга яисә югарырак органга (ул булганда) кергән шикаять теркәлгән көннән алып унбиш эш көне эчендә каралырга тиеш, ә муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларга карата шикаять белдерелгән очракта мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдә яки җибәрелгән хата һәм ялгышларны төзәтүдә яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылган очракта – аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.6.Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның кайсы да булса берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә түләтү Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартырга.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.7. Шикаятьнең канәгатьләндерелергә тиешле дип танылу очрагында мөрәҗәгать итүчегә шикаятьне карау нәтиҗәләре турындагы җавапта муниципаль хезмәт күрсәткәндә беленгән бозуларны кичекмәстән бетерү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы

Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмалар тарафыннан тормышка ашырылучы гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук күрсәтелгән уңайсызлыклар өчен кичерү сорала һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне алу максатларында гариза бирүчегә кылу зарур булган алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаятьнең канәгатьләндерелергә тиешле түгел дип табылу очрагында мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре хакында дәлилле аңлатмалар бирелә, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат китерелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре табылу очрагында шикаятьләрне карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрәләр.

Яшел утыртмаларны кисү хокукына
рөхсәтнамә бирү буенча муниципаль
хезмәт күрсәтүнең административ
регламентына кушымта №1

(Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган бланкы)

Яшел утыртмаларны кисү хокукына
РӨХСӘТНАМӘ

20 ___ елның ____ _______ __ № _____

20 ___ елның ____ _________ _____номерлы гаризага ярашлы рәвештә 20 ___ елның ____ _________ _____номерлы яшел утыртмаларның урнашу урынын тикшерү акты нигезендә ________________________(Ф.И.А.и., оешма)__________________________максатларында түбәндәге агачларны кисәргә (кырырга) РӨХСӘТ ИТЕЛӘ:

| №№ п/п | Урнашу урыны | Агач төре | Кәүсә диаметры | Саны данә | Агачларның хәле (торышы) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | |
| | | Барысы: | | | |

<u>РӨХСӘТНАМӘДӘ күрсәтелмәгән агачларны сакларга:</u>
Агач калдыкларын 2 көн эчендә чыгарырга.
Кисү-юнышу калдыкларын яндыру һәм контейнер мәйданчыкларына туплау (өю)тыела.
Компенсация рәвеше: __________________.
Кисүгә РӨХСӘТНАМӘНЕҢ гамәлдә булу вакыты: 20 ___ елның ____ _________кадәр.
20 ___ елның ____ _________кадәр озайтылды.

____________________ ______________ __________________
вазыйфа имза имзаның расшифровкасы

Агачларны кыру куркынычсызлык техникасы нигезендә башкарыла. Россия Федерациясендә гамәлдә булган кагыйдәләр (таләпләр, техник шартлар) белән аерым агачларны яисә куакларны (билгеле бер территорияләрдән агачлар яки куакларны) кисү махсуслаштырылган оешмаларны (белгечләрне) яисә махсус җиһазларны җәлеп итеп гамәлгә ашырылган очракта, мөрәҗәгать итүче әлеге таләпләрне үтәүне тәэмин итәргә тиеш.
Агач һәм куакларны кисү эшләрен башкарганнан соң территорияне гомуми төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыру (агач кәүсәләрен, ботакларны, башка чүп-чарны чыгаруны, планлаштыру эшләрен уздыруны да кертеп) мәҗбүри.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе ____________________

Яшел утыртмаларны кисү хокукына рөхсәтнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кушымта №2

Яшел утыртмаларны тикшерү
АКТЫ № ____

20 ___ елның ____ _________ ________________________________________урамы

(кирәк булганда объектның тулы исеме, кадастр номеры белән җир кишәрлеге күрсәтелә)
Кадастр номеры:
Адрес:
Комиссия әгъзалары :
(вазыйфасы, Ф.И.А.и.)
________________________________________________________________

Катнашучы вәкил: (Ф.И.А.и., вазыйфасы, оешма)
1. ______________________________________________________________________________

Тикшерүгә нигез: ___________________________________________________________

Тикшерү барышында шул тәгаенләнде: ___________________урамындагы кадастр номеры ___________булган _________________ урамында җир кишәрлегендә урнашкан ___________________зонада _______________________төзелешкә (реконструкцияләүгә рөхсәтнамә, эшләр башкаруга ордер) РӨХСӘТНАМӘНЕ исәпкә алып түбәндәге яшел утыртмалар туры килә:
Яшел утыртмалар төркеме:
- төркемнең исеме (аталышы) __________________________________________________,
- төркемне тасвирлау ______________________________________________________,
- яшел утыртмаларның төр составы _______________________________________________.

Барысы:

Комиссинең бәяләмәсе

Авария хәлендәге агачлар кыска вакыт эчендә киселергә тиеш.

_______________________________ _____________________________________________
(Ф.И.А.и.) (комиссия рәисе имзасы)

Зарурлык булганда:
1. __________________________ _____________________________________________
(Ф.И.А.и.) (вәкилнең имзасы)

Яшел утыртмаларны кисү хокукына
рөхсәтнамә бирү буенча муниципаль
хезмәт күрсәтүнең административ
регламентына кушымта №3

(Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган бланкы)

Яшел утыртмаларны кисү хокукына рөхсәтнамә бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында
КАРАР

__________________________________________турындагы 20 ___ елның ____ ___________
____ номерлы гаризасы белән _____________________________________________мөрәҗәгатенә
(мөрәҗәгать итүче физик затның Ф.И.А.и., юридик затның аталышы)
бәйле рәвештә ____________________________________________________________нигезләнеп

тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләргә таянып муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

1.______________________________________________________________________________

2. _________________________________________________________________________

Вазыйфаи зат (урындагы кеше) (ФИАи) _______________________________________

(кул куюны гамәлгә ашыручы органның
вазыйфаи заты имзасы)

Башкаручы (ФИАи)
___________________________
(Башкаручының контактлары)

Яшел утыртмаларны кисү хокукына рөхсәтнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кушымта №4

Юридик затлар өчен

(Җирле үзидарә органының аталышы)

________________________________________

________________________________________

(оешманың һәм оештыру-хокукый рәвешенең тулы аталышы)

________________________________________

йөзендә

(Җитәкченең яисә башка вәкаләтле затның ФИА)

Мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ

________________________________________

(документның төре)

________________________________________

(серия, номер)

________________________________________

(кем тарафыннан, кайчан бирелгән)

Юридик затны дәүләт теркәве турында белешмәләр:

ТДТН

________________________________________

________________________________________

СТТН

________________________________________

Булу урыны

________________________________________

________________________________________

Контакт мәгълүматлары:

тел.номеры 1 ____________________________

тел.номеры 2 ____________________________

эл. почта ________________________________

________________________________________

Физик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар өчен

ФИАи

________________________________________

Шәхесне таныклаучы документ:

________________________________________

(документның төре)

________________________________________

(серия, номер)

(кем тарафыннан, кайчан бирелгән)

ИЭТДТН (ИЭ өчен)

Теркәлү адресы

Ышанычнамә буенча вәкил яисә законлы вәкил:

ФИАи

Шәхесне таныклаучы документ:

(документның төре)

(серия, номер)

(кем тарафыннан, кайчан бирелгән)

Вәкаләтләрне раслаучы документның реквизитлары:

Теркәлү адресы

Контакт мәгълүматлары:

тел.номеры 1 тел.номеры 1

тел.номеры 2 тел.номеры 2

эл. почта эл. почта

## ГАРИЗА РӘВЕШЕ

________________________________________бәйле рәвештә

(Регламентның 2.5.2 - 2.5.4 пунктлары нигезендә яшел утыртмаларны кыру һәм (яисә) күчереп утырту өчен нигез күрсәтелә)

мәйданы _______________булган _____________________________ җир кишәрлегендә

(җир кишәрлегенең урнашу урыны адресы)

үсеп чыккан _______________яшел утыртмаларны кисү хокукына рөхсәтнамә

(яшел утыртмалар саны)

бирүегезне сорыйм.

Телефоннан яисә электрон адрес буенча яшел утыртмаларны тикшерү көне, вакыты һәм урыны турында хәбәр итүегезне сорыйм (*кирәклесен күрсәтергә*):

_______________________________________________________________

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен минем адреска түбәндәге ысул белән бирүне (җибәрүне) сорыйм:

□ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетына электрон рәвештә

□ КФҮ тә

Яшел утыртмаларны тикшергәндә мәҗбүри булу һәм аны уздырган көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча тикшерү акты белән танышу зарурлыгы турында, шулай ук тикшерүгә килмәү нәтиҗәләре турында хәбәрдармын.

Имзам:
Кушымталар:
1. ______________________________
2. ______________________________
3. ______________________________

Мөрәҗәгать
итүченең имзасы ____________________
(имзаның
расшифровкасы)

Дата ______________________________

Яшел утыртмаларны кисү хокукына
рөхсәтнамә бирү буенча муниципаль
хезмәт күрсәтүнең административ
регламентына кушымта №5

Рәвеш

## Яңадан санау ведомосте

_____________________________________________________________эшләрне башкару өчен
(эш төрләре)

_____________________________________________________________________________

(яшел утыртмаларның адресы (урнашу урыны), җир кишәрлегенең кадастр номеры күрсәтелә)

адресы буенча урнашкан агачлар һәм куакларны яңадан санау ведомосте.

_____________________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүче күрсәтелә: юридик зат өчен - оешманың тулы аталышы, физик зат өчен - Ф.И.А.и.)

| № п/п | Төрнең аталышы | Саны, данә | | Диаметр, см, мәйдан, кв. м, озынлы гы , п.м | Яшел утыртмаларның торышына сыйфатлама (яхшы, канәгатьләнерлек, канәгатьләнмәслек) | Искәрмә (саклап калырга, кисәргә, күчереп утыртырга) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | агачлар | куаклар | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | Барысы | | | | | |

Агач һәм куаклар саны:
саклап калынырга тиешле: агачлар ________ куаклар ____________
киселергә җиешле: агачлар ________ куаклар ____________
күчереп утыртылырга тиешле: агачлар ________ куаклар ____________

Юк ителергә тиешле үлән капламының (газон) мәйданы ________ кв. м

Төзеде (вазыйфа, Ф.И.О.и., имза)
Тикшерде (вазыйфа, Ф.И.О.и., имза)

Дата ________________

Яшел утыртмаларны кисү хокукына рөхсәтнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кушымта №6

(Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган бланкы)

Яшел утыртмаларны кисү хокукына рөхсәтнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында
КАРАР

_______________________________________________________ мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә
(мөрәҗәгать итүче физик затның Ф.И.А.и. , юридик затның аталышы)

20 ___ елның ____ _____________ ____номерлы _______________________ турындагы гаризаны һәм бирелгән документларны карау нәтиҗәләре буенча
__________________________________________________________________________нигезендә

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны түбәндәгеләргә бәйле рәвештә кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде:
1. ____________________________________________________________________________

2.____________________________________________________________________________

Вазыйфаи зат (урындагы кеше) (ФИАи) ____________________________________

(кул куюны гамәлгә ашыручы органның вазыйфаи заты имзасы)

Башкаручы (ФИАи)
__________________________
(башкаручының контактлары)

Яшел утыртмаларны кисү хокукына рөхсәтнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кушымта №7

__________________муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенә
____________________________

техник хатаны төзәтү турында
ГАРИЗА.

_______________________________________________муниципаль хезмәт
(күрсәтелгән хезмәтнең исеме)
күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.
Язылган:_________ _____________________________________________________
__________________________________________________________________________
Дөрес
мәгълүматлар:_______________________________________________________________
________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып торган документка тиешле үзгәрешләрне кертүне үтенәм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.
3.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кире кагу хакында карар кабул иткән очракта андый карарны җибәрүне үтенәм:

электрон документны E-mail________________адресына җибәрү ярдәмендә; почта аша кәгазь йөрткечтә расланган күчермә рәвешендә түбәндәге адрес буенча: __________________________________________________________________ ___

Әлеге гариза белән раслыйм: гаризадагы минем шәхескә һәм минем тарафтан тәкъдим ителүче затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры киләләр, гаризаны бирү моментына бу документлар чын һәм дөрес мәгълүматларны үз эчләренә алалар.

_______________ __________________ ( _________________)
(дата) (имза) (Ф.И.А.и.)

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Балык Бистәсе шәһәр
җирлеге Башкарма комитетының
2022 елның 31 мартындагы 29
номерлы карарына
кушымта №2

**Күпфатирлы йортта бүлмәләрне (урыннарны) үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты һәм күпфатирлы йортта бүлмәләрне төгәлләнгән үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турындагы актны кабул итү комиссиясе тарафыннан рәсмиләштерү**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – административ регламент) күпфатирлы йортта бүлмәләрне (урыннарны) үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү һәм күпфатирлы йортта бүлмәләрне төгәлләнгән үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турындагы актны кабул итү комиссиясе тарафыннан рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең (алга таба – муниципаль хезмәт) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт алучылар: күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре булып торучы физик затлар һәм юридик затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

Мөрәҗәгать итүчеләрнең мәнфәгатьләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан билгеләнгән тәртиптә вәкаләт бирелгән затлар һәм физик затларның законлы вәкилләре (алга таба - мөрәҗәгать итүче вәкиле) тәкъдим итә ала.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мәгълүмат бирү (хәбәр итү)

1.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат урнаштырыла:

1) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре биналарында урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендларында;

2) муниципаль районның “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге https://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru/ рәсми сайтында;

3) Татарстан Республикасының https://uslugi.tatarstan.ru дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр Порталында (алга таба – Республика порталы);

4) http:// www.gosuslugi.ru Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләр) порталында (алга таба – Бердәм портал);

5) “Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры” дәүләт мәгълүмат системасында (http://frgu.tatar.ru) (алга таба – Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры).

1.3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча консультация (мәслихәт) бирү гамәлгә ашырыла:

1) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яисә телефон буенча;

2) Республика порталының интерактив рәвешендә;

3) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетында (алга таба – Орган):

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яисә телефон буенча;

язма рәвештә (шул исәптән электрон документлар рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә – кәгазь йөрткечтә почта аша, электрон рәвештә электрон почта аша.

1.3.3. Бердәм порталда, Республика порталында Республика реестрындагы мәгълүматлар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат гариза бирүчегә бушлай бирелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка мөрәҗәгать итүченең нинди дә булса таләпләр үтәмичә генә, шул исәптән, мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштыру гариза бирүчедән түләү алуны, теркәүне яисә авторизацияне күздә тотучы программа тәэмин ителешенең хокук иясе белән лицензияле яисә башка килешү төзүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча яисә аларга шәхси мәгълүматлар бирмичә керү мөмкинлеге гамәлгә ашырыла.

1.3.4. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яки телефон аша мөрәҗәгать иткән очракта, кергән мөрәҗәгать нигезендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, *Органның* урнашу урыны турында мәгълүмат бирелергә мөмкин (адрес, эш графигы, белешмә телефоннары); муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе, гаризалар бирү ысуллары һәм сроклары турында; муниципаль хезмәт күрсәтелә торган гражданнар категорияләре хакында; муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләрен җайга салучы норматив хокукый актлар турында; муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны карау өчен кирәкле документлар исемлеге, гаризаны кабул итү һәм теркәү сроклары, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы хакында; муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүматның рәсми сайтта урнаштырылу урыны турында; *Органның* вазыйфаи затларының (урындагы кешеләренең) гамәлләренә яки гамәл кылмауларына карата шикаять белдерү тәртибе хакында.

Язма мөрәҗәгать буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы бүлекнең вазыйфаи затлары мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен һәм регламентның әлеге пунктында күрсәтелгән мәсьәләләрне язма рәвештә аңлаталар һәм мөрәҗәгатьне теркәгәннән соң өч эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрәләр. Җаваплар мөрәҗәгать иткән телдә бирелә. Мөрәҗәгать иткән телдә җавап бирү мөмкин булмаган очракта Татарстан Республикасы дәүләт телләре кулланыла.

1.3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат муниципаль районның рәсми сайтында һәм *Орган* бүлмәләрендәге гариза бирүчеләр белән эшләү өчен куелган мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

“Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге муниципаль районның рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларында урнаштырылган

Татарстан Республикасы Дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге Регламентның 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы үзидарәлек хезмәте турындагы мәгълүматларны, *Органның* урнашу урыны, белешмә телефоннары, эш вакыты, муниципаль хезмәт күрсәтүгә гаризалар кабул итү графигы турында мәгълүматны үз эченә ала.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актлар реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп) “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта, Республика реестрында урнаштырылган.

Гамәлдәге редакциядә административ регламент тексты Республика реестрында, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштырылырга тиеш.

1.5. Регламентта түбәндәге атамалар (терминнар) һәм билгеләмәләр файдаланыла:

вәкаләтле затлар дигәндә, милекченең ышанычнамә яисә граждан-хокукый шартнамә нигезендә вәкилләре булган физик затлар, индивидуаль эшкуарлар, юридик затлар аңлашыла;

дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтү күпфункцияле үзәгенең ераклашкан эш урыны – 2012 елның 22 декабрендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтү күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләрен раслау турында” 1376 номерлы карары белән расланган дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтү күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районының шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында төзелгән дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтү күпфункцияле үзәгенең территория ягыннан аерымланган структура бүлекчәсе (офисы);

техник хата – үзидарәлек хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка кертелгән (үзидарәлек хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсенә) мәгълүматларга тәңгәл булмауга, алар нигезендә кертелгән мәгълүматларның документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китерүче ялгыш (ялгышлык белән җибәрелгән хәреф, сүз хатасы, грамматик яки арифметик хата яисә шуларга охшаш ялгышлыклар).

күпфатирлы йортта бүлмәне (урынны) үзгәртеп кору күпфатирлы йорттагы бүлмәнең техник паспортына үзгәрешләр кертүне таләп итә торган инженерлык челтәрләрен, санитар-техник, электр яисә башка җиһазларны урнаштыру, алмаштыру яисә күчерүне аңлата;

күпфатирлы йорттагы бүлмәне (урынны) яңадан планлаштыру күпфатирлы йорттагы урынның техник паспортына үзгәреш кертүне таләп итә торган конфигурациясен (предметларның яисә аларның кисәкләренең үзара урнашуын) үзгәртүдән гыйбарәт;

Электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик үзара хезмәттәшлеген (багланышын) тәэмин итүче инфраструктурада идентификацияләүнең (бердәйләштерүнең, тәңгәлләштерүнең) һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы (алга таба – ЕСИА (Единая система

идентификации и аутентификации)) – дәүләт мәгълүмат системаларында һәм башка мәгълүмат системаларында булган мәгълүматны идентификацияләү һәм аутентификацияләү системасында мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучыларның санкцияләнгән файдалана алуын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы;

КФҮ – “Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге” дәүләт бюджет учреждениесе;

КФҮ нең АМС – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы.

Регламентта муниципаль (үзидарәлек) хезмәте күрсәтү турындагы гариза дигәндә (алга таба – гариза) үзидарәлек хезмәте күрсәтү турында “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 маддәсенең 3 пункты (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә бирелгән гарызнамә (рәсми таләп) аңлашыла.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

2.1. Муниципаль хезмәтнең аталышы

Күпфатирлы йортта бүлмәләрне (урыннарны) үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү һәм күпфатирлы йортта бүлмәләрне төгәлләнгән үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турындагы актны кабул итү комиссиясе тарафыннан рәсмиләштерү

2.2 Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарәнең башкарма-боеручы органының исеме (аталышы)
Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты

2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау

2.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып тора:

1) күпфатирлы йортта бүлмәне (урынны) үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү (1 нче кушымта);

2) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар (2 нче кушымта);

3) күпфатирлы йортта бүлмәне (торак урынны) төгәлләнгән үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турында акт (7 нче кушымта).

2.3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе “Электрон имза турында” 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә мөрәҗәгать итүчегә Бердәм порталның шәхси кабинетына Органның вәкаләтле вазыйфаи затының (урындагы кешесенең) (яисә Органның) көчәйтелгән квалификацияле электрон култамгасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

2.3.3. Мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе Органда яки КФҮтә кәгазьдә йөрткечтәге электрон документ нөсхәсе рәвешендә бирелә, ул тиңдәшле рәвештә Органның вәкаләтле вазыйфаи заты яисә КФҮ хезмәткәре имзасы һәм мөһер белән таныкланган була.

2.3.4. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәтне күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең гамәлдә булу срогы дәвамында алырга хокуклы.

## 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы

2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты – 15 эш көне.

Мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе Торак кодексының 26 маддәсендәге 2.1 өлешендә каралган документларны тапшыру кирәклеге турында хәбәрнамә җибәрелгән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты - 30 эш көне.

Күпфатирлы йортта бүлмәне үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыруны тәгәлләү буенча кабул итү комиссиясе актын төзү 10 эш көненнән дә артмаска тиеш.

Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты гаризаны теркәгәннән соң икенче көнне исәпләнә башлый.

2.4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

2.4.3. Электрон документ формасында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документ муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

## 2.5. Үзидарәлек хезмәте күрсәтү өчен законнар яки башка норматив хокукый актлар нигезендә гариза бирүче тапшырырга тиешле зарури документларның, шулай ук үзидарәлек хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрнең тулы исемлеге, аларны гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Муниципаль хезмәт алу өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тапшыра:

1) шәхесне таныклаучы документ (Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта таләп ителми);

2) мөрәҗәгать итүче вәкиле муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклаучы документ (физик затларның законлы вәкилләреннән гайре).

3) гариза:

- КФҮ кә мөрәҗәгать иткәндә кәгазь йөрткечтәге документ рәвешендә (3, 4 нче кушымталар);

- электрон рәвештә (тиешле мәгълүматларны гаризаның электрон рәвешенә кертү юлы белән тутырыла), ул Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә Регламентның 2.5.3 пункты таләпләре нигезендә имзалана.

**4) күпфатирлы йортта үзгәртеп корыла торган һәм (яисә) яңадан планлаштырыла торган бүлмәгә (урынга) хокук билгели торган документлар (төп нөсхәләр яисә нотариаль тәртиптә таныкланган күчермәләр), әгәр аңа хокук Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында теркәлмәгән булса, яңа төзелгән йортларда эшләр башкарылган очрактан тыш, бүлмәгә теркәлгән хокуклар булмаганда;**

Яңа төзелә торган йортларда өлешләп төзелештә катнашу шартнамәсе буенча эшләр башкарганда, бүлмәгә теркәлгән хокуклар булмаган очракта, Регламентның 2.5.1 пунктының 4 пунктчасында каралган хокук билгели торган документлар урынына мөрәҗәгать итүче түбәндәге документлар тапшыра:

а) өлешләп төзелештә катнашу шартнамәсе (шартнамәдә төзүченең бүлмәне яңадан планлаштыруга ризалыгы булырга тиеш) яисә нотариаль таныкланган күчермә;

б) өлешләп төзелештә катнашу шартнамәсе буенча хокукларны бирү турында шартнамә (шартнамә буенча хокукларга ташлама яки юл кую булса) яисә нотариаль таныкланган күчермә;

в) күчемсез милекне кабул итү-тапшыру акты яисә нотариаль таныкланган күчермә;

г) төзүчедән өлешләп төзүдә катнашучының шартнамә буенча йөкләмәләре тулысынча үтәлүе турында белешмә (әгәр күчемсез милекне кабул итү-тапшыру актында әлеге йөкләмәләрнең үтәлеше турында мәгълүмат булмаса);

5) билгеләнгән тәртиптә әзерләнгән һәм рәсмиләштерелгән күпфатирлы йортта үзгәртеп корыла һәм (яки) яңадан планлаштырыла торган бүлмәне үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру проекты;

6) күпфатирлы йортта бүлмәне үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтнең бер өлешен әлеге бүлмәгә кушмыйча гына мөмкин булмаса, күпфатирлы йорттагы урыннарның барлык милекчеләренең күпфатирлы йорттагы бүлмәне мондый үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру өчен ризалыгы турында Россия Федерациясе Торак кодексының 40 маддәсендәге 2 өлешендә каралган гомуми җыелышның беркетмәсе;

Арендатор, яллаучы, авыр йөкләнештәге (ипотекадагы) бүлмә милекчесенең мөрәҗәгать итү очрагында:

7) социаль наем шартнамәсе нигезендә үзгәртеп корыла торган һәм (яисә) яңадан планлаштырыла торган торак урынын биләп торучы барлык гаилә әгъзаларының (шул исәптән яллаучының вакытлыча булмаган гаилә әгъзаларының) язма рәвештә ризалыгы (әгәр мөрәҗәгать итүче социаль наем шартнамәсе буенча үзгәртеп корыла һәм (яисә) яңадан планлаштырыла торган торак урынын яллаучы әлеге пунктта каралган документларны тапшыруга вәкаләтле файдалануга бирүче булса);

8) барлык урыннар милекчеләренең язма ризалыгы (Татарстан Республикасы, муниципаль берәмлек милкендәге урыннардан гайре);

9) урын йөкләнештә булганда йөкләнеш тотучының ризалыгы;

10) урыннан файдалану һәм (яки) биләү хокукын раслаучы документлар.

Регламентның 2.5.1 пунктының 7, 8 пунктчаларында күрсәтелгән документлар регламентның 2.5.3 пункты таләпләре нигезендә имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә тапшырылырга мөмкин.

Кабул итү комиссиясе тарафыннан күпфатирлы йортта бүлмәне үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турындагы актны рәсмиләштерүне сорап мөрәҗәгать ителгән очракта, регламентның 2.5.1 пунктының 4-9 пунктчаларында күрсәтелгән документлар таләп ителми.

2.5.2. Гариза һәм теркәлеп бирелә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

1) КФҮ аша кәгазь йөрткечләрдә һәм Регламентның 2.5.3. пункты таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә;

2) Республика порталы аша электрон рәвештә;

3) Органда шәхсән яисә кәгазь йөрткечтә почта элемтәсе ярдәмендә.

Гариза һәм теркәлә торган документлар почта элемтәсе аша җибәрелгәндә билгеләнгән тәртиптә таныклана.

2.5.3. Физик затлар һәм шәхси эшкуарлар гариза һәм кирәкле документларны республика порталы аша җибәргәндә гаризаны гади электрон култамга белән имзалыйлар.

Гади электрон имза алу өчен гариза бирүчегә ЕСИА да теркәлү (аутентификацияләү) процедурасын узарга, шулай ук хисап язмасын расларга кирәк.

Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән юридик затлар һәм юридик затлар вәкилләре гариза һәм кирәкле документларны республика порталы аша җибәргәндә гаризаны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалыйлар.

Гарызнамәне Республика порталы аша биргәндә гариза бирүче документларның электрон үрнәкләрен яисә әлеге пункт таләпләренә туры китереп, электрон култамга белән имзаланган документларны тапшыра.

Регламентның 2.5.1 пунктының 7 пунктчасында күрсәтелгән документ гариза бирүченең гади электрон имзасы яисә гариза бирүченең гаилә әгъзаларының гади электрон имзасы белән раслана.

Регламентның 2.5.1 пунктындагы 4-6, 8, 9 пунктчаларында күрсәтелгән документлар мондый документларны төзү һәм имзалау өчен вәкаләтле затларның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән раслана.

2.5.4. Мөрәҗәгать итүчедән таләп итү тыела:

1) муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшыру яисә гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыру яисә гамәлләр кылуны;

2) муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле һәм башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга мөрәҗәгать итү белән бәйле гамәлләрне, шул исәптән килештерүләрне гамәлгә ашыруны, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 9 маддәсенең 1 өлешендә күрсәтелгән исемлекләргә кертелгән мондый

хезмәтләр (кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр) күрсәтү нәтиҗәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрне һәм документларны алудан гайре;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны башта кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәткәндә баш тартканда документларның һәм мәгълүматның булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүматны тапшыруны, түбәндәге очраклардан гайре:

а) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза башта бирелгәннән соң муниципаль хезмәт күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актлар таләпләренең үзгәрүе;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризада һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны баштагы кабул итүдән баш тартканнан соң мөрәҗәгать итүче биргән документларда яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдә элек бирелгән документлар комплектына кертелмәгән хаталар булу;

в) документларның гамәлдә булу вакыты чыгу яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән башта баш тартканнан соң яки муниципаль хезмәт күрсәтүдә мәгълүмат үзгәрү;

г) Органның вазыйфаи затының (урындагы кешесенең), КФҮ хезмәткәренең муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне баштагы кире какканда яисә муниципаль хезмәт күрсәткәндә хаталы яки хокукка каршы гамәл кылуының (гамәл кылмавының) документаль расланган факты (билгеләре) ачыклану, әлеге муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу очрагында Орган җитәкчесе имзасы белән язма рәвештә мөрәҗәгать итүчегә хәбәрнамә ирештерелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә;

4) электрон рәвешләре 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсендәге 1 өлешенең 7.2 пункты нигезендә элек расланган документларны һәм мәгълүматны кәгазь йөрткечтә тапшыру, мондый документларга тамга салу яисә аларны алу дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан гайре.

### 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә зарур булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хаклы документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма.

2.6.1. Ведомствоара хезмәттәшлек (багланышлар) кысаларында алына:

1) күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматларны үз эченә алган) мәгълүматлар – Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте (Росреестр);

2) күчерелә торган урынның аның техник тасвирламасы белән планы яисә күпфатирлы йортта үзгәртеп корыла торган һәм (яисә) яңадан планлаштырыла торган урынның техник паспорты – Росреестр;

3) юридик зат мөрәҗәгать иткән очракта Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан Федераль салым хезмәтеннән мәгълүматлар соратып алына;

4) индивидуаль эшкуар мөрәҗәгать иткән очракта, Федераль салым хезмәтеннән Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар соратып алына;

5) Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрнең) бердәм дәүләт реестрыннан өземтә – мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты;

6) күпфатирлы йортта бүлмәне (торак урынны) үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру мөмкинлеге турында архитектура, тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен саклау органы бәяләмәсе, әгәр ул урнашкан бина яки йорт архитектура, тарих һәм мәдәният һәйкәле булып торса – шул очракта, әгәр күпфатирлы йорт федераль, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты булса, ул мәдәни мирас объекты булып санала – мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты; әгәр күпфатирлы йорт җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты булса – муниципаль район (шәһәр округы) Башкарма комитеты;

7) өлешләп төзүдә катнашу шартнамәсе буенча төзелгән яңа йортларда эшләр башкарганда, объектны файдалануга тапшыруга рөхсәтнамә – муниципаль район Башкарма комитеты;

8) социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирелгән очракта, социаль наем шартнамәсе турында мәгълүматлар – Орган;

9) гариза законлы вәкил тарафыннан бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле вәкаләтләрен раслый торган документ (Россия Федерациясе гражданлык хәле актларын теркәү органнары тарафыннан бирелгән туу турында таныклык яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә опека һәм попечительлек органнары тарафыннан бирелгән документ өлешендә) – гражданлык хәле актларын теркәүнең бердәм дәүләт реестры яки социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы;

10) ышанычнамәне бирү һәм аның эчтәлеге турында мәгълүматлар - нотариатның бердәм мәгълүмат системасы;

11) Татарстан Республикасы, муниципаль берәмлек милкендә булган күпфатирлы йортта урынга хокук иясенең ризалыгы – Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары.

2.6.2. Мөрәҗәгать итүче Регламентның 2.6.1 пунктының 1-9 пунктчаларында күрсәтелгән документларны (мәгълүматларны) мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затларның көчәйтелгән квалификацияле култамгасы белән таныкланган электрон документлар рәвешендә гаризаны Республика порталы аша биргәндә яисә КФҮ тә кәгазь йөрткечтә тапшырырга хокуклы.

2.6.3. Күрсәтелгән дәүләт хакимияте органнары, Органның структур бүлекчәләре тарафыннан документлар һәм белешмәләрне тапшырмау (вакытында тапшырмау) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.6.4. Күрсәтелгән органнарның вазыйфаи заты һәм (яисә) хезмәткәренә алар карамагында булган документларны яисә мәгълүматларны тапшырмаган (үз вакытында тапшырмаган) өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә административ, дисциплинар яки башка җаваплылык каралырга тиеш.

2.6.5. Гариза бирүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар карамагындагы документларны һәм мәгълүматларны, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәткән өчен гариза бирүче тарафыннан түләү кертүне раслый торган мәгълүматларны таләп итү тыела.

Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалар карамагында булган мәгълүматларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырмау мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

### 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту (асылы буенча карамыйча документларны кире кайтару) өчен нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

9) регламентның 2.5.1 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөстәкыйль тапшырылырга тиеш булган документларны тапшырмау яисә каршылыклы мәгълүматлары булган документларны тапшыру;

10) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратылган законлы вәкилләр турында мәгълүматларның расланмавы, вәкаләтле булмаган зат исеменнән гариза (гарызнамә) бирелү;

11) документларны тиешле булмаган органга тапшыру;

12) дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы мәгълүматлар, килешенмәгән төзәтүләр, җитди зарарланулар булган документларны бирү, алар эчтәлекне бертөрле генә аңлатырга мөмкинлек бирми, үз көчләрен югалткан документлар тапшыру;

13)
регламент нигезендә муниципаль хезмәт алучы булмаган затның муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүе;

14) г
ризаның электрон формасында мәҗбүри кырларны дөрес тутырмау, гаризаның электрон формасында һәм тапшырылган документларда каршылыклы мәгълүматлар булу;

15) г
ариза (гарызнамә) һәм электрон рәвештәге башка документлар гамәлдәге законнарны бозып электрон култамга белән имзаланган;

16) э лектрон документлар аларны бирү форматларына куелган таләпләргә туры килми һәм (яисә) укылмый.

2.7.2. Муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге төгәл булып тора.

2.7.3. Гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү вакытында да, Органның җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны (мәгълүматларны) ведомствоара мәгълүмати багланышны файдаланып алганнан соң да, гаризаны теркәгәннән соң 7 эш көненнән дә артмаган срокта кабул ителергә мөмкин.

2.7.4. Муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, Регламентка 5 нче кушымтада билгеләнгән форма нигезендә рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә Органның вәкаләтле вазыйфаи заты (Орган) тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон култамга белән имзалана һәм гариза бирүчегә республика порталының шәхси кабинетына һәм (яки) КФҮ кә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне җибәрелә.

2.7.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда, Республика порталында бастырылган муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

### 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр күздә тотылмый.

2.8.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге:

1) мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшыру аның бурычы булган документлар тапшырылмаган;

1.1) килештерүне гамәлгә ашыручы органга дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының яисә дәүләт хакимияте органына яисә җирле үзидарә органына караган оешманың ведомствоара гарызнамәгә Россия Федерациясе Торак кодексының 26 маддәсендәге 2.1 өлеше нигезендә урынны үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру өчен кирәкле документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавын раслаучы җавапның килеп ирешүе, әгәр тиешле документ мөрәҗәгать итүче тарафыннан үз инициативасы белән күрсәтелмәгән булса;

2) документларны тиешле булмаган органга тапшыру;

3) бинаны (бүлмәне, урынны) үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру проектының закон таләпләренә туры килмәве;

4) күпфатирлы йортта бинаны (бүлмәне, урынны) үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү турында карарның шартларын үтәмәү шул

исәптән башкарылган ремонт-төзелеш эшләренең үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру проектына туры килмәве;

5) мөрәҗәгать итүче тарафыннан башкарылган ремонт-төзелеш эшләрен кабул итү өчен күпфатирлы йорттагы торак урынга билгеләнгән көн һәм вакыт эчендә керүгә рөхсәт итмәү;

6) мөрәҗәгать итүче инициативасы буенча муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны кире алу.

2.8.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге төгәл булып тора.

2.8.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турындагы карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, Регламентка 2 нче кушымтада билгеләнгән форма нигезендә рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә Органның вәкаләтле вазыйфаи заты (Орган) тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон култамга белән имзалана һәм мөрәҗәгать итүчегә Республика порталының шәхси кабинетына һәм (яисә) КФҮ кә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне җибәрелә.

2.8.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза Бердәм порталда, Республика порталында игълан ителгән (бастырылган) муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту тыела.

### 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алынучы дәүләт пошлинасы һәм бүтән түләүнең тәртибе, күләме һәм түләтү нигезе

Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә.

### 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында мәгълүматлар

Күпфатирлы йортта торак урынны үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру проектын билгеләнгән тәртиптә махсуслаштырылган оешмалар тарафыннан эшләү һәм рәсмиләштерү.

### 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтүгә түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп

Күпфатирлы йортта торак урынны (бүлмәне) үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру проектын эшләү һәм рәсмиләштерү өчен түләү күләме һәм тәртибе яклар тарафыннан мөрәҗәгать итүче һәм күпфатирлы йортта торак урынны (бүлмәне) үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру проектын эшләүче (махсуслаштырылган оешма) арасында төзелгән шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла.

### 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамә биргәндә, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәт

күрсәтелгәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты

2.12.1. Муниципаль хезмәт алуга гариза биргәндә көтү вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.12.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең гарызнамәсен һәм хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтне теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон рәвештә

2.13.1. Гариза биргән көнне КФҮкә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүчегә гаризаның җибәрелүен раслаучы теркәлү номеры һәм электрон гаризаны бирү датасы белән КФҮ АМС ннан раслама бирелә.

2.13.2. Гаризаны Республика порталы ярдәмендә юллаганда мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Республика порталының шәхси кабинетында һәм электрон почта аша, гаризаның теркәлү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелеп, гаризаның җибәрелүен раслый торган хәбәрнамә ала.

2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, көтү залына, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамәләрне тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре һәм һәр муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге булган мәгълүмат стендларына карата, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыру һәм бизәүгә, шул исәптән әлеге объектларга инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвалидлар өчен үтү (керү) мөмкинлеген тәэмин итүгә таләпләр

2.14.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебельләр, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына каршылыксыз керүе (үтә алуы) тәэмин ителә (бина-бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм алар эчендә күченү, хәрәкәт итү).

Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

2.14.2. Инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү (үтү) максатларында түбәндәгеләр тәэмин ителә:

6) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләренең ныклы тайпылышлары булган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

7) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм алардан чыгу, транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

8) инвалидларның хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөрткечләрне аларның тереклек эшчәнлегенең чикләнгәнлеген исәпкә алып тиешенчә урнаштыру;

9) инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук өсьязуларны, билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайль рельеф-нокталы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау;

10) сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчегә рөхсәт итү;

6) озатучы-этне махсус укыту-өйрәтүне раслаучы һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының “Озатучы-этне махсус укытуны раслый торган документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында” 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән билгеләнгән рәвештә һәм тәртиптә бирелгән документы булганда рөхсәт итү.

2.14.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектлардан һәм муниципаль хезмәт күрсәткәндә кулланыла торган Регламентның 2.14.2 пунктының 1 – 4 пунктчаларында күрсәтелгән чаралардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр, алар 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизацияләнгән объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

2.15. Муниципаль хезмәтнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән муниципаль хезмәт күрсәткәндә үзара багланышлары саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләрен кулланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы күләмдә), җирле үзидарәнең башкарма-боеру органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә муниципаль хезмәт алу мөмкинлеге яисә мөмкин түгеллеге, мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча (экстерриториаль принцип), 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 маддәсендә каралган күпфункцияле үзәкләрдә берничә дәүләт һәм (яисә) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамә (комплекслы гарызнамә) ярдәмендә

2.15.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкинлеге (доступность) күрсәткечләре булып тора:

документлар кабул итү, бирү алып барыла торган бинаның җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итүне гамәлгә ашыра торган бүлмәләрнең кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, муниципаль районның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында муниципаль хезмәтне күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

инвалидларга башкалар белән бер үк дәрәҗәдә хезмәтләр алырга комачаулаучы киртәләрне җиңәргә ярдәм итү.

2.15.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләр:

1) документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;

2) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу срогын үтәү;

3) орган хезмәткәрләре тарафыннан Регламентны бозуга карата нигезле шикаятьләр булмау;

4) мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән багланышлары саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең КФҮ хезмәткәрләре белән багланышы барлык кирәкле документлар белән гариза биргәндә бер тапкыр гамәлгә ашырыла;

бер тапкыр Органда яки КФҮ тә электрон документның нөсхә рәвешендә кәгазь йөрткечтәге муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу кирәк булган очракта.

Муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бер мәртәбә багланышының дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.

Мөрәҗәгать итүче күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын Республика порталы, терминал җайланмалары аша бәяләргә хокуклы.

2.15.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүматны мөрәҗәгать итүче Бердәм порталда яисә Республика порталында шәхси кабинетта, Органда, КФҮ тә алырга мөмкин.

2.15.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча яшәү урынына яисә фактта яшәү (булу) урынына бәйсез рәвештә Татарстан Республикасы территориясендә экстерриториаль принцип буенча.теләсә кайсы КФҮ тә гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәтне комплекслы гарызнамә составында алырга хокуклы.

## 2.16. Башка таләпләр, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча (әгәр муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә икән) муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алып, һәм электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре

2.16.1. Муниципаль хезмәт электрон рәвештә күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хаклы:

а) бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон рәвешләре 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсендәге 1 өлешенең 7.2 пункты

нигезендә Республика порталыннан файдаланып таныкланган документлар һәм мәгълүмат бирүгә;

в) электрон рәвештә бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында мәгълүматлар алырга;

г) муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;

д) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә алырга;

е) Республика порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә кылынган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауларга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итүче федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Органның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирергә.

2.16.2. Гаризаны формалаштыру Республика порталында гаризаның электрон рәвешен тутыру юлы белән нинди дә булса башка рәвештә гариза бирү зарурлыгыннан башка гамәлгә ашырыла.

2.16.3. Мөрәҗәгать итүчеләрнең КФҮ кә кабул итүгә язылуы (алга таба – язылу) Республика порталы, КФҮнең контакт-үзәге телефоны аша башкарыла.

Мөрәҗәгать итүчегә кабул итү өчен теләсә нинди буш вакытка күпфункцияле үзәкнең кабул итү графигының билгеләнгән чикләрендә язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу бу датага кадәр бер тәүлек кала төгәлләнә.

Республика порталы ярдәмендә алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә система тарафыннан соратыла торган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилия, исем, атасының исемен (булган сурәттә);

телефон номерын;

электрон почта адресын (теләк буенча);

теләгән кабул итү датасын һәм вакытын.

Мөрәҗәгать итүче алдан язылу вакытында хәбәр иткән мәгълүматларның шәхси кабул итү вакытында гариза бирүче биргән документлардагы мәглүматларга туры килмәве очрагында алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда мөрәҗәгать итүчегә талон-раслауның распечаткасын алу мөмкинлеге бирелә.

Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын хәбәр итсә, күрсәтелгән адреска, кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда гариза бирүчегә мәҗбүри рәвештә, билгеләнгән кабул итү вакытына килмәгән очракта кабул итү вакытыннан 15 минут узгач, алдан язылу гамәлдән чыгарылуы турында хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүчедән, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан гайре, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен броньларга кирәк булган вакытлыча интервал дәвамлылыгын исәпләү өчен зарури мәгълүматлар бирүдән башка гамәлләр кылуны таләп итү тыела.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Описание последовательности действий при предоставлении муниципальной услуги

3.1. Муниципаль хезмәтләр күрсәткәндәге гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә (гариза бирүчегә) консультация (мәслихәт) бирү;

2) мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар комплектын (тупламын) кабул итү һәм карау;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара гарызнамәләр җибәрү;

4) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;

5) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

3.2. Гариза бирүче (мөрәҗәгать итүче) белән консультацияләр үткәрү (мәслихәт бирү)

3.2.1. Административ процедураны үтәүне башлауның нигезе – мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгате.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы урындагы кеше (хезмәткәр) булып тора:

-мөрәҗәгать итүче КФҮ кә мөрәҗәгать иткәндә – КФҮ хезмәткәре;

- мөрәҗәгать итүченең Башкарма комитетка мөрәҗәгатендә әйдәп баручы белгеч (алга таба – консультация бирү өчен җаваплы вазыйфаи зат).

3.2.2. Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында консультация сорап КФҮ тә шәхсән һәм телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә консультация бирә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тапшырыла торган документациянең составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча.

Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүматны КФҮ нең http://mfc16.tatarstan.ru сайтыннан ирекле файдалану юлы белән алырга мөмкин.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелә торган документациянең составы, формасы һәм муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча консультация.

3.2.3. Мөрәҗәгать итүче телефон һәм электрон почта аша Башкарма комитетка мөрәҗәгать итәргә, шулай ук Республика порталында, Органның муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында сайтында консультация алырга хокуклы, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тапшырыла торган документациянең составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча.

Консультация бирү өчен җаваплы вазыйфаи зат Регламентның 1.3.4 пункты таләпләре нигезендә мөрәҗәгать итүчегә мәгълүмат бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать кергән көннән алып өч эш көне эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелә торган документациянең составы, формасы һәм муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча консультацияләр.

## 3.3. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар комплектын (тупламын) кабул итү һәм карау

3.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документларны КФҮ яки КФҮнең ераклашкан эш урыны аша кабул итү.

3.3.1.1. Мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамә белән КФҮкә мөрәҗәгать итә һәм Регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны тапшыра.

3.3.1.2. Гаризаларны кабул итүче КФҮ хезмәткәре:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый;

мөрәҗәгать предметын билгели;

документлар бирүче затның вәкаләтләрен тикшерә;

документларның Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен тикшерә;

КФҮнең АМС на гаризаның электрон формасын тутыра;

Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар кәгазь йөрткечтә тапшырылганда, тапшырылган документларны сканерлауны гамәлгә ашыра;

КФҮ нең АМС нан гаризаның распечаткасын ала;

мөрәҗәгать итүчегә тикшерүгә һәм кул куюга тапшыра;

имза салганнан соң кул куелган гаризаны КФҮ нең АМС нда сканерлый;

электрон формада яки электрон рәвештәге сканерланган тәкъдим ителгән документларны КФҮ нең АМС на кертә (йөкли), электрон дело (эш) формалаштыра;

имзаланган гаризаны һәм кәгазь документларның төп нөсхәләрен кире кайтара;

мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү хакындараслама бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: җибәрергә әзер гариза һәм документлар пакеты.

3.3.1.3. КФҮ хезмәткәре мөрәҗәгать итүчедән кабул ителгән документлар пакетын (электрон эшләр пакетлары составында) КФҮ нең структур бүлекчәсенә мөрәҗәгать иткән көннән бер эш көне эчендә электрон формада Башкарма комитетка җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: электрон бигланыш системасы ярдәмендә Башкарма комитетка җибәрелгән гариза һәм документлар пакеты (электрон эш).

3.3.2. Республика порталы аша муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәтү өчен документлар кабул итү.

3.3.2.1. Гаризаны Республика порталы аша электрон рәвештә бирү өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

авторизацияне башкара;

электрон гариза формасын (рәвешен) ача;

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган мәгълүматларны үз эченә алган электрон гариза рәвешен тутыра;

документларны электрон формада яисә электрон документлар образларын электрон гариза формасына беркетә (зарурлык булганда);

электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтүнең шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамганы билгели);

хәбәр ителгән мәгълүматларның дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамганы билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасында тиешле төймәгә баса);

электрон гариза 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә (гади электрон култамга һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон култамга белән) имзалана;

электрон гаризаны җибәрү турында хәбәрнамә ала.

Әлеге пункт белән билгеләнгән административ процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә Башкарма комитетка юнәлтелгән электрон эш тора.

3.3.3. Орган тарафыннан документлар тупламын карау.

3.3.3.1. Административ процедураны үтәүне башлауга нигез булып муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм башка документлар килеп ирешү тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы урындагы кеше (хезмәткәр) – эйдәүче белгеч (алга таба – документларны кабул итү өчен җаваплы урындагы кеше).

Документлар кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат, документлар каралуга кергәннән соң:

Гаризага эш номенклатурасы нигезендә номер һәм "Документларны тикшерү" статусы бирелә, бу Республика порталының шәхси кабинетында чагыла;

килеп ирешкән электрон эшләрне, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан кушымта итеп бирелгән электрон формадагы документларны һәм документларның электрон рәвешләрен (образларын) өйрәнә;

документларның комплектлылыгын (тупланганлыгын), документларның электрон образларының (рәвешләренең) укылышын тикшерә;

Бердәм порталга мөрәҗәгать итү юлы белән электрон култамганың чын (дөрес) булу шартларының үтәлүен тикшерә (гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон култамга белән имзаланган электрон документлар рәвешләре тапшырылган очракта).

Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булганда, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын әзерли.

Көчәйтелгән квалификацияле электрон култамганы тикшерү нәтиҗәсендә аның чын булу шартларын үтәмәү ачыкланган очракта, баш тарту турындагы карар проектында аны кабул итүгә нигез булган 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 маддәсе пунктлары булырга тиеш.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проекты, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп (әгәр дә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуның нигезләре мондый документларга карата билгеләнгән таләпләрне бозу белән бәйле булса, документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрдә дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы белешмәләр булган, билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән алдан тәкъдим ителмәгән документлар (мәгълүмат, белешмәләр) исеме турында мәгълүмат булырга тиеш), 5 нче кушымтага ярашлы рәвеш буенча рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә электрон документ әйләнеше системасы аша килештерүгә җибәрелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проектын килештерү Регламентның 3.5.5 пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат, гариза кергән көннән алып бер эш көне эчендә гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә гаризаның теркәү номеры, гаризаны алу датасы, файлларның исемнәре, аңа тәкъдим ителгән документлар исемлеге, муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу датасы булган гариза килеп ирешү турында хәбәрнамә җибәрә.

3.3.3.2. Регламентның 3.3.3.1 пунктында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

3.3.3.3. Регламентның 3.3.3 пункты белән билгеләнә торган процедуралар гариза карауга кергән көннән бер эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: карауга кабул ителгән гариза яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты.

## 3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара гарызнамәләр җибәрү

3.4.1. Административ процедураны үтәүне башлау өчен нигез булып мөрәҗәгать итүчедән алынган документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи заттан (хезмәткәрдән) административ процедураны башкаруга вәкаләтле вазыйфаи затның (хезмәткәрнең) алуы тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы урындагы кеше (хезмәткәр) булып җитәкче урынбасары тора (алга таба – ведомствоара гарызнамәләр җибәрү өчен җаваплы урындагы кеше).

Ведомствоара гарызнамәләр җибәрү өчен җаваплы урындагы кеше ведомствоара электрон багланышлар системасы аша (техник мөмкинлек булмаганда – башка ысуллар белән) электрон рәвештә Регламентның 2.6. пунктында каралган документларны һәм мәгълүматларны тапшыруга гарызнамәләр формалаштыра һәм җибәрә.

Кабул итү комиссиясе тарафыннан күпфатирлы йортта урынны үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турында актны рәсмиләштерүне сорап мөрәҗәгать ителгән очракта ведомствоара гарызнамәләр җибәрү гамәлгә ашырылмый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар карау өчен гариза кабул ителгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: хакимият органнарына һәм (яки) хакимият органнарына буйсынган оешмаларга юлланган гарызнамәләр.

3.4.2. Белешмәләр белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре, ведомствоара электрон багланыш системасы аша кергән гарызнамәләр нигезендә, соратыла торган документларны (мәгълүматны) тапшыралар яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмау турында хәбәрнамәләр юллыйлар (алга таба – кире кагу турында хәбәрнамә).

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнгән процедуралар түбәндәге срокларда башкарыла:

Росреестр белгечләре тарафыннан җибәрелә торган документлар (мәгълүматлар) буенча өч эш көненнән артык түгел;

җирле үзидарә органнары һәм аларга буйсынучы оешмалар карамагындагы документлар (мәгълүматлар) буенча - өч эш көненнән артык түгел;

башка тәэмин итүчеләр буенча - ведомствоара гарызнамә документ һәм мәгълүмат бирүче органга яки оешмага кергән көннән алып биш көн эчендә, әгәр ведомствоара гарызнамәгә җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актларында һәм

федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында билгеләнмәсә.

Результатами выполнения административных процедур являются: документы (сведения), необходимые для предоставления муниципальной услуги, либо уведомление об отказе, направленные должностному лицу, ответственному за направление межведомственных запросов.

3.4.3. Ведомствоара гарызнамәләр җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле ведомствоара электрон багланышлар системасы аша соратыла торган документларны (мәгълүматларны) яки документ һәм (яки) мәгълүмат булмаганда баш тарту турында хәбәрнамә ала;

Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булганда, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын әзерли.

әлеге мәгълүмат белән тәэмин итүчеләрдән регламентның 2.6.1 пунктының 1, 2, 4 пунктларында каралган документлар һәм (яки) мәгълүмат булмаганда баш тарту турында хәбәрнамә алган очракта, мөрәҗәгать итүчедән хәбәрнамәне республика порталында һәм (яки) КФҮтә шәхсән кабинетка җибәрү юлы белән кирәкле документларны соратып ала. Мөрәҗәгать итүче документларны хәбәрнамә җибәргәннән соң 15 эш көне эчендә тапшырырга хокуклы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проекты, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп (әгәр дә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуның нигезләре мондый документларга карата билгеләнгән таләпләрне бозу белән бәйле булса, документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрдә дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы белешмәләр булган, билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән алдан тәкъдим ителмәгән документлар (мәгълүмат, белешмәләр) исеме турында мәгълүмат булырга тиеш) Регламентка 5 нче кушымта нигезендәге рәвеш буенча рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә электрон документ әйләнеше системасы аша килештерүгә җибәрелә.

Регламентның 2.8.2 пунктында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрне ачыклаганда, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын әзерли.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проектын килештерү Регламентның 3.5.5 пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларның үтәлеш нәтиҗәләре булып тора: документларны тапшыру кирәклеге турында хәбәрнамә, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар комплекты (мәгълүматлар).

3.4.4. Регламентның 3.4.1, 3.4.3 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын, шул исәптән гаризаны

Регламентның 2.13 пункты нигезендә теркәгән мизгелдән файдаланып, автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

3.4.5. Регламентның 3.4 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны үтәүнең максималь срогы 5 эш көне тәшкил итә, мөрәҗәгать итүчегә документлар тапшыру кирәклеге турында хәбәрнамә юлланган очракта - 20 эш көне.

3.5. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү

3.5.1. Административ процедураны башкару өчен нигез булып, ведомствоара гарызнамәләр җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи заттан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның (мәгълүматларның) килеп ирешүе тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы урындагы кеше – җитәкче урынбасары (алга таба – муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы урындагы кеше).

3.5.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

ведомствоара комиссия тарафыннан кергән документлар комплектын билгеләнгән тәртиптә карау кирәклеге турында карар кабул итә;

комиссия үткәргән очракта бәяләмә әзерли һәм документларның формалаштырылган комплектын ведомствоара комиссиягә электрон документлар әйләнеше системасы ярдәмендә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән административ процедуралар бер эш көне дәвамында башкарыла.

3.5.3. Уңай карар кабул итү турындагы тәкъдимнәр яисә, тискәре карар кабул итү сәбәпләрен күрсәтеп, 2.8.2 пунктында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр комиссия әгъзалары һәм рәисе тарафыннан документларның төзелгән комплектына килештерү кәгазендә тапшырыла.

Административ процедура биш эш көненнән артмаган вакытта башкарыла, шул исәптән күпфатирлы йортта урынны тәгәлләнгән үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турында акт рәсмиләштерелгән очракта.

3.5.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

регламентның 2.8.2 пунктында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр ачыкланганда, ә ведомствоара комиссия тарафыннан карар кабул ителгән очракта, ведомствоара комиссия карарын исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын әзерли;

регламентның 2.8.2 пунктында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны карау нәтиҗәләре буенча, күпфатирлы йортта урыннарны үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү турында карар проектын яки күпфатирлы йорттагы урынны тәгәлләнгән үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турында акт проекты әзерли;

әзерләнгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе проектын билгеләнгән тәртиптә электрон документ әйләнеше системасы аша килештерүгә җибәрә.

Административ процедуралар бер эш көне эчендә башкарыла.

3.5.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын, күпфатирлы йорттагы урыннарны үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү турындагы яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын, күпфатирлы йорттагы урынны төгәлләнгән үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турында акт проектын (алга таба – проектлар) килештерү һәм имзалау муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе, Орган җитәкчесе урынбасары, Орган җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Искәртүләре булган карарларның әзерләнгән проектлары муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы затка кире кайтарыла.

Административ процедуралар ике эш көне дәвамында башкарыла.

Административ процедураларның үтәлеше нәтиҗәләре булып тора: муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар, күпфатирлы йорттагы урыннарны үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү турындагы яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты, күпфатирлы йорттагы урынны төгәлләнгән үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турында акт.

3.5.6. Регламентның 3.5.2 – 3.5.5 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

3.5.7. Административ регламентның 3.5 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны үтәүнең максималь срогы тугыз эш көне тәшкил итә.

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү (җибәрү)

3.6.1. Административ процедураны башкару өчен нигез булып административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне раслаучы документ алу тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы урындагы кеше булып җитәкче урынбасары (алга таба - документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы урындагы кеше) тора.

Документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы урындагы кеше:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасы документациясен алып бару системасына һәм (яки) шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү буенча мәгълүмат системасына муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүматларны теркәүне һәм кертүне тәэмин итә;

мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән ысул белән, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында һәм Органда яки КФҮ тә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, автомат рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Органның вәкаләтле вазыйфаи заты (Орган) тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне (бирүдән баш тартуны) раслаучы документка кул куелган көнне үтәлә.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: мәгълүмат системаларында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыру, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре һәм аны алу ысуллары турында хәбәрнамә ирештерү.

3.6.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү) тәртибе:

3.6.2.1. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт нәтиҗәсен сорап КФҮ кә мөрәҗәгать иткәндә, КФҮ хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә электрон документның кәгазь йөрткечтәге нөсхәсе рәвешендә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирә. Мөрәҗәгать итүче таләбе буенча аңа электрон документның кәгазь йөрткечтәге нөсхәсе белән бергә аны салдырыла торган йөрткечкә яздыру юлы белән электрон документның нөсхәсе бирелә яки мөрәҗәгать итүче адресына электрон почта аша электрон документның нөсхәсе җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән административ процедуралар мөрәҗәгать итүченең КФҮ регламентында билгеләнгән срокларда килү көнендә чиратлылык тәртибендә башкарыла.

3.6.2.2. Мөрәҗәгать итүче Республика порталы аша муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен сорап мөрәҗәгать иткәндә, мөрәҗәгать итүчегә шәхси кабинетка автомат рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган, Органның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон култамгасы белән имзаланган документның электрон үрнәге җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслаучы документка Органның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан кул куелган көнне башкарыла.

Административ процедураларның үтәлеше нәтиҗәләре булып тора: гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүне раслаучы документның Республика порталыннан файдаланып җибәрү (бирү) (шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту).

## 3.7. Техник хаталарны төзәтү

3.7.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып торган документта техник хата барлыгы беленгән очракта гариза бирүче (мөрәҗәгать итүче) Органга җибәрә:

техник хатаны төзәтү турында гариза (әлеге административ регламентка 6 нчы кушымта);

муниципаль хезмәт нәтиҗәсе буларак гариза бирүчегә бирелгән техник хаталы документ;

техник хата булуны дәлилләүче юридик көчкә ия булган документлар.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән мәгълүматларда техник хатаны төзәтү турында гаризаны мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) почта аркылы (шул исәптән электрон почтаны кулланып) яки Республика порталы яисә КФҮ аша бирә.

3.7.2 Документлар кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, кушымта итеп теркәлгән документлар белән гаризаны терки һәм аларны документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гаризаны теркәү датасыннан бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка карауга юнәлтелгән кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.7.3. Документлар эшкәртүгә җаваплы вазыйфаи зат документларны карый һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм төзәтелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) техник хата булган документның төп нөсхәсен алып калып шәхсән кул куйдырып бирә яки гариза бирүче адресына почта аша (электрон почта ярдәмендә) Башкарма комитетка техник хата булган документның төп нөсхәсен тапшырганда документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хатаны ачыклаганнан яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң ике эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүгә контроль тәртибе һәм формалары

4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан регламент нигезләмәләрен һәм муниципаль хезмәт күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларны үтәүгә һәм башкаруга, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүгә агымдагы контрольне гамәлгә ашыру тәртибе

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгына һәм сыйфатына контроль мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуын ачыклау һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлүенә тикшерүләр уздыруны, җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешенә контроль формалары булып торалар:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү.

2) делопроизводствоны алып баруны билгеләнгән тәртиптә уздырылучы тикшерүләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларын үтәүгә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Агымдагы контроль максатларында электрон мәгълүматлар базасында булган белешмәләр, хезмәт урыны корреспонденциясе, административ процедураларны үтәүче вазыйфаи затларның телдән һәм язма мәгълүматы,

тиешле документларны исәпкә алу журналлары һәм башка мәгълүматлар файдаланыла.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм җирле үзидарә органы җитәкчесенә карарлар кабул иткәндә гамәлләрнең башкарылуын тикшереп тору өчен муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр бирелә.

Административ процедураларның срокларын, эзлеклелеген һәм эчтәлеген бозу очраклары һәм сәбәпләре турында вазыйфаи затлар кичекмәстән муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенә хәбәр итәләр, шулай ук бозуларны бетерү буенча ашыгыч чаралар күрәләр.

Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контроль муниципаль хезмәт күрсәтү эшен оештыруга җаваплы җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары, муниципаль хезмәт күрсәтү эшен оештыручы бүлек башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге җирле үзидарә органының структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

### 4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфаты буенча планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне гамәлгә ашыру тәртибе һәм периодиклыгы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарә органы эшенең ярты еллык яисә еллык планнары нигезендә гамәлгә ашырылырга) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәт күрсәтүгә (комплекслы тикшерүләргә) бәйле барлык мәсьәләләр яисә мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча каралырга мөмкин.

### 4.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында үзләре тарафыннан кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен муниципаль хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затларының җаваплылыгы

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылган очракта гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

Җирле үзидарә органы җитәкчесе гариза-мөрәҗәгатьләрне вакытында тикшермәгән өчен җаваплы.

Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (җитәкче урынбасары) Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яисә) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә торган (гамәлгә ашырыла торган) карар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр законнарда билгеләнгән тәртиптә җаваплы булалар.

4.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне тикшереп тору тәртибенә һәм рәвешләренә таләпләрне сыйфатлаучы нигезләмәләр, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан да.

Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне тикшереп тору (контроль) муниципаль хезмәт күрсәткәндә җирле үзидарә органы эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

**5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе**

5.1. Муниципаль хезмәт алучылар муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган хезмәткәренең, җитәкчесенең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр тәртиптә шикаять бирү хокукына ия.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 маддәсендә күрсәтелгән гарызнамәне, муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гарызнамәне теркәү срокларын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, аның хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда тапшыру яисә гамәлгә ашыру каралмаган документларны яки мәгълүматны яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гамәлләр кылуны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль

хокукый актларда каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда баш тарту нигезләре күздә тотылмаган булуга карамастан муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, аның хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин;

6) муниципаль хезмәт күрсәтүдә гариза бирүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, муниципаль район норматив хокукый актларында күздә тотылмаган түләүне таләп итү;

7) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмалар яисә аларның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хата һәм ялгышларны төзәтүне кире кагуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, аның хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирүнең срогын яисә тәртибен бозу;

9) федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары, муниципаль районның норматив хокукый актларында муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатуга нигезләр күздә тотылмаган булуга карамастан, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату (туктатып тору);

Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, аның хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин;

10) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны баштагы кабул итүдәге кире кагуда юклыгы һәм (яки) дөрес

түгеллеге күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүматны муниципаль хезмәт күрсәтүдә, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ Федераль законның 7 маддәсе 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан гайре, мөрәҗәгать итүчедән таләп итү.

Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, аның хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин.

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазь йөрткечтә, электрон рәвештә муниципаль хезмәтне күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә яки күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы тиешле дәүләт хакимияте органына (алга таба – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы), шулай ук 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларга тапшырыла. Муниципаль хезмәтне күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр югарырак органга (ул булган очракта) бирелә яки ул булмаган очракта турыдан-туры муниципаль хезмәтне күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала. Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр шушы күпфункцияле үзәк җитәкчесенә бирелә. Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәкне оештыручыга яисә Татарстан Республикасының норматив хокукый акты белән вәкаләтле вазыйфаи затка тапшырыла. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр әлеге оешмалар җитәкчеләренә бирелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аркылы, күпфункцияле үзәк аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайтыннан, Бердәм порталдан яисә республика порталыннан, судка кадәр шикаять бирү мәгълүмат системасыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәкнең, Бердәм порталның яисә Республика порталының рәсми сайтыннан, судка шикаять бирүнең мәгълүмат системасы аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1 өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, әлеге оешмаларның, Бердәм порталның яисә Республика порталының рәсми

сайтларыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесе һәм (яисә) хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның җитәкчеләре һәм (яисә) хезмәткәрләренең исемнәрен (аталышларын);

2) мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), гариза бирүченең – физик затның яшәү урыны турында мәгълүматлар, гариза бирүченең – юридик затның урнашу урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (булган очракта) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы (булганда);

3) муниципаль хезмәтне күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүче алар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешми торган дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аның дәлилләрен раслаучы документлар (булганда) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.4. Килеп ирешкән шикаять кергән көннән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш.

5.5 Муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларга яисә югарырак органга (ул булганда) кергән шикаять теркәлгән көннән алып унбиш эш көне эчендә каралырга тиеш, ә муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларга карата шикаять белдерелгән очракта мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдә яки җибәрелгән хата һәм ялгышларны төзәтүдә яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылган очракта – аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.6.Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның кайсы да булса берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда

җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә түләтү Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартырга.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.7. Шикаятьнең канәгатьләндерелергә тиешле дип танылу очрагында мөрәҗәгать итүчегә шикаятьне карау нәтиҗәләре турындагы җавапта муниципаль хезмәт күрсәткәндә беленгән бозуларны кичекмәстән бетерү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмалар тарафыннан тормышка ашырылучы гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук күрсәтелгән уңайсызлыклар өчен кичерү сорала һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне алу максатларында гариза бирүчегә кылу зарур булган алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаятьнең канәгатьләндерелергә тиешле түгел дип табылу очрагында мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре хакында дәлилле аңлатмалар бирелә, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат китерелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре табылу очрагында шикаятьләрне карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрәләр.

Күпфатирлы йортта бүлмәләрне (урыннарны) үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү һәм күпфатирлы йортта бүлмәләрне төгәлләнгән үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турындагы актны кабул итү комиссиясе тарафыннан рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына кушымта №1

**Торак урынны үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү турында карар кабул итүне раслаучы документ рәвеше**

(Килештерүне гамәлгә ашыручы орган бланкы)

Торак урынны үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү турында
КАРАР

________________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүче :физик затлар өчен - фамилиясе, исеме, атасының исеме, юридик затлар өчен – тулы аталышы)
мөрәҗәгать итүенә бәйле рәвештә аның ________________________________адресы буенча урнашкан, биләгән (анык булган) торак урыннарны үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан
(кирәк түгелен сызарга) (кирәк түгелен сызарга)
планлаштыру нияте белән ________________________________________________
(үзгәртеп корыла һәм (яки) яңадан планлаштырыла торган урынга хокук билгели торган документ төре һәм реквизитлары)
______________нигезендә тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча карар кабул ителде:

1.Торак урыннарны ________________________________________________________
(үзгәртеп коруга , яңадан планлаштыруга, үзгәртеп коруга һәм яңадан планлаштыруга – тиешлесен күрсәтергә)
тәкъдим ителгән проект (проект документациясе) нигезендә ризалык бирергә.

2. Билгеләргә [1*]:

ремонт-төзелеш эшләрен башкару срогын 20 __
елның ___ __________-нан (-нән) 20___ елның ___
_________-на (-нә) кадәр;

ремонт-төзелеш эшләрен башкару режимы сәг._____
-дан (-тан, -нан)____сәг.кә кадәр
_________көннәрдә.

3. Мөрәҗәгать итүчегә проект (проект документациясе) нигезендә торак урынны үзгәртеп коруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны һәм ________________________________________________________________________
________________________________________________________________таләпләрне

1 * Ремонт-төзелеш эшләрен башкару срогы һәм режимы гариза нигезендә билгеләнә.Килештерүне гамәлгә ашыручы орган гаризада күрсәтелгән ремонт-төзелеш эшләрен башкару вакытын һәм режимын үзгәрткән очракта, карарда мондый карар кабул итү сәбәпләре бәян ителә.

(Урыннарны үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру буенча ремонт-төзелеш эшләрен башкару тәртибен регламентлаучы Россия Федерациясе яки җирле үзидарә органы акты, субъектның норматив хокукый акты реквизитлары күрсәтелә)

үтәүне йөкләргә

4. Кабул итү комиссиясе башкарылган ремонт-төзелеш эшләрен кабул итә һәм торак урынны үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру турындагы актка билгеләнгән тәртиптә имза сала дип билгеләргә.

5. Кабул итү комиссиясенә, торак урынны үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турындагы актка кул куйганнан соң, кул куелган актны җирле үзидарә органына җибәрергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны ______________________________________________

(структур бүлекчәнең аталышы һәм (яки) килештерүне гамәлгә ашыручы органның урындагы кешесенең Ф.И.А.и.)

______________________________________________йөкләргә.

______________________________

(килештерүне гамәлгә ашыручы органның вазыйфаи заты имзасы)

М.У.

Алдым: “ ____” _______________ , 20__ ел ___________________________ (карар шәхсән алынган очракта тутырыла)

(мөрәҗәгать итүченең яисә вәкаләтле затның имзасы)

Карар мөрәҗәгать итүче адресына җибәрелде “____” ________________, 20 __ ел

(карар почта аша җибәрелгән очракта тутырыла)

______________________________

(мөрәҗәгать итүче адресына карарны җибәргән вазыйфаи зат имзасы )

Күпфатирлы йортта бүлмәләрне
үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан
планлаштыруны килештерү һәм
күпфатирлы йортта бүлмәләрне
төгәлләнгән үзгәртеп кору һәм (яки)
яңадан планлаштыру турындагы
актны кабул итү комиссиясе
тарафыннан рәсмиләштерү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтү
административ регламентына
кушымта №2

**Торакны үзгәртеп коруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны килештерүдән баш тарту турында хәбәрнамә рәвеше**

(Килештерүне гамәлгә
ашыручы орган бланкы)

Хәбәрнамә

___________________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүче физик затның Ф.И.А.и., юридик затның аталышы)

_______________________________________________________________турында
____________________________________________________________адресы буенча
биләгән (анықы булган)________________________________________нигезендә
тәбәндәгеләргә бәйле рәвештә тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча торак урынны үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

1.
2.

______________________________
(килештерүне гамәлгә ашыручы органның вазыйфаи заты имзасы)

М.У.

Алдым: “ ____” _____________ , 20__ ел ______________________ (карар шәхсән алынган очракта тутырыла)

(мөрәҗәгать итүченең яисә вәкаләтле затның имзасы)

______________________________
(мөрәҗәгать итүче адресына карарны җибәргән вазыйфаи зат имзасы )

Күпфатирлы йортта бүлмәләрне үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү һәм күпфатирлы йортта бүлмәләрне төгәлләнгән үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турындагы актны кабул итү комиссиясе тарафыннан рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына кушымта №3

__________________________________________
(муниципаль берәмлекнең
_____________________________________________
җирле үзидарә органы)

Торак урынны үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турында
ГАРИЗА

_____________________________________________________________________________________
(яллаучы, я арендатор, яки урын милекчесе, ике һәм аннан күбрәк затның гомуми милкендә булган урын милекчеләре күрсәтелә, милекчеләрнең берсе дә яки башка зат та билгеләнгән тәртиптә аларның мәнфәгатьләрен якларга вәкаләтле булмаса)

__________________________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________________________

Искәрмә. Физик затлар өчен фамилиясе, исеме, атасының исеме, шәхесне таныклаучы документның реквизитлары (сериясе, номеры һәм кайчан бирелгән), яшәү урыны, телефон номеры күрсәтелә; физик зат вәкиле өчен түбәндәгеләр күрсәтелә: фамилиясе, исеме, атасының исеме, гаризага теркәлә торган вәкилнең ышанычнамә реквизитлары.

Юридик затлар өчен күрсәтелә: аталышы, оештыру-хокукый рәвеше, булу урынының адресы, телефон номеры, юридик зат мәнфәгатьләрен тәкъдим итәргә тиешле вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, бу вәкаләтләрне таныклый торган һәм гаризага теркәлә торган документның реквизитларын күрсәтеп.

Торак урынның урнашкан урыны: ____________________________________________________
(тулы адрес күрсәтелә: Россия Федерациясенең субъекты,
__________________________________________________________________________________________
муниципаль берәмлек, җирлек, урам, йорт, корпус, төзелмә,
__________________________________________________________________________________________
фатир (бүлмә), подъезд, кат)

Торак урынның милекчесе: __________________________________________________________
__________________________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________________________

______________________________________________________________нигезендә билгеләнә торган
(милек хокукы, наем шартнамәсе, аренда шартнамәсе – кирәклесен күрсәтергә)

торак урынны кушымта итеп бирелә торган проект (проект документациясе) нигезендә үзгәртеп коруга , яңадан планлаштыруга яки үзгәртеп коруга һәм яңадан планлаштыруга рөхсәт бирүегезне сорыйм.

Ремонт-төзелеш эшләрен башкару срогы: “____” ________________ 20__ елдан “ ____” _______________ 20__кадәр.

Ремонт-төзелеш эшләрен башкару режимы : _____________кадәр_______________ сәг. ләрдә___________________________көннәрдә____________________________________

Үз өстемә алам:

проект (проект документациясе) нигезендә ремонт-төзелеш эшләрен башкарырга;

эш барышын тикшерү өчен муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының яисә алар тарафыннан вәкаләт бирелгән органга ремонт-төзелеш эшләрен башкару урынына ирекле керү мөмкинлеген тәэмин итәргә;

эшләрне билгеләнгән срокларда һәм килештерелгән эш режимын үтәп гамәлгә ашырырга.

Үзгәртеп коруга һәм (яки) яңадан планлаштыруга ризалык торак урынын яллаучы гаиләнең балигъ булмаган әгъзаларыннан ____ елның ___ _______________ _____номерлы социаль наем шартнамәсе буенча алынды.

| № п/п | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Шәхесне таныклаучы документ (серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән) | Имза * | Затларның имзаларын раслау турында билге |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |
| | | | | |

* Имзалар документларны кабул итүче вазыйфаи зат барында куела. Башка очракта, нотариуста расланган гаилә әгъзасының язма ризалыгы белән, бу хакта 5 графада билге куелып, тапшырыла.

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

1) Үзгәртеп корыла торган һәм (яки) яңадан планлаштырыла торган торак урынга хокук билгели торган документлар (төп нөсхәләр яисә нотариаль тәртиптә таныкланган күчермәләр), әгәр аңа хокук күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм аның белән _____ биттәге алыш-бирешләргә Бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән булса;

2) Торак урынны үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру проекты (проект документациясе) __ биттә;

3) үзгәртеп корыла торган һәм (яки) яңадан планлаштырыла торган торак урынның техник паспорты
__ биттә;

4) архитектура, тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен саклау буенча органның торак урынны үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру мөмкинлеге турында бәяләмәсе (мондый торак урын яки ул урнашкан йорт архитектура, тарих һәм мәдәният һәйкәле булган очракта тапшырыла) __ биттә;

5) яллаучы гаиләсенең вакытлыча булмаган әгъзаларының торак урынын үзгәртеп коруга һәм (яки) яңадан планлаштыруга ризалыгын раслаучы документлар ___ биттә (зарурлык булганда);

6) башка документлар: ____________________________________________
(ышанычнамәләр, уставлардан өземтәләр һәм башкалар.)

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен минем адреска түбәндәге ысул белән бирүегезне (җибәрүегезне) сорыйм:

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетына электрон рәвештә

☐ КФҮ тә

Гариза бирүче затларның имзалары *:

“_____” _______________ , 20__ел ________________ ____________________
(дата) (мөрәҗәгать итүченең имзасы) (мөрәҗәгать итүче имзасының расшифровкасы)

“_____” _______________ , 20__ел ________________ ____________________
(дата) (мөрәҗәгать итүченең имзасы) (мөрәҗәгать итүче имзасының расшифровкасы))

* Социаль наем шартнамәсе нигезендә торак урыныннан файдаланганда гариза шартнамәдә як сыйфатында күрсәтелгән яллаучы тарафыннан имзалана, торак урыныннан аренда шартнамәсе нигезендә файдаланганда – арендатор тарафыннан, торак урыннан милек хокукында файдаланганда - милекче (милекчеләр)тарафыннан.

Күпфатирлы йортта бүлмәләрне үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү һәм күпфатирлы йортта бүлмәләрне төгәлләнгән үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турындагы актны кабул итү комиссиясе тарафыннан рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына кушымта №4

________________________________________
(муниципаль берәмлекнең

________________________________________
җирле үзидарә органы)

## Күпфатирлы йортта торак урынны үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыруның төгәлләнүен раслый торган документ бирү турында
## ГАРИЗА

____________________________________________________________________________
(яллаучы, я арендатор, яки урын милекчесе, ике һәм аннан күбрәк затның гомуми милкендә булган урын милекчеләре күрсәтелә, милекчеләрнең берсе дә яки башка зат та билгеләнгән тәртиптә аларның мәнфәгатьләрен якларга вәкаләтле булмаса)

____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________

<u>Искәрмә.</u> <u>Искәрмә.</u> Физик затлар өчен фамилиясе, исеме, атасының исеме, шәхесне таныклаучы документның реквизитлары (сериясе, номеры һәм кайчан бирелгән), яшәү урыны, телефон номеры күрсәтелә; физик зат вәкиле өчен түбәндәгеләр күрсәтелә: фамилиясе, исеме, атасының исеме, гаризага теркәлә торган вәкилнең ышанычнамә реквизитлары.

Юридик затлар өчен күрсәтелә: аталышы, оештыру-хокукый рәвеше, булу урынының адресы, телефон номеры, юридик зат мәнфәгатьләрен тәкъдим итәргә тиешле вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, бу вәкаләтләрне таныклый торган һәм гаризага теркәлә торган документның реквизитларын күрсәтеп.

Торак урынның урнашкан урыны: ________________________________________
(тулы адрес күрсәтелә: Россия Федерациясенең субъекты,

____________________________________________________________________________
муниципаль берәмлек, җирлек, урам, йорт, корпус, төзелмә,

____________________________________________________________________________
фатир (бүлмә), подъезд, кат)

Торак урынның милекчесе: ______________________________________________
____________________________________________________________________________

______________________________________________тарафыннан эшләнгән проект һәм
(проектны эшләүченең исеме (аталышы))

Башкарма комитетның 20___ елның ____ _____________ ___ номерлы карары нигезендә башкарылган торакны үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру эшләрен кабул итүегезне сорыйм.

Проектта каралган эшләр башкарылды:______________________________________________
(эшләрне башкаручының исеме һәм реквизитлары)

Проектта каралган эшләр түбәндәге срокларда үтәлде:
эшләр башланды:_________________________эшләр
төгәлләнде:_______________________________
Ремонт-төзелеш эшләрен кабул итү өчен комиссия чыгуның датасы һәм вакыты турында хәбәр итүегезне сорыйм электрон почта адресына_____________ түбәндәге телефон буенча____________

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен минем адреска түбәндәге ысул белән бирүегезне (җибәрүегезне) сорыйм:

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетына электрон рәвештә

☐ КФҮ тә

Гариза бирүче затларның имзалары *:

| | | | |
|---|---|---|---|
| “_____” _______________ | , 20__ ел | _________________ | ____________________________ |
| (дата) | | (мөрәҗәгать итүченең имзасы) | (мөрәҗәгать итүче имзасының расшифровкасы) |
| “_____” _______________ | , 20__ ел | _________________ | ____________________________ |
| (дата) | | (мөрәҗәгать итүченең имзасы) | (мөрәҗәгать итүче имзасының расшифровкасы)) |

*Социаль наем шартнамәсе нигезендә торак урыныннан файдаланганда гариза шартнамәдә як сыйфатында күрсәтелгән яллаучы тарафыннан имзалана, торак урыныннан аренда шартнамәсе нигезендә файдаланганда – арендатор тарафыннан, торак урыннан милек хокукында файдаланганда - милекче (милекчеләр)тарафыннан.

Күпфатирлы йортта бүлмәләрне үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү һәм күпфатирлы йортта бүлмәләрне төгәлләнгән үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турындагы актны кабул итү комиссиясе тарафыннан рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына кушымта №5

**Документларны кабул итүдән баш тарту турында хәбәрнамә рәвеше**

(Килештерүне гамәлгә
ашыручы орган бланкы)

Хәбәрнамә

______________________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүче физик затның Ф.И.А.и., юридик затның аталышы)

_____________________________________________________________________турында
_______________________________________________________________адресы буенча
билгән (анык булган)___________________________________________нигезендә тәбәндәгеләргә бәйле рәвештә тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

1.
2.

______________________________
(килештерүне гамәлгә ашыручы органның вазыйфаи заты имзасы)

М.У.

Алдым: “ ____” ______________ , 20__ ел ________________________ (карар шәхсән алынган очракта тутырыла)

(мөрәҗәгать итүченең яисә вәкаләтле затның имзасы)

______________________________
(мөрәҗәгать итүче адресына карарны җибәргән вазыйфаи зат имзасы )

Күпфатирлы йортта бүлмәләрне үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү һәм күпфатирлы йортта бүлмәләрне төгәлләнгән үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турындагы актны кабул итү комиссиясе тарафыннан рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына кушымта №6

Башкарма комитет җитәкчесе
______________________________
____________________________

техник хатаны төзәтү турында
ГАРИЗА.

_______________________________________________муниципаль хезмәт
(күрсәтелгән хезмәтнең исеме)
күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.
Язылган:______________________________________________________________
__________________________________________________________________________
Дөрес мәгълүматлар:__________________________________________________________
________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып торган документка тиешле үзгәрешләрне кертүне үтенәм.

Түбәндәге документларны терким:
1.
2.
3.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кире кагу хакында карар кабул иткән очракта андый карарны җибәрүне үтенәм:

электрон документны E-mail_______________адресына җибәрү ярдәмендә; почта аша кәгазь йөрткечтә расланган күчермә рәвешендә түбәндәге адрес буенча:
____________________________________________________________________ ___

Әлеге гариза белән раслыйм: гаризадагы минем шәхескә һәм минем тарафтан тәкъдим ителүче затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры киләләр, гаризаны бирү моментына бу документлар чын һәм дөрес мәгълүматларны үз эчләренә алалар.

_______________ ___________________ ( _________________)
(дата) (имза) (Ф.И.А.и.)

Күпфатирлы йортта бүлмәләрне үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү һәм күпфатирлы йортта бүлмәләрне төгәлләнгән үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турындагы актны кабул итү комиссиясе тарафыннан рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына кушымта №7

РАСЛЫЙМ
____________________________________
(Вазыйфаи зат)
_________________ (___________________)
(шәхси имза) (имзаның расшифровкасы)
М.У. " __ " _______, 20__ ел

Күпфатирлы йортта урыннарны төгәлләнгән үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турында

АКТ

___________ " ___ " ______ 20_ ел

Объектның адресы: ________________________________________ ________ ________ ________
(ур./тыкрык һ.б.ш.) (йорт № ы) ( кор. №ы) (фатир № ы)
Урын ________________________________________________ ____ ______________ ___________
(күрсәтергә: торак / торак булмаган) (подъезд № ы) (кат)
Комиссия тәбәндәге вәкилләр составында:
- _______________ (рәис) - _______________________________________________
- мөрәҗәгать итүче (заказ бирүче)- _________________________________________
- үтәүче (эшләрне башкаручы) - ____________________________________________
- күпфатирлы йорт белән идарә итүче оешма (зарурлык булганда) - билгеләде:
______________________________

1. Комиссиягә түбәндәге эшләр тәкъдим ителде::
_____________________________________________________________________________
(торак урынны, элементларны, инженерлык системаларын күрсәтеп)

2. Эшләр башкарылды:
_____________________________________________________________________________
(эшләрне башкаручының исеме (аталышы) һәм реквизитлары)

3. Проект (башкару) документлары эшләнде:
_____________________________________________________________________________
(документлар составы, авторның исеме һәм реквизитлары)

расланды ______________________________________________ « ___» ______ 20__ ел
(раслаучы затның статусы)

4. Эшләр түбәндәге срокларда башкарылды:
эшләр башланды «___» ______ 20__ ел; төгәлләнде «___» _______ 20__ ел

5. Кабул итүгә куелган торак урыннарны (элементларны, инженерлык системаларын) натурада карап чыгу һәм проект (башкару) документлары белән танышу нигезендә билгеләнде:
5.1. ___________________________________________________________________________
(проектка туры килә / туры килми - күрсәтергә)
5.2. ___________________________________________________________________________
(күзәтчелек органнарының искәртүләре-(күрсәтергә: бетерелгән/бетерелмәгән)

КОМИССИЯ КАРАРЫ:

1. Комиссиягә тәкъдим ителгән эшләрне санарга: __________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
күпфатирлы йортлар өчен гамәлдә булган норматив документлар таләпләре нигезендә башкарылган/ башкарылмаган дип.

2. Әлеге Актны катлар планнарына һәм техник инвентаризация органнарының экспликацияләренә үзгәрешләр кертү өчен нигез дип санарга.

Актка кушымталар:
1. Башкару сызымнары:
_______________________________________________________________________________
(билгеләнгән тәртиптә кертелгән үзгәрешләр белән проект материаллары)
_______________________________________________________________________________
2. ______________________ _____________________________________________________
(күрсәтергә)
_______________________________________________________________________________

Комиссия рәисе __________________________________ ( _______________________ )
(Шәхси имза) (имзаның расшифровкасы)

Комиссия әгъзалары
________________________ ( _______________________ )
________________________ ( _______________________ )

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Балык Бистәсе шәһәр
җирлеге Башкарма комитетының
2022 елның 31 мартындагы
29 номерлы карарына
кушымта №3

## Социаль наем шартнамәсе нигезендә торак урыны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Административ регламентны җайга салу предметы

1.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) социаль наем шартнамәсе нигезендә торак урыны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең (алга таба – муниципаль хезмәт) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.1.2. Административ регламент нигезләмәләре социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль торак фондының “Татарстан Республикасы дәүләт торак фондының һәм социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондының торак урыннарын бирүгә гражданнарның хокукларын тормышка ашыру турында” 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә торак урынын биргәндә кулланыла (алга таба – тиңдәшле рәвештә торак урыннары, 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы).

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре

1.2.1. Муниципаль хезмәт алу хокукына ия затлар – Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче торак урыннарга мохтаҗ дип танылган һәм аларга карата торак урыны бирү турында карар кабул ителгән Россия Федерациясе гражданнары (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

1.2.2. Гариза белән мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамәгә нигезләнгән вәкаләтләр нигезендә эш итүче вәкаләтле вәкиле, мөрәҗәгать итүченең федераль закон нигезендә яисә моңа вәкаләтле җирле үзидарә органы акты нигезендә эш итүче законлы вәкиле мөрәҗәгать итәргә хокуклы (алга таба – мөрәҗәгать итүче, мөрәҗәгать итүче вәкиле).

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мәгълүмат бирү (хәбәр итү) тәртибе

1.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат урнаштырыла:

1) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре биналарында урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендларында;

2) муниципаль районның “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге https://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru/ рәсми сайтында;

3) Татарстан Республикасының https://uslugi.tatarstan.ru дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр Порталында (алга таба – Республика порталы);

4) http:// www.gosuslugi.ru Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләр) порталында (алга таба – Бердәм портал);

5) “Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры” дәүләт мәгълүмат системасында (http://frgu.tatar.ru) (алга таба – Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры).

1.3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча консультация (мәслихәт) бирү гамәлгә ашырыла:

1) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яисә телефон буенча;

2) Республика порталының интерактив рәвешендә;

3) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетында (алга таба – Орган):

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яисә телефон буенча;

язма рәвештә (шул исәптән электрон документлар рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә – кәгазь йөрткечтә почта аша, электрон рәвештә электрон почта аша.

1.3.3. Бердәм порталда, Республика порталында Республика реестрындагы мәгълүматлар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат гариза бирүчегә бушлай бирелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка мөрәҗәгать итүченең нинди дә булса таләпләр үтәмичә генә, шул исәптән, мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштыру гариза бирүчедән түләү алуны, теркәүне яисә авторизацияне күздә тотучы программа тәэмин ителешенең хокук иясе белән лицензияле яисә башка килешү төзүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча яисә аларга шәхси мәгълүматлар бирмичә керү мөмкинлеге гамәлгә ашырыла.

1.3.4. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә телефон аша мөрәҗәгать иткәндә кергән мөрәҗәгать нигезендә түбәндәге мәгълүмат бирелә:

1) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, Органның урнашкан урыны турында (адресы, эш графигы, белешмә телефоннары);

2) муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында, гаризалар бирү ысуллары һәм сроклары турында;

3) муниципаль хезмәт күрсәтелә торган гражданнар категорияләре турында; муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләрен җайга сала торган норматив хокукый актлар турында;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны карау өчен кирәкле документлар исемлеге турында, гаризаны кабул итү һәм теркәү сроклары турында;

5) муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында;

6) муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүматның рәсми сайтында урнашу урыны турында;

7) Органның вазыйфаи затларының (урындагы кешеләренең) гамәлләренә яисә гамәл кылмауларына карата шикаять белдерү тәртибе турында.

Язма мөрәҗәгать буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы бүлекнең вазыйфаи затлары мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен һәм регламентның әлеге пунктында күрсәтелгән мәсьәләләрне язма рәвештә аңлаталар һәм мөрәҗәгатьне теркәгәннән соң өч эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрәләр. Җаваплар мөрәҗәгать иткән телдә бирелә. Мөрәҗәгать иткән телдә җавап бирү мөмкин булмаган очракта Татарстан Республикасы дәүләт телләре кулланыла.

1.3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат муниципаль районның рәсми сайтында һәм Орган бүлмәләрендәге гариза бирүчеләр белән эшләү өчен куелган мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

“Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге муниципаль районның рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларында урнаштырылган Татарстан Республикасы Дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге Регламентның 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы үзидарәлек хезмәте турындагы мәгълүматларны, Органның урнашу урыны, белешмә телефоннары, эш вакыты, муниципаль хезмәт күрсәтүгә гаризалар кабул итү графигы турында мәгълүматны үз эченә ала.

## 1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге

1.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актлар реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп) Бердәм порталда, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта, Республика реестрында урнаштырылган.

1.4.2. Гамәлдәге редакциядә административ регламент тексты Бердәм порталда, Республика реестрында, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштырылырга тиеш.

## 1.5. Административ регламентта кулланыла торган терминнар һәм аларның билгеләмәләре

1.5.1. Регламентта түбәндәге атамалар (терминнар) һәм билгеләмәләр файдаланыла:

дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтү күпфункцияле үзәгенең ераклашкан эш урыны – 2012 елның 22 декабрендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтү күпфункцияле

үзәкләре эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләрен раслау турында” 1376 номерлы карары белән расланган дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтү күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районының шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында төзелгән дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтү күпфункцияле үзәгенең территория ягыннан аерымланган структура бүлекчәсе (офисы);

техник хата – үзидарәлек хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка кертелгән (үзидарәлек хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсенә) мәгълүматларга тәңгәл булмауга, алар нигезендә кертелгән мәгълүматларның документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китерүче ялгыш (ялгышлык белән җибәрелгән хәреф, сүз хатасы, грамматик яки арифметик хата яисә шуларга охшаш ялгышлыклар).

Электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик үзара хезмәттәшлеген (багланышын) тәэмин итүче инфраструктурада идентификацияләүнең (бердәйләштерүнең, тәңгәлләштерүнең) һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы (алга таба – ЕСИА (Единая система идентификации и аутентификации)) – дәүләт мәгълүмат системаларында һәм башка мәгълүмат системаларында булган мәгълүматны идентификацияләү һәм аутентификацияләү системасында мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучыларның санкцияләнгән файдалана алуын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы;

КФҮ – “Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге” дәүләт бюджет учреждениесе;

КФҮ нең АМС – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы.

1.5.2. Әлеге административ регламентта кулланыла торган төп төшенчәләр “Конкуренцияне яклау турында” 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закондагы мәгънәләрендә кулланыла.

1.5.3. Регламентта муниципаль (үзидарәлек) хезмәте күрсәтү турындагы гариза дигәндә (алга таба – гариза) үзидарәлек хезмәте күрсәтү турында “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 маддәсенең 3 пункты (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә бирелгән гарызнамә (рәсми таләп) аңлашыла.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

2.1. Муниципаль хезмәтнең аталышы

Социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү.

2.2 Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарәнең башкарма-боеручы органының исеме (аталышы)

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты

2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау

2.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып тора:

4) торак урынга социаль наем шартнамәсе проекты (әлеге административ регламентка 1 нче кушымта, шартнамә рәвешен кушымта итеп бирергә);

5) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар (әлеге административ регламентка 2 нче кушымта).

2.3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе “Электрон имза турында” 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә мөрәҗәгать итүчегә Бердәм порталның шәхси кабинетына Органның вәкаләтле вазыйфаи затының (яисә Органның) көчәйтелгән квалификацияле электрон култамгасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә. Гариза Республика порталы ярдәмендә җибәрелгән очракта муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе Республика порталының шәхси кабинетына да җибәрелә.

2.3.3. Мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе Органда яки КФҮтә кәгазьдә йөрткечтәге электрон документ нөсхәсе рәвешендә бирелә, ул тиңдәшле рәвештә Органның вәкаләтле вазыйфаи заты яисә КФҮ хезмәткәре имзасы һәм мөһер белән таныкланган була.

2.3.4. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәтне күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең гамәлдә булу срогы дәвамында алырга хокуклы.

2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы

2.4.1. Муниципаль хезмәт документлар бирелгән көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча күрсәтелә.

2.4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктату каралмаган.

2.4.3. Электрон документ рәвешендә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документны җибәрү муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

2.5. Үзидарәлек хезмәте күрсәтү өчен законнар яки башка норматив хокукый актлар нигезендә гариза бирүче тапшырырга тиешле зарури документларның, шулай ук үзидарәлек хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрнең тулы исемлеге, аларны гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Мөрәҗәгатьнең категориясенә һәм нигезенә карамастан муниципаль хезмәт алу өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тапшыра: :

1) шәхесне таныклаучы документ (Республика порталы ярдәмендә мөрәҗәгать иткәндә таләп ителми);

2) мөрәҗәгать итүче вәкиленең муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, аның вәкаләтләрен раслаучы документ (физик затларның законлы вәкилләре мөрәҗәгать иткән очракта таләп ителми);

3) гариза:

кәгазь йөрткечтәге документ рәвешендә (әлеге административ регламентка 3 нче кушымта);

электрон рәвештә (тиешле мәгълүматларны гаризаның электрон рәвешенә кертү юлы белән тутырыла), ул Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә Регламентның 2.5.7 пункты таләпләре нигезендә имзалана.

4) мөрәҗәгать итүченең гаилә составын раслый торган документлар:

чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе;

гражданлык хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясе консул учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклыклар;

сорау алу, тикшерү органнары тарафыннан яисә җинаять эшләре буенча производство барышында суд тарафыннан бирелгән документлар, граждан яисә административ суд эшчәнлеге барышында бирелгән (рәсмиләштерелгән) документлар яисә арбитраж судлар производствосы барышында бирелгән документлар, шул исәптән гомуми юрисдикция һәм арбитраж судларның карарлары, приговорлары, хөкемнәре һәм постановлениеләре.

5) мөрәҗәгать итүчене яисә аның гаилә әгъзасын торак законнары нигезендә чиратсыз торак урыны бирү хокукына ия гражданнар категориясенә кертергә нигез бирә торган документлар:

медицина оешмасыннан медицина белешмәсе – гражданның гаиләсе составында хроник чирнең авыр формасы белән интегүче хаста булып, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы раслаган исемлек буенча аның белән бер фатирда бергә яшәү мөмкин булмаган очракта;

опекун билгеләү турында опека һәм попечительлек органнарыннан белешмә - хокукый сәләтсез граждан исеменнән эш итүче опекун тарафыннан исәпкә алу турында гариза имзаланган очракта;

ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларның статусын раслый торган документлар, алар мәгариф һәм башка оешмаларда булу тәмамланганнан соң, шул исәптән социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында, тәрбиягә алган гаиләләрдә, гаилә тибындагы балалар йортларында, опеканы (попечительлекне) туктатканда, шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәт тәмамланганнан соң яисә иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтү учреждениеләреннән кайтканнан соң;

6) күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрында хокуклар теркәлмәгән күчемсез мөлкәт объектларына хокук билгели торган документлар;

7) социаль наем шартларында элек биләгән мәйданны яңа торак урыны алганнан соң гаиләнең балигъ булган әгъзаларының азат итүе турында йөкләмәләре, торак урынны булган торак урынга өстәмә итеп бирү очракларыннан тыш.

2.5.2. Мөрәҗәгать итүче аз керемле дип танылган очракта, административ регламентның 2.5.1 пунктында каралган документлар белән бер үк вакытта түбәндәге документлар бирелә:

1) мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзалары уку йортларында укыган очракта, аларның урта һөнәри яки югары белем бирү оешмаларында укуы турында белешмәләре;

2) салым салуның гомуми һәм гадиләштерелгән системасын, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре өчен салым салу системасын (бердәм авыл хуҗалыгы салымы) кулланучы индивидуаль эшкуарның керемнәрен һәм чыгымнарын һәм хуҗалык операцияләрен исәпкә алу кенәгәсендәге мәгълүматлары;

3) индивидуаль эшкуарларның хисап чорындагы чыгымнарны раслый торган беренчел исәпкә алу документлары, салым салу объекты тиешле чыгымнар күләменә киметелмәгән керемнәр булса;

4) крестьян (фермер) хуҗалыгы әгъзалары арасында нәтиҗәләрне, продукция һәм әгәр гариза бирүченең гаилә әгъзалары шундый хуҗалык әгъзалары булса, әлеге хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәрне бүлү турында килешү (шартнамә);

5) торак урыннарына мохтаҗ дип танылган гражданнар милкендәге транспорт чараларын бәяләү турында бәяләү эшчәнлеге субъекты хисабы.

2.5.3. Исәп-хисап чоры дәвамында гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче мөрәҗәгать итүче салым салынырга тиешле һәм гражданнарны аз керемле дип тану өчен исәпкә алына торган мөлкәт исемлегенә керүче мөлкәтне сатарга мәҗбүр булган очракта, сатуның сәбәбен раслый торган документлар тапшырыла (медицинада вакытлы дәвалану, кыйммәтле дарулар һәм башкалар.).

2.5.4. Торак-төзелеш һәм гараж кооперативларында пай тупланышлары булганда, мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән пай тупланышларының торак-төзелеш, гараж кооперативлары тарафыннан таныкланган хакы (бәясе) турында мәгълүматлар тапшыра.

2.5.5. Әгәр мөрәҗәгать итүче Федераль закон, Россия Федерациясе Президенты Указы яисә Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән категориягә административ регламентның 2.5.1 пунктында каралган документлар белән бер үк вакытта кертелгән булса, гражданнарның федераль закон, Россия Федерациясе Президенты Указы яисә Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алыну хокукына ия булган башка категориягә мөнәсәбәтен раслаучы документлар кирәк булачак.

2.5.6. Гариза һәм теркәп бирелә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

1) КФҮ аша кәгазь йөрткечләрдә һәм Регламентның 2.5.7 пункты таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә;

2) Республика порталы аша электрон рәвештә.

3) Органда шәхсән яки кәгазь йөрткечтә почта элемтәсе ярдәмендә.

Гариза һәм теркәлә торган документлар почта элемтәсе аша җибәрелгәндә билгеләнгән тәртиптә таныклана.

2.5.7. Республика порталы аша җибәрелгәндә гариза мөрәҗәгать итүченең гади электрон култамгасы белән имзалана.

Гади электрон имза алу өчен гариза бирүчегә ЕСИА да теркәлү (аутентификацияләү) процедурасын узарга, шулай ук хисап язмасын расларга кирәк.

Регламентның 2.5.1 пунктының 2, 4-6 пунктчаларында, 2.5.2 пунктының 5 пунктчасында күрсәтелгән электрон документлар (документларның электрон үрнәкләре) мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затлар, шул исәптән нотариуслар тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон култамга белән имзаланалар.

Гаризага теркәлеп бирелә торган электрон документлар (электрон документлар үрнәкләре), шул исәптән ышанычнамәләр pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf форматларында 50 Мбайттан да артмаган күләмдә файллар рәвешендә җибәрелә.

Электрон документларның (электрон документлар үрнәкләренең) сыйфаты документ текстын тулы күләмдә укырга һәм документ реквизитларын танырга мөмкинлек бирергә тиеш.

2.5.8. Мөрәҗәгать итүчедән таләп итү тыела:

1) муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшыру яисә гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыру яисә гамәлләр кылуны;

2) муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле һәм башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга мөрәҗәгать итү белән бәйле гамәлләрне, шул исәптән килештерүләрне гамәлгә ашыруны, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 9 маддәсенең 1 өлешендә күрсәтелгән исемлекләргә кертелгән мондый хезмәтләр (кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр) күрсәтү нәтиҗәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрне һәм документларны алудан гайре;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны башта кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәткәндә баш тартканда документларның һәм мәгълүматның булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүматны тапшыруны, түбәндәге очраклардан гайре:

а) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза башта бирелгәннән соң муниципаль хезмәт күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актлар таләпләренең үзгәрүе;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризада һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны баштагы кабул итүдән баш тартканнан соң мөрәҗәгать итүче биргән документларда яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдә элек бирелгән документлар комплектына кертелмәгән хаталар булу;

в) документларның гамәлдә булу вакыты чыгу яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән башта баш тартканнан соң яки муниципаль хезмәт күрсәтүдә мәгълүмат үзгәрү;

г) Органның вазыйфаи затының, КФҮ хезмәткәренең муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне баштагы кире какканда яисә муниципаль хезмәт күрсәткәндә хаталы яки хокукка каршы гамәл кылуының (гамәл кылмавының) документаль расланган факты (билгеләре) ачыклану, әлеге муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу очрагында Орган җитәкчесе имзасы белән язма рәвештә мөрәҗәгать итүчегә хәбәрнамә ирештерелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә;

4) электрон рәвешләре 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсендәге 1 өлешенең 7.2 пункты нигезендә элек расланган документларны һәм мәгълүматны кәгазь йөрткечтә тапшыру, мондый документларга тамга салу яисә аларны алу дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан гайре.

## 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә зарур булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хаклы документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма.

2.6.1. Ведомствоара хезмәттәшлек (багланышлар) кысаларында алына:

1) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан (алга таба – КМБДР) мөрәҗәгать итүчегә, аның гаилә әгъзаларына һәм аның белән бергә теркәлгән барлык гражданнарга аерым затның Россия Федерациясе территориясендә булган күчемсез милек объектларына хокуклары турында өземтәләр.

2) Күчемсез милек объектларына мөрәҗәгать итүчегә, аның гаилә әгъзаларына һәм алар белән бергә теркәлгән барлык гражданнарга хокукларның күчүе турында БДКМР нан өземтәләр.

3) Күчемсез милек объектына төп сыйфатламалар һәм теркәлгән хокуклар турында БДКМР нан өземтәләр.

4) Физик затны салым органында исәпкә кую турындагы мәгълүматлар (ИНН – СТТН (салым түләүченең таныклау номеры)).

5) Шәхси лицевой счётның иминият номеры (СНИЛС – ШЛСИН) турындагы мәгълүматлар.

6) иминиятләштерелгән затны түләү күләме турында мәгълүматлар.

7) туу турында таныклык күләмендә мәгълүматлар.

8) никахлашу турында таныклык күләмендә мәгълүматлар.

9) үлем турында таныклык күләмендә мәгълүматлар.

10) Яшәү урыны буенча теркәлгән барлык гражданнар турында мәгълүматлар булган документ, гражданнарның адресын, теркәлү датасын, бирелә торган торак урынына документ бирү датасын күрсәтеп.

11) Торак урынның торак мәйданы һәм гомуми мәйданы, бирелә торган торак урынының бирү датасы күрсәтелгән финанс лицевой счеты.

Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге регламентның 2.5.6 пунктында тәгаенләнгән. Мөрәҗәгать итүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы югарыда санап үтелгән документларны таләп итү тыела.

2.6.2. Мөрәҗәгать итүче Регламентның 2.6.1 пунктының 1-9 пунктчаларында күрсәтелгән документларны (мәгълүматларны) мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затларның көчәйтелгән квалификацияле култамгасы белән таныкланган электрон документлар рәвешендә гариза биргәндә тапшырырга хокуклы.

2.6.3. Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар тарафыннан документлар һәм мәгълүматларны тапшырмау (вакытында тапшырмау) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.6.4 Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән органнарның соралган һәм карамагында булган документларны яисә мәгълүматларны тапшырмаган (үзвакытында тапшырмаган) вазыйфаи заты һәм (яисә) хезмәткәре Россия Федерациясе законнары нигезендә административ, дисциплинар яисә башка җаваплылыкка тартылырга тиеш.

2.6.5. Гариза бирүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар карамагындагы документларны һәм мәгълүматларны, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәткән өчен гариза бирүче тарафыннан түләү кертүне раслый торган мәгълүматларны таләп итү тыела.

Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалар карамагында булган мәгълүматларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырмау мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

## 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

1) тапшырылган документларда текстның бетерелгән (сөртелгән) һәм Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланмаган төзәтмәләре бар.

2) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлардагы зарарланулар мәгълүматны тулы күләмдә кулланырга, текстны укырга һәм (яки) танырга мөмкинлек бирми;

3) тапшырылган документлар яисә мәгълүматлар муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итү вакытына үз көчләрен югалтканнар (вәкил муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклаучы документ);

4) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар билгеләнгән таләпләрне бозып, электрон формада бирү;

5) гариза формасындагы мәҗбүри кырларны, шул исәптән Республика порталындагы гаризаның интерактив рәвешендә, дөрес тутырмау (дөрес түгел, тулы булмаган яисә дөрес тутырылмаган);

6) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мәҗбүри булган регламентта каралган документларның тулы булмаган комплекты бирелгән;

7) хезмәт күрсәтү турында гариза муниципаль хезмәт күрсәтү вәкаләтләренә керми торган дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына яисә оешмага тапшырылган;

8) “Электрон имза турында” 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 маддәсендә билгеләнгән көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаның чынлыгын тану шартларын үтәмәү.

2.7.2. Муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге төгәл булып тора.

2.7.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда, Республика порталында бастырылган муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

### 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр күздә тотылмый.

2.8.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:

2.8.2.1. Хезмәтләр күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге:

1) әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гаризага теркәп бирелә торган документларны тапшырмау;

2) тәкъдим ителгән документларда тулы булмаган һәм (яисә) дөрес булмаган мәгълүмат булу;

3) гражданнарның мөлкәти хәлләрен исәпкә алып, аз керемле дип тану өчен нигезләренең булмавы;

4) гражданнарның социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар дип тану өчен нигезләре булмау;

5) дәүләт органы, җирле үзидарә органы, оешманың ведомствоара гарызнамәгә җавабы гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүматның булмавын күрсәтә, әгәр тиешле документ гариза бирүче тарафыннан үз инициативасы буенча тапшырылмаган булса, мондый соратып алына торган документ яисә мондый органнар яки оешмалар карамагында мәгълүмат булмау тиешле гражданнарның торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптә тору хокукын раслый торган очраклардан тыш;

6) гражданнарның торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптә тору хокукын расламый торган документлар тапшырылган һәм (яисә) гарызнамә буенча алынган;

7) күрсәтелгән гражданнар торак урыннарына мохтаҗ дип танылырга мөмкин булган гражданнар тарафыннан кылынган гамәлләр көненнән соң кануннарда билгеләнгән вакыт чыкмаган.

2.8.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге төгәл булып тора.

2.8.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза Бердәм порталда, Республика порталында игълан ителгән (бастырылган) муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.9. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алынучы дәүләт пошлинасы (акчалата җыемы) һәм бүтән түләүнең тәртибе, күләме һәм түләтү нигезе

Муниципаль хезмәт бушлай күрсәтелә.

2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында мәгълүматлар

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтүгә түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми

2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамә биргәндә, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәт күрсәтелгәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты

2.12.1. Муниципаль хезмәт алуга гариза биргәндә көтү вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.12.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

## 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең гарызнамәсен һәм хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтне теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон рәвештә

2.13.1. Гариза биргән көнне КФҮкә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүчегә гаризаның җибәрелүенраслаучы теркәлү номеры һәм электрон гаризаны бирү датасы белән КФҮ АМС ннан раслама бирелә.

2.13.2. Гаризаны Республика порталы ярдәмендә юллаганда мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Республика порталының шәхси кабинетында һәм электрон почта аша, гаризаның теркәлү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелеп, гаризаның җибәрелүен раслый торган хәбәрнамә ала.

2.13.3. Органга шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гариза биргән көнне вәкаләтле вазыйфаи зат Органга мөрәҗәгать итүчегә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан теркәү номеры, гариза бирү датасы һәм тапшырылган документлар исемлеге белән раслама бирә.

## 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, көтү залына, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамәләрне тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре һәм һәр муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге булган мәгълүмат стендларына карата, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыру һәм бизәүгә, шул исәптән әлеге объектларга инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвалидлар өчен үтү (керү) мөмкинлеген тәэмин итүгә таләпләр

2.14.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебельләр, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

2.14.2. Инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү (үтү) максатларында түбәндәгеләр тәэмин ителә:

11) инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына каршылыксыз керүе (үтә алуы) тәэмин ителә (бина-бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм алар эчендә күченү, хәрәкәт итү).

12) муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

13) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләренең ныклы тайпылышлары булган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

14) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм алардан чыгу, транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

15) инвалидларның хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөрткечләрне аларның тереклек эшчәнлегенең чикләнгәнлеген исәпкә алып тиешенчә урнаштыру;

16) инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук өсьязуларны, билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайль рельеф-нокталы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау;

17) сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчегә рөхсәт итү;

8) озатучы-этне махсус укыту-өйрәтүне раслаучы һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының “Озатучы-этне махсус укытуны раслый торган документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында” 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән билгеләнгән рәвештә һәм тәртиптә бирелгән документы булганда рөхсәт итү.

2.14.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектлардан һәм муниципаль хезмәт күрсәткәндә кулланыла торган Регламентның 2.14.2 пунктының 1 – 4 пунктчаларында күрсәтелгән чаралардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр, алар 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизацияләнгән объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

## 2.15. Муниципаль хезмәтнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән муниципаль хезмәт күрсәткәндә үзара багланышлары саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләрен кулланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы күләмдә), җирле үзидарәнең башкарма-боеру органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә муниципаль хезмәт алу мөмкинлеге яисә мөмкин түгеллеге, мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча (экстерриториаль принцип), 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 маддәсендә каралган күпфункцияле үзәкләрдә берничә дәүләт һәм (яисә) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамә (комплекслы гарызнамә) ярдәмендә

2.15.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкинлеге (доступность) күрсәткечләре булып тора:

документлар кабул итү, бирү алып барыла торган бинаның җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итүне гамәлгә ашыра торган бүлмәләрнең кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, муниципаль районның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында муниципаль хезмәтне күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

инвалидларга башкалар белән бер үк дәрәҗәдә хезмәтләр алырга комачаулаучы киртәләрне җиңәргә ярдәм итү.

2.15.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләр:

1) документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;

2) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу срогын үтәү;

3) орган хезмәткәрләре тарафыннан Регламентны бозуга карата нигезле шикаятьләр булмау;

4) мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән багланышлары саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең КФҮ хезмәткәрләре белән багланышы барлык кирәкле документлар белән гариза биргәндә бер тапкыр гамәлгә ашырыла;

бер тапкыр Органда яки КФҮ тә электрон документның нөсхә рәвешендә кәгазь йөрткечтәге муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу кирәк булган очракта.

Муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бер мәртәбә багланышының дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.

Мөрәҗәгать итүче күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын Республика порталы, терминал җайланмалары аша бәяләргә хокуклы.

2.15.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүматны мөрәҗәгать итүче Бердәм порталда яисә Республика порталында шәхси кабинетта, Органда, КФҮ тә алырга мөмкин.

2.15.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча яшәү урынына яисә фактта яшәү (булу) урынына бәйсез рәвештә Татарстан Республикасы территориясендә экстерриториаль принцип буенча.теләсә кайсы КФҮ тә гамәлгә ашырыла.

Комплекслы гарызнамә составында муниципаль хезмәт күрсәтелми.

### 2.16. Башка таләпләр, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча (әгәр муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә икән) муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алып, һәм электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре

2.16.1. Муниципаль хезмәт электрон рәвештә күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хаклы:

1) Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон рәвешләре 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсендәге 1 өлешенең 7.2 пункты нигезендә Республика порталыннан файдаланып таныкланган документлар һәм мәгълүмат бирүгә;

3) электрон рәвештә бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында мәгълүматлар алырга;

4) муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;

5) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә алырга;

6) Республика порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә кылынган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауларга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итүче федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Органның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирергә.

2.16.2. Гаризаны формалаштыру Республика порталында гаризаның электрон рәвешен тутыру юлы белән нинди дә булса башка рәвештә гариза бирү зарурлыгыннан башка гамәлгә ашырыла.

2.16.3. Гаризаны формалаштырганда түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) гаризаны һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны күчермәләү һәм саклау мөмкинлеге;

2) берничә мөрәҗәгать итүче тарафыннан уртак гариза җибәрүне күздә тоткан хезмәтләр сорап мөрәҗәгать иткәндә гаризаның бер электрон рәвешен берничә мөрәҗәгать итүченең бергә тутыру мөмкинлеге;

3) гаризаның электрон рәвеше күчермәсен кәгазь йөрткечтә бастыру мөмкинлеге;

4) кулланучы теләге буенча теләсә кайсы вакытта электрон рәвешкә элек кертелгән кыйммәтләрне саклап калу, шул исәптән кертү хаталары барлыкка килгәндә һәм кыйммәтләрне гаризаның электрон формасына кабат кертү өчен кире кайтару;

5) гаризаның электрон рәвеше кырларын гариза бирүче тарафыннан, ЕСИА (БИАС)да урнаштырылган мәгълүматлардан файдаланып, мәгълүматларны кертә башлаганчы тутыру һәм Бердәм порталда, Республика порталында бастырылган мәгълүматларны идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасында булмаган мәгълүматларга кагылышлы өлешендә куллану;

6) элек кертелгән мәгълүматны югалтмыйча, гариза электрон формасын тутыруның теләсә кайсы этапларына кире кайту мөмкинлеге;

7) мөрәҗәгать итүченең республика Порталында элек бирелгән гаризаларга бер елдан да ким булмаган, шулай ук өлешчә формалаштырылган гаризаларга - кимендә 3 ай эчендә керә алу мөмкинлеге.

2.16.4. Мөрәҗәгать итүчеләрнең КФҮ кә кабул итүгә язылуы (алга таба – язылу) Республика порталы, КФҮнең контакт-үзәге телефоны аша башкарыла.

Мөрәҗәгать итүчегә кабул итү өчен теләсә нинди буш вакытка күпфункцияле үзәкнең кабул итү графигының билгеләнгән чикләрендә язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу бу датага кадәр бер тәүлек кала төгәлләнә.

Республика порталы ярдәмендә алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә система тарафыннан соратыла торган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилия, исем, атасының исемен (булган сурәттә);

телефон номерын;

электрон почта адресын (теләк буенча);

теләгән кабул итү датасын һәм вакытын.

Мөрәҗәгать итүче алдан язылу вакытында хәбәр иткән мәгълүматларның шәхси кабул итү вакытында гариза бирүче биргән документлардагы мәглүматларга туры килмәве очрагында алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда мөрәҗәгать итүчегә талон-раслауның распечаткасын алу мөмкинлеге бирелә.

Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын хәбәр итсә, күрсәтелгән адреска, кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда гариза бирүчегә мәҗбүри рәвештә, билгеләнгән кабул итү вакытына килмәгән очракта кабул итү вакытыннан 15 минут узгач, алдан язылу гамәлдән чыгарылуы турында хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүчедән, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан гайре, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен броньларга кирәк булган вакытлыча интервал дәвамлылыгын исәпләү өчен зарури мәгълүматлар бирүдән башка гамәлләр кылуны таләп итү тыела.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәтләр күрсәткәндәге гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә (гариза бирүчегә) консультация (мәслихәт) бирү;

2) мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар комплектын (тупламын) кабул итү һәм карау;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара гарызнамәләр җибәрү;

4) документларны һәм (яисә) килеп ирешкән мәгълүматларны эшкәртү, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар комплектын (тупламын) формалаштыру;

5) торглар үткәрү һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;

6) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

7) техник хаталарны төзәтү.

### 3.2. Гариза бирүче (мөрәҗәгать итүче) белән консультацияләр үткәрү (мәслихәт бирү)

3.2.1. Административ процедураны үтәүне башлауның нигезе – мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгате.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы урындагы кеше (хезмәткәр) булып тора:

мөрәҗәгать итүче КФҮ кә мөрәҗәгать иткәндә – КФҮ хезмәткәре;

мөрәҗәгать итүченең Органга мөрәҗәгатендә – Органның әйдәүче белгече (алга таба – консультация (мәслихәт) бирү өчен җаваплы урындагы кеше).

3.2.2. Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында консультация сорап КФҮ тә шәхсән һәм телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә консультация бирә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тапшырыла торган документациянең составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча.

Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүматны КФҮ нең http://mfc16.tatarstan.ru сайтыннан ирекле файдалану юлы белән алырга мөмкин.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелә торган документациянең составы, формасы һәм муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча консультация.

3.2.3. Мөрәҗәгать итүче телефон һәм электрон почта аша Органга мөрәҗәгать итәргә, шулай ук Республика порталында, Органның муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында сайтында консультация алырга хокуклы, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тапшырыла торган документациянең составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча.

Консультация бирү өчен җаваплы вазыйфаи зат Регламентның 1.3.4 пункты таләпләре нигезендә мөрәҗәгать итүчегә мәгълүмат бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать кергән көннән алып өч эш көне эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелә торган документациянең составы, формасы һәм муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча консультацияләр.

### 3.3. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар комплектын (тупламын) кабул итү һәм карау

3.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документларны КФҮ яки КФҮнең ераклашкан эш урыны аша кабул итү.

3.3.1.1. Мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамә белән КФҮкә мөрәҗәгать итә һәм Регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны тапшыра.

3.3.1.2. Гаризаларны кабул итүче КФҮ хезмәткәре:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый;

мөрәҗәгать предметын билгели;

документлар бирүче затның вәкаләтләрен тикшерә;

документларның Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен тикшерә;

КФҮнең АМС на гаризаның электрон формасын тутыра;

Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар кәгазь йөрткечтә тапшырылганда, тапшырылган документларны сканерлауны гамәлгә ашыра;

КФҮ нең АМС нан гаризаның распечаткасын ала;

мөрәҗәгать итүчегә тикшерүгә һәм кул куюга тапшыра;

имза салганнан соң кул куелган гаризаны КФҮ нең АМС нда сканерлый;

электрон формада яки электрон рәвештәге сканерланган тәкъдим ителгән документларны КФҮ нең АМС на кертә (йөкли), электрон дело (эш) формалаштыра;

имзаланган гаризаны һәм кәгазь документларның төп нөсхәләрен кире кайтара;

мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү хакында раслама бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: җибәрергә әзер гариза һәм документлар пакеты.

3.3.1.3. КФҮ хезмәткәре мөрәҗәгать итүчедән кабул ителгән документлар пакетын (электрон эшләр пакетлары составында) КФҮ нең структур бүлекчәсенә мөрәҗәгать иткән көннән бер эш көне эчендә электрон формада Органга җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: электрон багланыш системасы ярдәмендә Органга җибәрелгән гариза һәм документлар пакеты (электрон эш).

3.3.2. Республика порталы аша муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәтү өчен документлар кабул итү.

3.3.2.1. Гаризаны Республика порталы аша электрон рәвештә бирү өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

авторизацияне башкара;

электрон гариза формасын (рәвешен) ача;

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган мәгълүматларны үз эченә алган электрон гариза рәвешен тутыра;

документларны электрон формада яисә электрон документлар образларын электрон гариза формасына беркетә (зарурлык булганда);

электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтүнең шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамганы билгели);

хәбәр ителгән мәгълүматларның дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамганы билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасында тиешле төймәгә баса);

электрон гариза Регламентның 2.5.7 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаны җибәрү турында хәбәрнамә ала.

Формалаштырылган гаризаны формат-логик тикшерү гариза бирүче тарафыннан һәр кырның электрон формасы тутырылганнан соң гамәлгә ашырыла. Тиешенчә (дөрес) тутырылмаган электрон гариза кырын ачыклаганда, мөрәҗәгать итүче ачыкланган хатаның характеры һәм аны мәгълүмати хәбәр итү юлы белән турыдан-туры гаризаның электрон формасында бетерү тәртибе турында хәбәр итә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән административ процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә Органга юнәлтелгән электрон эш тора.

3.3.3. Орган тарафыннан документлар тупламын карау.

3.3.3.1. Административ процедураны үтәүне башлауга нигез булып муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм башка документлар килеп ирешү тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы урындагы кеше (хезмәткәр) – әйдәүче белгеч (алга таба – документларны кабул итү өчен җаваплы урындагы кеше).

3.3.3.2. Документлар кабул итү өчен җаваплы урындагы кеше, мөрәҗәгать итүченең Органга гаризасы белән мөрәҗәгать иткән очракта:

мөрәҗәгать предметын билгели;

гариза бирүченең шәхесен тәгаенли;

документлар бирүче затның вәкаләтләрен тикшерә;

регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен тикшерә, тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү үткәрә (документлар күчермәләренең тиешенчә рәсмиләштерелүен, документларда бетереп төзәтүләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм башка килешенмәгән төзәтмәләр булмауны тикшерә);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасында гаризаның электрон формасын тутыра;

регламентның 2.5 пунктында кәгазь йөрткечтәге документларны тапшырганда, тапшырылган документларны сканерлауны гамәлгә ашыра;

гаризаның распечаткасын ала;

мөрәҗәгать итүчегә тикшерү һәм имзалау өчен бирә;

кул куелганнан соң имзаланган гариза сканерлана;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасына электрон формада тәкъдим ителгән документларны яки электрон рәвештәге документларны йөкли, электрон эш формалаштыра;

имзаланган гаризаны һәм кәгазь документларның төп нөсхәләрен гариза бирүчегә кире кайтара;

гариза бирүчегә документларны кабул итү өчен раслама бирә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат мөрәҗәгать итүчегә гаризаны кабул итү өчен киртәләр булу турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, аңа документларны кире кайтара.

3.3.3.3. Документлар кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат, документлар каралуга кергәннән соң:

гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә номер һәм “Документларны тикшерү” статусы бирә;

килеп ирешкән электрон эшләрне, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан кушымта итеп бирелгән электрон формадагы документларны һәм документларның электрон рәвешләрен (образларын) өйрәнә;

документларның комплектлылыгын (тупланганлыгын), документларның электрон образларының (рәвешләренең) укылышын тикшерә;

Бердәм порталга мөрәҗәгать итү юлы белән электрон култамганың чын (дөрес) булу шартларының үтәлүен тикшерә (гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон култамга белән имзаланган электрон документлар рәвешләре тапшырылган очракта).

Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булганда, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын әзерли.

Көчәйтелгән квалификацияле электрон култамганы тикшерү нәтиҗәсендә аның чын булу шартларын үтәмәү ачыкланган очракта, баш тарту турындагы карар проектында аны кабул итүгә нигез булган 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 маддәсе пунктлары булырга тиеш.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проекты, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп (әгәр дә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуның нигезләре мондый документларга карата билгеләнгән таләпләрне бозу белән бәйле булса, документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрдә дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы белешмәләр булган, билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән алдан тәкъдим ителмәгән документлар (мәгълүмат, белешмәләр) исеме турында мәгълүмат булырга тиеш), билгеләнгән тәртиптә электрон документ әйләнеше системасы аша килештерүгә җибәрелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проектын килештерү Регламентның 3.5.3 пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат, гариза кергән көннән алып бер эш көне эчендә гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә гаризаның теркәү номеры, гаризаны алу датасы, файлларның исемнәре, аңа тәкъдим ителгән документлар исемлеге, муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу датасы булган гариза килеп ирешү турында хәбәрнамә җибәрә.

3.3.3.4. Регламентның 3.3.3.1, 3.3.3.3 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

3.3.3.5. Регламентның 3.3.3 пункты белән билгеләнә торган процедуралар гариза карауга кергән көннән бер эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: карауга кабул ителгән документлар тупламы яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты.

### 3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара гарызнамәләр җибәрү

3.4.1. Административ процедураны үтәүне башлау өчен нигез булып мөрәҗәгать итүчедән алынган документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи заттан (хезмәткәрдән) административ процедураны башкаруга вәкаләтле вазыйфаи затның (хезмәткәрнең) алуы тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы урындагы кеше (хезмәткәр) булып җитәкче урынбасары тора (алга таба – ведомствоара гарызнамәләр җибәрү өчен җаваплы урындагы кеше).

3.4.2. Ведомствоара гарызнамәләр җибәрү өчен җаваплы урындагы кеше ведомствоара электрон багланышлар системасы аша (техник мөмкинлек булмаганда – башка ысуллар белән) электрон рәвештә Регламентның 2.6.1 пунктында каралган документларны һәм мәгълүматларны тапшыруга гарызнамәләр формалаштыра һәм җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар карау өчен гариза кабул ителгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: хакимият органнарына һәм (яки) хакимият органнарына буйсынган оешмаларга юлланган гарызнамәләр.

3.4.3. Белешмәләр белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре, ведомствоара электрон багланыш системасы аша кергән гарызнамәләр нигезендә, соратыла торган документларны (мәгълүматны) тапшыралар яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмау турында хәбәрнамәләр юллыйлар (алга таба – кире кагу турында хәбәрнамә).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар документ һәм мәгълүмат бирә торган органга яки оешмага ведомствоара гарызнамә кергән көннән өч көн эчендә башкарыла, әгәр ведомствоара гарызнамәгә җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары федераль законнарда, Россия Федерациясе

Хөкүмәтенең хокукый актларында һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында билгеләнмәсә.

Процедураларның нәтиҗәсе: муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар (мәгълүматлар) яки ведомствоара гарызнамәләр җибәрү өчен җаваплы урындагы кешегә юлланган баш тарту турында хәбәрнамә.

3.4.4. Ведомствоара гарызнамәләр җибәрү өчен җаваплы урындагы кеше:

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле ведомствоара электрон багланышлар системасы аша соратыла торган документларны (мәгълүматларны) яки документ һәм (яки) мәгълүмат булмаганда баш тарту турында хәбәрнамә ала;

Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булганда, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын әзерли.

Административ процедураларның үтәлеш нәтиҗәләре булып тора: муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар (мәгълүматлар).

3.4.5. Регламентның 3.4.2, 3.4.4 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын, шул исәптән гаризаны Регламентның 2.13 пункты нигезендә теркәгән мизгелдән файдаланып, автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

3.4.6. Регламентның 3.4 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны үтәүнең максималь срогы биш эш көне тәшкил итә.

## 3.5.Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү

3.5.1. Административ процедураны башкару өчен нигез булып, ведомствоара гарызнамәләр җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи заттан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның (мәгълүматларның) килеп ирешүе тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы урындагы кеше – җитәкче урынбасары (алга таба – муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы урындагы кеше).

3.5.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

3.5.2.1 Муниципаль мөлкәтне арендага бирү, түләүсез файдалану турында гаризаны караганда, түбәндәге гамәлләрне тормышка ашыра:

административ регламентның 2.8.2.1 пунктында билгеләнгән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, муниципаль мөлкәтне арендага бирү, түләүсез файдалану турында карар проектын әзерләүне гамәлгә ашыра.

регламентның 2.8.2.1 пунктында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрне ачыклаганда, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын әзерли.

3.5.2.2. Субарендага, өченче затларга түләүсез файдалануга муниципаль мөлкәт бирүне килештерү турындагы гаризаны караганда, түбәндәге гамәлләрне башкара.

Административ регламентның 2.8.2.2 пунктында билгеләнгән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, субарендага, өченче затларга түләүсез файдалануга муниципаль мөлкәт бирүне килештерү турында хәбәрнамә проектын әзерләүне гамәлгә ашыра.

Административ регламентның 2.8.2.2 пунктында билгеләнгән баш тарту өчен нигезләр булганда, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын әзерләүне гамәлгә ашыра.

Гаризаларны карау нәтиҗәләре буенча әзерләнгән документлар проектлары вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан аларны имзалауга вәкаләтле вазыйфаи затларга административ регламентның 3.5.3 пунктында каралган тәртиптә килештерүгә, имза салуга тапшырыла.

3.5.2.3. Муниципаль милекне арендага, муниципаль преференция тәртибендә түләүсез файдалануга биргән очракта (кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү максатларында муниципаль преференция бирү очракларыннан тыш), монополиягә каршы органга мондый преференцияне бирү турында Россия Федерациясе законнары нигезендә документлар теркәп гариза бирә.

Шушы пунктның беренче абзацында күрсәтелгән гаризаны монополиягә каршы органга җибәргәндә, муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары монополиягә каршы органга муниципаль преференцияне тәкъдим итүгә ризалык бирү турында гаризаны юллау датасыннан алып Органда монополиягә каршы орган карарын теркәү датасына кадәрге чорга туктатылып тора.

3.5.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен (алга таба - документлар проектлары) проектын килештерү һәм имзалау муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы структура бүлекчә җитәкчесе, Орган җитәкчесе урынбасары, Орган җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Искәртүләре булган документларның әзерләнгән проектлары муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы затка эшләп бетерүгә кайтарыла. Искәртүләре бетерелгәннән соң, документлар проектлары килештерү һәм имзалау өчен кабат тапшырыла.

Орган җитәкчесе документлар проектларын караганда, административ процедураларны үтәү сроклары өлешендә органның урындагы кешеләре тарафыннан административ регламентны үтәүне, аларның эзлеклелеге һәм тулылыгын, вәкаләтле урындагы кешеләрнең электрон документ әйләнеше системасында ярашып эшләүләре булуны тикшерә.

Административ процедураларны үтәү срокларын, аларның эзлеклелеген һәм тулылыгын ачыклау өлешендә тәртип бозулар ачыкланган очракта, Орган җитәкчесе Регламентның 4.3 пункты нигезендә хокук бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту инициативасы белән чыга.

Әлеге пункт белән билгеләнгән административ процедуралар ике эш көне

дәвамында башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: муниципаль мөлкәтне арендага бирү турында шартнамә проекты; муниципаль мөлкәтне түләүсез файдалануга бирү турында шартнамә проекты; муниципаль мөлкәтне субарендага, өченче затларга түләүсез файдалануга бирүне килештерү турында карар; муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар; муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар.

3.5.4. Регламентның 3.5.2, 3.5.3 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

Административ регламентның 3.5 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны үтәүнең максималь срогы дүрт эш көне тәшкил итә.

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү (җибәрү)

3.6.1. Административ процедураны үти башлау өчен нигез – административ процедураны үтәү өчен җаваплы урындагы кеше тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне раслый торган документ алу.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы урындагы кеше булып әйдәүче белгеч (алга таба - документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы урындагы кеше) тора.

Документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы урындагы кеше:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен аталган автоматлаштырылган мәгълүмат системасы документациясен алып бару ярдәмче системасына муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турындагы мәгълүматларны теркәүне һәм кертүне тәэмин итә;

мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән ысул белән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе һәм Органда яисә КФҮ тә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Мөрәҗәгать итүчегә Регламентның 2.3.1 пунктының 1, 2 бүлекләрендә күрсәтелгән шартнамәләр проектларын тапшыру рәсми сайтта торг нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштырылган көннән ун календарь көннән дә иртәрәк булмаган вакытта гамәлгә ашырыла.

Процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, автомат рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Органның вәкаләтле урындагы заты муниципаль хезмәт күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслый торган документка кул куйган көндә башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: мәгълүмат системаларында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыру, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе һәм аны алу ысуллары турында мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) хәбәр итү.

3.6.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү) тәртибе:

3.6.2.1. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт нәтиҗәсен сорап КФҮ кә мөрәҗәгать иткәндә, КФҮ хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә электрон документның кәгазь йөрткечтәге нөсхәсе рәвешендә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирә. Мөрәҗәгать итүче таләбе буенча аңа электрон документның кәгазь йөрткечтәге нөсхәсе белән бергә аны салдырыла торган йөрткечкә яздыру юлы белән электрон документның нөсхәсе бирелә яки мөрәҗәгать итүче адресына электрон почта аша электрон документның нөсхәсе җибәрелә.

Шартнамә проектын имзалау мөрәҗәгать итүче тарафыннан КФҮтә гамәлгә ашырыла.

Шартнамәне имзалаганда КФҮ хезмәткәре документлар имзалаучы затның вәкаләтләрен тикшерә. Гариза бирүченең документларны имзалауга вәкаләтле вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документларны сканерлый.

Мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең документлар имзалауга вәкаләтле вәкиле) шартнамәнең ике нөсхәсен имзалый, арткы яктан үз имзасын куя һәм мөһере белән беркетә (мөрәҗәгать итүче юридик зат булган очракта).

КФҮ хезмәткәре шартнамәне имзалау датасын язып куя һәм мөрәҗәгать итүченең кулына (мөрәҗәгать итүче вәкиленә) бер нөсхәсен бирә. Мөрәҗәгать итүче шартнамәгә кул куйганнан соң, бер эш көненнән дә соңга калмыйча, КФҮ шартнамәләрнең нөсхәләрен Органга җибәрә.

Мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән шартнамә проекты аның тарафыннан имзаланырга һәм КФҮ тә күрсәтелгән шартнамә проектын алган көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча бирелергә тиеш.

Әлеге пункт белән билгеләнгән административ процедуралар мөрәҗәгать итүченең КФҮ регламентында билгеләнгән срокларда килү көнендә чиратлылык тәртибендә башкарыла.

3.6.2.2. Мөрәҗәгать итүче Республика порталы аша муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен сорап мөрәҗәгать иткәндә, мөрәҗәгать итүчегә шәхси кабинетка автомат рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган, Органның вәкаләтле урындагы кешесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон култамгасы белән имзаланган документның электрон үрнәге җибәрелә.

Мөрәҗәгать итүче Республика порталының Шәхси кабинетында көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән шартнамә проектын 30 календарь көн эчендә имзаларга хокуклы.

30 календарь көн узгач, мөрәҗәгать итүчегә шартнамәне имзалау срогы тәмамлану турында мәгълүмат килә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Органның вәкаләтле урындагы кешесе муниципаль хезмәт күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслый торган документка кул куйган көндә башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: Республика порталыннан файдаланып мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүне раслый торган документны юллау (бирү) (шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту).

3.7. Техник хаталарны төзәтү

3.7.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып торган документта техник хата барлыгы беленгән очракта гариза бирүче (мөрәҗәгать итүче) Органга җибәрә:

техник хатаны төзәтү турында гариза (5 нче кушымта);

муниципаль хезмәт нәтиҗәсе буларак гариза бирүчегә бирелгән техник хаталы документ;

техник хата булуны дәлилләүче юридик көчкә ия булган документлар.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән мәгълүматларда техник хатаны төзәтү турында гаризаны мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) почта аркылы (шул исәптән электрон почтаны кулланып) яки Республика порталы яисә КФҮ аша бирә.

3.7.2. Документлар кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, кушымта итеп теркәлгән документлар белән гаризаны терки һәм аларны документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гаризаны теркәү датасыннан бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка карауга юнәлтелгән кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.7.3. Документлар эшкәртүгә җаваплы вазыйфаи зат документларны карый һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм төзәтелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) техник хата булган документның төп нөсхәсен алып калып шәхсән кул куйдырып бирә яки гариза бирүче адресына почта аша (электрон почта ярдәмендә) Органга техник хата булган документның төп нөсхәсен тапшырганда документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хатаны ачыклаганнан яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң ике эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүгә контроль тәртибе һәм формалары

4.1. Җаваплы урындагы кешеләр тарафыннан регламент нигезләмәләрен һәм муниципаль хезмәт күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларны үтәүгә һәм башкаруга, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүгә агымдагы контрольне гамәлгә ашыру тәртибе

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгына һәм сыйфатына контроль мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуын ачыклау һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлүенә тикшерүләр уздыруны, җирле

үзидарә органнары урындагы кешеләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешенә контроль формалары булып торалар:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү.

2) делопроизводствоны алып баруны билгеләнгән тәртиптә уздырылучы тикшерүләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларын үтәүгә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Агымдагы контроль максатларында электрон мәгълүматлар базасында булган белешмәләр, хезмәт урыны корреспонденциясе, административ процедураларны үтәүче урындагы кешеләрнең телдән һәм язма мәгълүматы, тиешле документларны исәпкә алу журналлары һәм башка мәгълүматлар файдаланыла.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм җирле үзидарә органы җитәкчесенә карарлар кабул иткәндә гамәлләрнең башкарылуын тикшереп тору өчен муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр бирелә.

Административ процедураларның срокларын, эзлеклелеген һәм эчтәлеген бозу очраклары һәм сәбәпләре турында урындагы кешеләр кичекмәстән муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенә хәбәр итәләр, шулай ук бозуларны бетерү буенча ашыгыч чаралар күрәләр.

Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контроль муниципаль хезмәт күрсәтү эшен оештыруга җаваплы җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары, муниципаль хезмәт күрсәтү эшен оештыручы бүлек башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы урындагы кешеләр исемлеге җирле үзидарә органының структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

## 4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфаты буенча планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне гамәлгә ашыру тәртибе һәм периодиклыгы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.2.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору түбәндәгеләр рәвешендә гамәлгә ашырыла:

1) тикшерүләр уздыру;

2) мөрәҗәгать итүчеләрнең органның, шулай ук аларның урындагы кешеләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләрен карау.

4.2.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору максатларында планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрелә. Планлы

тикшерүләрне уздыру тәртибе һәм ешлыгы (периодиклыгы) Органның эш планы белән билгеләнә. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле барлык мәсьәләләр (комплекслы тикшерүләр) яисә мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча каралырга мөмкин. Тикшерү шулай ук мөрәҗәгать итүченең конкрет шикаяте буенча үткәрелергә мөмкин.

4.2.3. Планнан тыш тикшерүләр алдан ачыкланган хокук бозуларны бетерү белән бәйле рәвештә үткәрелә, шулай ук Орган гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүчеләрнең шикаятьләре алынган очракта, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең.

4.2.4. Тикшерү нәтиҗәләре тикшерү акты рәвешендә рәсмиләштерелә, анда ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәр күрсәтелә.

4.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында үзләре тарафыннан кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен муниципаль хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затларының (урындагы кешеләренең) җаваплылыгы

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылган очракта гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

Җирле үзидарә органы җитәкчесе гариза-мөрәҗәгатьләрне вакытында тикшермәгән өчен җаваплы.

Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (җитәкче урынбасары) Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яисә) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә торган (гамәлгә ашырыла торган) карар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр законнарда билгеләнгән тәртиптә җаваплы булалар.

4.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне тикшереп тору тәртибенә һәм рәвешләренә таләпләрне сыйфатлаучы нигезләмәләр, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан да.

Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне тикшереп тору (контроль) муниципаль хезмәт күрсәткәндә җирле үзидарә органы эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

**5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә күрсәтелгән**

**оешмаларның, шулай ук аларның урындагы кешеләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе**

5.1. Муниципаль хезмәт алучылар муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган хезмәткәренең, җитәкчесенең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр тәртиптә шикаять бирү хокукына ия.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 маддәсендә күрсәтелгән гарызнамәне, муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гарызнамәне теркәү срокларын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, аның хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда тапшыру яисә гамәлгә ашыру каралмаган документларны яки мәгълүматны яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гамәлләр кылуны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда баш тарту нигезләре күздә тотылмаган булуга карамастан муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, аның хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин;

6) муниципаль хезмәт күрсәтүдә гариза бирүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, муниципаль район норматив хокукый актларында күздә тотылмаган түләүне таләп итү;

7) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмалар яисә аларның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хата һәм ялгышларны төзәтүне кире кагуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, аның хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирүнең срогын яисә тәртибен бозу;

9) федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары, муниципаль районның норматив хокукый актларында муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатуга нигезләр күздә тотылмаган булуга карамастан, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату (туктатып тору);

Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, аның хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин;

10) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны баштагы кабул итүдәге кире кагуда юклыгы һәм (яки) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүматны муниципаль хезмәт күрсәтүдә, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ Федераль законның 7 маддәсе 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан гайре, мөрәҗәгать итүчедән таләп итү.

Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, аның хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин.

2. Шикаять язма рәвештә кәгазь йөрткечтә, электрон рәвештә муниципаль хезмәтне күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә яки күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы тиешле дәүләт хакимияте органына (алга таба – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы), шулай ук 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларга тапшырыла. Муниципаль хезмәтне күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр югарырак органга (ул булган очракта) бирелә яки ул булмаган очракта турыдан-туры муниципаль хезмәтне күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала. Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр шушы күпфункцияле үзәк җитәкчесенә бирелә. Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәкне оештыручыга яисә Татарстан Республикасының норматив хокукый акты белән вәкаләтле вазыйфаи затка тапшырыла. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр әлеге оешмалар җитәкчеләренә бирелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аркылы, күпфункцияле үзәк аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайтыннан, Бердәм порталдан яисә республика порталыннан, судка кадәр шикаять бирү мәгълүмат системасыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәкнең, Бердәм порталның яисә Республика порталының рәсми сайтыннан, судка шикаять бирүнең мәгълүмат системасы аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1 өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, әлеге оешмаларның, Бердәм порталның яисә Республика порталының рәсми сайтларыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесе һәм (яисә) хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның җитәкчеләре һәм (яисә) хезмәткәрләренең исемнәрен (аталышларын);

2) мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), гариза бирүченең – физик затның яшәү урыны турында мәгълүматлар, гариза бирүченең – юридик затның урнашу урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (булган очракта) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы (булганда);

3) муниципаль хезмәтне күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүче алар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешми торган дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аның дәлилләрен раслаучы документлар (булганда) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.4. Килеп ирешкән шикаять кергән көннән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш.

5.5 Муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларга яисә югарырак органга (ул булганда) кергән шикаять теркәлгән көннән алып унбиш эш көне эчендә каралырга тиеш, ә муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларга карата шикаять белдерелгән очракта мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдә яки җибәрелгән хата һәм ялгышларны төзәтүдә яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылган очракта – аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.6.Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның кайсы да булса берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә түләтү Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартырга.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең

теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.7. Шикаятьнең канәгатьләндерелергә тиешле дип танылу очрагында мөрәҗәгать итүчегә шикаятьне карау нәтиҗәләре турындагы җавапта муниципаль хезмәт күрсәткәндә беленгән бозуларны кичекмәстән бетерү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмалар тарафыннан тормышка ашырылучы гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук күрсәтелгән уңайсызлыклар өчен кичерү сорала һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне алу максатларында гариза бирүчегә кылу зарур булган алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаятьнең канәгатьләндерелергә тиешле түгел дип табылу очрагында мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре хакында дәлилле аңлатмалар бирелә, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат китерелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре табылу очрагында шикаятьләрне карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрәләр.

Социаль наем шартнамәсе нигезендә
торак урыны бирү буенча муниципаль
хезмәт күрсәтүнең административ
регламентына кушымта №1

**ТОРАК УРЫННЫ СОЦИАЛЬ НАЕМГА**
**ҮРНӘК ШАРТНАМӘ № ___**

_____________________________________________ __ _______________, 202_ ел
(муниципаль берәмлек исеме) (дата, ай, ел)

___________________________________________________________________________,
(Россия Федерациясе дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы яисә милекче тарафыннан вәкаләт бирелгән бүтән зат исеме)

___________________________________________________________________________ торак урын милекчесе исеменнән эш итүче ____________________
(милекчене күрсәтергә: Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлек)
түбәндәге документ нигезендә ____________________________ "__" __________ел, № ___,
(вәкаләтле документның аталышы)
алга таба Файдалануга бирүче (наймодатель) дип аталучы, бер яктан, һәм гражданин ___________________________________________________________,
(фамилия, исеме, атасының исеме)
алга таба Яллаучы (наниматель) дип аталучы, икенче яктан, торак урын бирү турындагы түбәндәге карар нигезендә "__" ________, 200_ел, № ____
бу шартнамәне түбәндәгеләр хакында төзеделәр.

I. Шартнамә предметы

1. Файдалануга бирүче яллаучыга һәм аның гаилә әгъзаларына аерым (ялгыз) торак урынны вакыты чикләнмәгән биләүгә һәм файдалануга тапшыра, ул түбәндәгенең милкендә __________
___________________________________________________________________________
(дәүләт, муниципаль – тиешлесен күрсәтергә)
Ул _____________фатирдагы (йорттагы) ___ бүлмәдән тора, гомуми мәйданы ____ кв.м, шул исәптән торак мәйданы ____ кв.м. Адресы: ________________________, йорт № _________, корпус № _____________, фатир № ____________, анда яшәү өчен, шулай ук хак түләү бәрабәренә коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итә:_______________________________________
_______________________________________________________ (электр белән тәэмин итү, газ белән тәэмин итү, шул исәптән
___________________________________________________________________________
баллонлы газ, салкын су белән тәэмин итү, су агызу (субүлү)_____________________________
__________________________________________________
(канализация), кайнар су белән тәэмин итү һәм җылылык белән тәэмин итү (җылылык),
___________________________________________________________________________
шул исәптән каты ягулык сатып алу һәм китерү___________________________________________
_____________________________.
мичкә ягу булганда - тиешлесен күрсәтергә)

2. Бирелә торган торак урынының, аның техник халәтенең, шулай ук андагы санитар-техник һәм башка җиһазларның сыйфатламасы торак урынның техник паспортында күрсәтелгән.

3. Яллаучы белән бергә торак урынга гаиләнең түбәндәге әгъзалары урнаша:
1) ________________________________________________________________;
(гаилә әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм яллаучы белән туганлык дәрәҗәсе)
2) ________________________________________________________________;
(гаилә әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм яллаучы белән туганлык дәрәҗәсе)
3) ________________________________________________________________.

(гаилә әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм яллаучы белән туганлык дәрәҗәсе)

## II. Якларның бурычлары

4. Яллаучы тиеш:

а) Файдаланучы бирүчедән әлеге шартнамәгә кул куелганнан соң 10 көннән дә артмаган срокта агымдагы ремонт үткәрелгән яшәү өчен яраклы торак урынын кабул итәргә, торак урын яңа файдалануга тапшырылган торак фондыннан бирелгән очраклардан тыш (актта торак урын тапшырыла торган социаль наем шартнамәсен төзү датасы, шартнамә яклары һәм аларның реквизитлары, торак бинаның төзеклеге, шулай ук актка кул куелган вакытка анда булган санитар-техник һәм башка җиһазлар турында мәгълүматлар, агымдагы ремонт үткәрү датасы, торак бинаның яшәү өчен яраклылыгы турында мәгълүматлар, акт төзегән якларның имзалары булырга тиеш);

б) торак биналардан файдалану кагыйдәләрен үтәргә;

в) торак урыннан аның билгеләнеше нигезендә файдаланырга;

г) торак урынны, санитар-техник һәм андагы башка җиһазларны төзек хәлдә тотарга, аларның сакланышын тәэмин итәргә. Торак бинада яисә андагы санитар-техник һәм башка җиһазларның төзексезлеге ачыкланганда, аларны бетерү буенча кичекмәстән мөмкин булган чараларны күрергә һәм кирәк булган очракта алар турында Файдаланучы бирүчегә яисә тиешле идарәче оешмага хәбәр итәргә;

д) торак урынны, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне, төзекләндерү объектларын чиста хәлдә һәм тәртиптә тотарга;

е) биләгән торак урынына агымдагы ремонт ясарга;

Яллаучы биләгән торак бинаны үз хисабына башкара торган агымдагы ремонтлауга түбәндәге эшләр керә: агарту, стеналарны, түшәмнәрне, идәннәрне буяу һәм ябыштыру, ишекләрне, тәрәзә төпләрен, эчке яктан тәрәзәләрне, радиаторларны буяу, шулай ук тәрәзә һәм ишек приборларын алыштыру, фатир эчендәге инженерлык җиһазларын ремонтлау (электр үткәргечләр, салкын һәм кайнар су белән тәэмин итү, җылылык, газ белән тәэмин итү).

Әлеге эшләрне башкару күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтнең конструктив элементларының яки андагы җиһазларның төзек булмавы аркасында килеп чыккан очракта яисә йортка капиталь ремонт ясау белән бәйле булса, алар файдаланучы бирүче хисабына ул тәкъдим иткән оешма тарафыннан башкарыла;

ж) торак урынны, Россия Федерациясенең торак законнарында каралган тиешле килештерүне алмыйча, үзгәртеп кормаска һәм (яисә) яңадан планлаштырмаска;

з) Россия Федерациясе законнары нигезендә расланган бәяләр һәм тарифлар буенча торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүне үзвакытында һәм тулы күләмдә кертергә.

Билгеләнгән вакытка торак урын һәм (яки) коммуналь хезмәтләр өчен түләү кертмәгән очракта, яллаучы файдаланучы бирүчегә Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнгән күләмдә пеня түли, бу яллаучыны тиешле түләүләрне түләүдән азат итми;

и) Россия Федерациясе Торак кодексы белән билгеләнгән тәртиптә, ул яши торган йортны капиталь ремонтлау яки реконструкцияләү вакытында үз гаиләсе әгъзалары белән Файдаланучы бирүче тарафыннан санитар һәм техник таләпләргә җавап бирә торган торак бинага күченеп торырга (ремонт яки реконструкция яллаучыны күчермичә генә башкарыла алмаганда);

к) Әлеге шартнамәне өзгәндә билгеләнгән вакытта төзек хәлдә торак бинаны бушатырга һәм Файдаланучы бирүчегә андагы санитар-техник һәм башка җиһазларны тапшырырга, яллаучы тарафыннан җитештерелмәгән һәм аның вазыйфасына керүче торак урынны, андагы санитар-техник һәм башка җиһазларны ремонтлауның бәясен түләргә яки аны үз исәбенә башкарырга, шулай ук торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычларны капларга;

л) әлеге шартнамәнең яклары тарафыннан алдан килештерелгән вакытта Файдаланучы бирүченең хезмәткәрләрен яисә ул вәкаләт биргән затларны, торак бинаның техник һәм санитария торышын, андагы санитар-техник һәм башка җиһазларны карау өчен дәүләт

күзәтчелеге һәм контроль органнары вәкилләрен торак урынына кертергә, шартнамә өзелгән очракта, кирәкле ремонт эшләрен башкару өчен, ә килеп чыккан һәлакәтләрне бетерү өчен – теләсә кайсы вакытта;

м) социаль наем шартнамәсе буенча торак урыныннан файдалану хокукын бирә торган нигезләрнең һәм шартларның үзгәрүе турында Файдалануга бирүчегә мондый үзгәреш кертелгәннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә;

н) Россия Федерациясе Торак кодексында һәм федераль законнарда каралган башка бурычларны үтәргә.

5. Файдалануга бирүче тиеш:

а) әлеге шартнамәгә кул куйган көннән алып 10 көн эчендә яллаучыга башка затларның хокукларыннан ирекле һәм яшәү өчен яраклы, янгын куркынычсызлыгы таләпләренә, санитария-гигиена, экология һәм башка таләпләргә җавап бирә торган халәттәге торак урынны тапшырырга;

б) социаль наем шартнамәсе буенча тапшырылган торак урыны урнашкан күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тиешле тәртиптә тотуда һәм ремонтлауда катнашырга;

в) торак бинага капиталь ремонт ясарга.

Файдалануга (наемга) бирелгән торак урынны, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне, торак бинада урнашкан санитар-техник һәм башка җиһазларны вакытында ремонтлауны Файдалануга бирүче башкармаган яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, яллаучы үз теләге (сайлавы) буенча торак урын өчен түләүне киметүне яисә күпфатирлы йорттагы торак урынның һәм (яисә) гомуми мөлкәтнең җитешсезлекләрен бетерү чыгымнарын каплау яисә Файдалануга бирүче тарафыннан күрсәтелгән йөкләмәләрне тиешенчә үтәмәгән яисә үтәмәгәнлектән килгән зыяннарны каплауны таләп итәргә хаклы;

г) Яллаучыга һәм аның гаилә әгъзаларына Россия Федерациясе Торак кодексында каралган тәртиптә йортны капиталь ремонтлау яисә реконструкцияләү чорына (ремонт яки реконструкция Яллаучыны күчермичә генә башкарыла алмаганда) маневр фондының санитария һәм техник таләпләргә җавап бирә торган торак урынын бирергә.

Яллаучыны һәм аның гаилә әгъзаларын маневр фондының торак бүлмәсенә һәм киредән күчерү (капиталь ремонт яисә реконструкция тәмамланганнан соң) Файдалануга бирүче хисабына башкарыла;

д) эшләр башланганчы 30 көннән дә соңга калмыйча Яллаучыга капиталь ремонт яисә реконструкция үткәрү турында хәбәр бирергә;

е) өйне, андагы санитар-техник һәм башка җиһазларны кышкы шартларда файдалануга вакытында әзерләүдә катнашырга;

ж) Яллаучыга әлеге шартнамәдә каралган коммуналь хезмәтләрне тиешле сыйфатта күрсәтүне тәэмин итәргә;

з) күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын контрольдә тотарга;

и) торакны карап тоту, ремонтлау, торак урыннарны яллауга, коммуналь хезмәтләргә, торак-коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен куллану нормативлары, исәп-хисап тәртибенә тарифлар үзгәргәннән соң 3 эш көне эчендә бу хакта Яллаучыга хәбәр итәргә;

к) хезмәтләр күрсәткән һәм тиешле булмаган сыйфатлы эшләр башкарган һәм (яисә) билгеләнгән дәвамлылыктан артып киткән өзеклекләр булган очракта торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүне яңадан санауны башкарырга яисә вәкаләтле затка йөкләргә;

л) әлеге шартнамә өзелгәннән соң Яллаучыдан билгеләнгән срокларда файдалануга тапшыру акты буенча торак урынын кабул итәргә;

м) Россия Федерациясе законнарында каралган башка бурычларны үтәргә.

### III. Якларның хокуклары

6. Яллаучы хаклы:

а) күпфатирлы йортның гомуми мөлкәтеннән файдаланырга;

б) биләгән торак урынга Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә башка затларны кертергә, вакытлыча яшәүчеләргә торак урынында яшәргә рөхсәт итәргә, торак

урынын яллауга тапшырырга, белгән торак урынын алмаштырырга яки алыштырырга. Балигъ булмаган балаларны ата-аналары янына урнаштыруга (кертүгә) гаиләнең башка әгъзаларының һәм Файдалануга бирүченең ризалыгы таләп ителми;

в) үзе һәм гаилә әгъзалары вакытлыча булмаганда торак урынга хокукны саклап калу;

г) Файдаланута бирүчедән торак бинаны вакытында капиталь ремонтлауны, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тотуда тиешенчә катнашуны, шулай ук әлеге шартнамәдә каралган тиешле сыйфаттагы коммуналь хезмәтләр күрсәтүне таләп итәргә;

д) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда, яллаучы белән бергә яшәүче гаилә әгъзаларының язмача ризалыгы белән әлеге шартнамәне үзгәртүне таләп итәргә;

е) Яллаучы белән бергә яшәүче гаилә әгъзаларының язмача ризалыгы белән теләсә кайсы вакытта әлеге шартнамәне өзәргә;

ж) Россия Федерациясе Торак кодексында һәм федераль законнарда каралган торак урыннан файдалану буенча башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

7. Яллаучы гаиләсенең аның белән бергә яшәүче әгъзалары үзе белән әлеге шартнамәдән килеп чыга торган хокук һәм бурычларда тигез хокуклы. Гаиләнең хокукка сәләтле әгъзалары Яллаучы белән әлеге шартнамәдән килеп чыга торган йөкләмәләр буенча теләктәшлек күрсәтә.

8. Файдалануга бирүче хаклы:

а) торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүне үз вакытында кертүне таләп итәргә;

б) әлеге шартнамәнең яклар тарафыннан алдан килештерелгән үз хезмәткәрләренең яисә вәкаләтле затларның торак бинаның техник һәм санитария торышын, андагы санитар-техник һәм башка җиһазларны карау өчен, кирәкле ремонт эшләрен башкару өчен, шартнамә өзелгән очракта, ә аварияләрне бетерү өчен теләсә кайсы вакытта торак урынына кертүне таләп итәргә;

в) әгәр күчену очрагында гаиләнең 1 әгъзасына туры килә торган торак урынының гомуми мәйданы исәпкә алу нормасыннан азрак килеп чыкса, яллаучы биләп торган торак урынына гражданнарның аның белән бергә яшәүче гаилә әгъзалары буларак күченүен тыярга.

## IV. Шартнамәне үзгәртү, өзү һәм туктату тәртибе

9. Әлеге шартнамә яклар килешүе буенча Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә теләсә кайсы вакытта үзгәртелергә яисә өзелергә мөмкин.

10. Яллаучы һәм аның гаилә әгъзалары башка яшәү урынына күченгәндә, әлеге шартнамә чыгып китү көненнән өзелгән дип санала.

11. Файдалануга бирүче таләбе буенча әлеге шартнамә суд тәртибендә түбәндәге очракларда өзелергә мөмкин:

а) торак бинаны яллаучының билгеләнеше (аталуы) буенча файдаланмавы;

б) торак бинаны яллаучы яисә башка гражданнар тарафыннан җимерү яки зыян китерү, ул гамәлләр өчен яллаучы җавап бирә;

в) күршеләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен системалы рәвештә бозу, ул бер торак бинада бергә яшәү мөмкинлеген чикли;

г) Яллаучының торак урыны һәм (яисә) коммуналь хезмәтләр өчен 6 айдан артык түләмәве.

12. Әлеге шартнамә суд тәртибендә Россия Федерациясе Торак кодексында каралган башка очракларда өзелергә мөмкин.

## V. Башка шартлар

13. Әлеге шартнамә буенча яклар арасында барлыкка килергә мөмкин булган бәхәсләр Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә хәл ителә.

14. Әлеге шартнамә 2 нөсхәдә төзелде, аларның берсе Файдалануга бирүчедә, икенчесе Яллаучыда.

Файдалануга бирүче__________________ Яллаучы __________________________

(имза) (имза)

М.У.

Социаль наем шартнамәсе нигезендә торак урыны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кушымта №2

Рәвеш

(Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган бланкы)

Кемгә: ___________________________
_________________ _________________
Контакт мәгълүматлары:
_______________ _________________
Вәкил: ___________________
_________________ _________________
Вәкилнең контакт мәгълүматлары:
__________________________________

Социаль наем шартнамәсе нигезендә торак урыны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында

КАРАР

20 ___ елның ____ __________ № _____

Сезнең 20 ___ елның ____ _____________ ____номерлы гаризагызны һәм аңа теркәлгән документларны карау нәтиҗәләре буенча ________________________ вәкаләтле орган тарафыннан түбәндәге нигезләр буенча социаль наем шартнамәсе нигезендә торак урыны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

1. _______________________________________________________________
2. _______________________________________________________________

Кире кагу сәбәпләренә аңлатма: ________________________________________
Өстәмә мәгълүмат: __________________________________________

Күрсәтелгән (хокук) бозулар бетерелгәннән соң хезмәт күрсәтү турында гариза белән сез вәкаләтле органга кабаттан мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Әлеге кире кагу судка кадәр шикаятьне вәкаләтле органга җибәрү юлы белән, шулай ук суд тәртибендә шикаять ителергә мөмкин.

Вазыйфаи зат (урындагы кеше) (ФИАи)

| Электрон имза турында мәгълүматлар |
|---|

______________________________________

(органның вәкаләтле вазыйфаи заты имзасы)

Социаль наем шартнамәсе нигезендә торак урыны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кушымта №3

Рәвеш

______________________________________________

(муниципаль берәмлекнең

______________________________________________

җирле үзидарә органы исеме (аталышы))

______________________________________________

______________(алга таба — мөрәҗәгать итүче)

(физик затлар өчен - фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт мәгълүматлары, яшәү урыны буенча теркәлү, телефон)

Муниципаль милектәге торак урынны гражданга социаль наем шартнамәсе буенча бирү турында
ГАРИЗА

Социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирүегезне сорыйм.

Торак урынының адресы: ________________________муниципаль районы (шәһәр округы), _________________________(торак пункт), ___________урамы,____йорт.

Гаризага түбәндәге сканерланган документлар теркәлә:

1) Мөрәҗәгать итүче граждан һәм аның гаилә әгъзаларының паспортларының яисә шәхесне таныклый торган башка документларының күчермәләре;

2) Мөрәҗәгать итүче гражданның гаилә составы турындагы документларның күчермәләре (туу турында таныклык, никахлашу турында таныклык, уллыкка (кызлыкка) алу турында карар, гаилә әгъзасы итеп тану турында суд карары һ.б.).

3) Мөрәҗәгать итүче граждан һәм аның гаилә әгъзалары биләгән торак урыннан файдалану хокукынраслый торган документларның күчермәләре (шартнамә, ордер, торак урын бирү турында карар һәм башка документлар);

4) Мөрәҗәгать итүчене яисә аның гаилә әгъзасын торак законнары нигезендә чиратсыз торак урыны бирү хокукына ия гражданнар категориясенә кертергә нигез бирә торган документлар:

- медицина оешмасыннан медицина белешмәсе – гражданның гаиләсе составында хроник чирнең авыр формасы белән интегүче хаста булып, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы раслаган исемлек буенча аның белән бер фатирда бергә яшәү мөмкин булмаган очракта;

- опекун билгеләү турында опека һәм попечительлек органнарыннан белешмә - хокукый сәләтсез граждан исеменнән эш итүче опекун тарафыннан исәпкә алу турында гариза имзаланган очракта;

- ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларның статусын раслый торган документлар, алар мәгариф һәм башка оешмаларда булу тәмамланганнан соң, шул исәптән социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында, тәрбиягә алган гаиләләрдә, гаилә тибындагы балалар йортларында, опеканы (попечительлекне) туктатканда, шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәт тәмамланганнан соң яисә иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтү учреждениеләреннән кайтканнан соң;

5) Йорт кенәгәсеннән өземтә (документ коммерция оешмалары тарафыннан бирелгән очракта);

6) Мөрәҗәгать итүче граждан һәм аның гаилә әгъзалары биләгән торак урыннан файдалану хокукын раслый торган документларның күчермәләре (шартнамә, ордер, торак урын бирү турында карар һәм башка документлар);

7) 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12, 18, 19 маддәләрендә күрсәтелгән башка документлар (гражданнарны аз керемле дип тану өчен).

Гарызнамә булганда сканерланган документларның төп нөсхәләрен бирүне үз өстемә алам.

________________ ____________ __________________________________________

(дата) (имза) (ФИАи)

Социаль наем шартнамәсе нигезендә
торак урыны бирү буенча муниципаль
хезмәт күрсәтүнең административ
регламентына кушымта №4

Рәвеш

(Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган бланкы)

Кемгә: ___________________________
________________ ________________
Контакт мәгълүматлары:
______________ ________________
Вәкил: __________________
________________ ________________
Вәкилнең контакт мәгълүматлары:
_________________________________

Социаль наем шартнамәсе нигезендә торак урын бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында
КАРАР

20 ___ елның ____ _________ № _____

Сезнең 20 ___ елның ____ ______________ ____номерлы гаризагызны һәм аңа теркәлгән документларны карау нәтиҗәләре буенча ________________________
вәкаләтле орган тарафыннан түбәндәге нигезләр буенча социаль наем шартнамәсе нигезендә торак урын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

1. ______________________________________________________________
2. ______________________________________________________________

Өстәмә мәгълүмат: ________________________________________

Күрсәтелгән (хокук) бозулар бетерелгәннән соң хезмәт күрсәтү турында гариза белән сез вәкаләтле органга кабаттан мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Әлеге кире кагу судка кадәр шикаятьне вәкаләтле органга җибәрү юлы белән, шулай ук суд тәртибендә шикаять ителергә мөмкин.

| Электрон имза турында мәгълүматлар |
| --- |

Вазыйфаи зат (урындагы кеше) (ФИАи) ______________________________

(органның вәкаләтле вазыйфаи заты имзасы)

Социаль наем шартнамәсе нигезендә торак урыны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кушымта №5

Башкарма комитет җитәкчесе
______________________________
____________________________

техник хатаны төзәтү турында
ГАРИЗА.

_______________________________________________муниципаль хезмәт
(күрсәтелгән хезмәтнең исеме)
күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

Язылган:______________________________________________________________
__________________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар:_____________________________________________________________
______________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып торган документка тиешле үзгәрешләрне кертүне үтенәм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.
3.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кире кагу хакында карар кабул иткән очракта андый карарны җибәрүне үтенәм:

электрон документны E-mail_______________адресына җибәрү ярдәмендә; почта аша кәгазь йөрткечтә расланган күчермә рәвешендә түбәндәге адрес буенча: ________________________________________________________________ ___

Әлеге гариза белән раслыйм: гаризадагы минем шәхескә һәм минем тарафтан тәкъдим ителүче затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры киләләр, гаризаны бирү моментына бу документлар чын һәм дөрес мәгълүматларны үз эчләренә алалар.

_______________ ___________________ ( __________________)
(дата) (имза) (Ф.И.А.и.)

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Балык Бистәсе шәһәр
җирлеге Башкарма комитетының
2022 елның 31 мартындагы
29 номерлы карарына
кушымта №4

**Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру документларын рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Административ регламентны җайга салу предметы

1.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру документларын рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең (алга таба – муниципаль хезмәт) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.1.2. Административ регламент нигезләмәләре Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге территориясендә социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән муниципаль торак фондының торак урыннарына карата кулланыла.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре

1.2.1. Муниципаль хезмәтне алуга хокуклы затлар – физик затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче, гариза бирүче).

1.2.2. Гариза белән мөрәҗәгать итүче вәкиле, аның вәкаләтләрен таныклаучы документ нигезендә эш итүче яки физик затның законлы вәкиле (алга таба – мөрәҗәгать итүче вәкиле) мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мәгълүмат бирү (хәбәр итү) тәртибе

1.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат урнаштырыла:

1) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре биналарында урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендларында;

2) муниципаль районның “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге https://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru/ рәсми сайтында;

3) Татарстан Республикасының https://uslugi.tatarstan.ru дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр Порталында (алга таба – Республика порталы);

4) http:// www.gosuslugi.ru Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләр) порталында (алга таба – Бердәм портал);

5) “Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры” дәүләт мәгълүмат системасында (http://frgu.tatar.ru) (алга таба – Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры).

1.3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча консультация (мәслихәт) бирү гамәлгә ашырыла:

1) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яисә телефон буенча;

2) Республика порталының интерактив рәвешендә;

3) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетында (алга таба – Орган):

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яисә телефон буенча;

язма рәвештә (шул исәптән электрон документлар рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә – кәгазь йөрткечтә почта аша, электрон рәвештә электрон почта аша.

1.3.3. Бердәм порталда, Республика порталында Республика реестрындагы мәгълүматлар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат гариза бирүчегә бушлай бирелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка мөрәҗәгать итүченең нинди дә булса таләпләр үтәмичә генә, шул исәптән, мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштыру гариза бирүчедән түләү алуны, теркәүне яисә авторизацияне күздә тотучы программа тәэмин ителешенең хокук иясе белән лицензияле яисә башка килешү төзүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча яисә аларга шәхси мәгълүматлар бирмичә керү мөмкинлеге гамәлгә ашырыла.

1.3.4. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә телефон аша мөрәҗәгать иткәндә кергән мөрәҗәгать нигезендә түбәндәге мәгълүмат бирелә:

7) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, Органның урнашкан урыны турында (адресы, эш графигы, белешмә телефоннары);

8) муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында, гаризалар бирү ысуллары һәм сроклары турында;

9) муниципаль хезмәт күрсәтелә торган гражданнар категорияләре турында; муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләрен җайга сала торган норматив хокукый актлар турында;

10) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны карау өчен кирәкле документлар исемлеге турында, гаризаны кабул итү һәм теркәү сроклары турында;

11) муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында;

12) муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүматның рәсми сайтында урнашу урыны турында;

7) органның вазыйфаи затларының гамәлләренә яисә гамәл кылмауларына карата шикаять белдерү тәртибе турында.

Язма мөрәҗәгать буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы бүлекнең вазыйфаи затлары мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен һәм регламентның әлеге пунктында күрсәтелгән мәсьәләләрне язма рәвештә аңлаталар һәм мөрәҗәгатьне теркәгәннән соң өч эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрәләр. Җаваплар мөрәҗәгать иткән телдә бирелә. Мөрәҗәгать иткән телдә җавап бирү мөмкин булмаган очракта Татарстан Республикасы дәүләт телләре кулланыла.

1.3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат муниципаль районның рәсми сайтында һәм Орган бүлмәләрендәге гариза бирүчеләр белән эшләү өчен куелган мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

“Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге муниципаль районның рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларында урнаштырылган Татарстан Республикасы Дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге Регламентның 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы үзидарәлек хезмәте турындагы мәгълүматларны, Органның урнашу урыны, белешмә телефоннары, эш вакыты, муниципаль хезмәт күрсәтүгә гаризалар кабул итү графигы турында мәгълүматны үз эченә ала.

## 1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге

1.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актлар реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп) Бердәм порталда, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта, Республика реестрында урнаштырылган.

1.4.2. Гамәлдәге редакциядә административ регламент тексты Бердәм порталда, Республика реестрында, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштырылырга тиеш.

## 1.5. Административ регламентта кулланыла торган терминнар һәм аларның билгеләмәләре

1.5.1. Регламентта түбәндәге атамалар (терминнар) һәм билгеләмәләр файдаланыла:

дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтү күпфункцияле үзәгенең ераклашкан эш урыны – 2012 елның 22 декабрендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтү күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләрен раслау турында” 1376 номерлы карары белән расланган дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтү күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районының шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр

округында төзелгән дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтү күпфункцияле үзәгенең территория ягыннан аерымланган структура бүлекчәсе (офисы);

техник хата – үзидарәлек хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка кертелгән (үзидарәлек хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсенә) мәгълүматларга тәңгәл булмауга, алар нигезендә кертелгән мәгълүматларның документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китерүче ялгыш (ялгышлык белән җибәрелгән хәреф, сүз хатасы, грамматик яки арифметик хата яисә шуларга охшаш ялгышлыклар).

Электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик үзара хезмәттәшлеген (багланышын) тәэмин итүче инфраструктурада идентификацияләүнең (бердәйләштерүнең, тәңгәлләштерүнең) һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы (алга таба – ЕСИА (Единая система идентификации и аутентификации)) – дәүләт мәгълүмат системаларында һәм башка мәгълүмат системаларында булган мәгълүматны идентификацияләү һәм аутентификацияләү системасында мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучыларның санкцияләнгән файдалана алуын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы;

КФҮ – “Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге” дәүләт бюджет учреждениесе;

КФҮ нең АМС – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы.

1.5.2. Регламентта муниципаль (үзидарәлек) хезмәте күрсәтү турындагы гариза дигәндә (алга таба – гариза) үзидарәлек хезмәте күрсәтү турында “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 маддәсенең 3 пункты (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә бирелгән гарызнамә (рәсми таләп) аңлашыла.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

### 2.1. Муниципаль хезмәтнең аталышы

Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру документларын рәсмиләштерү

### 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарәнең башкарма-боеручы органының исеме (аталышы)

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты

### 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау

2.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып тора:

6) торак урыннарын алмаштыру шартнамәсе;

7) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар (әлеге административ регламентка 1 нче кушымта);

8) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар (әлеге административ регламентка 2 нче кушымта).

2.3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе “Электрон имза турында” 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә мөрәҗәгать итүчегә Бердәм порталның шәхси кабинетына Органның вәкаләтле вазыйфаи затының (яисә Органның) көчәйтелгән квалификацияле электрон култамгасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

Гариза Республика порталы ярдәмендә җибәрелгән очракта муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе Республика порталының шәхси кабинетына да җибәрелә.

2.3.3. Мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе Органда яки КФҮтә кәгазьдә йөрткечтәге электрон документ нөсхәсе рәвешендә бирелә, ул тиңдәшле рәвештә Органның вәкаләтле вазыйфаи заты яисә КФҮ хезмәткәре имзасы һәм мөһер белән таныкланган була.

2.3.4. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәтне күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең гамәлдә булу срогы дәвамында алырга хокуклы.

## 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы

2.4.1. Муниципаль хезмәт унөч эш көне эчендә күрсәтелә.

2.4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктату каралмаган.

2.4.3. Электрон документ рәвешендә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документны җибәрү муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

## 2.5. Үзидарәлек хезмәте күрсәтү өчен законнар яки башка норматив хокукый актлар нигезендә гариза бирүче тапшырырга тиешле зарури документларның, шулай ук үзидарәлек хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрнең тулы исемлеге, аларны гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Муниципаль хезмәт алу өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тапшыра:

1) шәхесне таныклаучы документ (Республика порталы ярдәмендә мөрәҗәгать иткәндә таләп ителми) ;

2 мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ;

3) гариза:

кәгазь йөрткечтәге документ рәвешендә (әлеге административ регламентка 3 нче кушымта);

электрон рәвештә (тиешле мәгълүматларны гаризаның электрон рәвешенә кертү юлы белән тутырыла), ул Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә Регламентның 2.5.3 пункты таләпләре нигезендә имзалана.

4) мөрәҗәгать итүче граждан һәм аның гаилә әгъзалары били торган торак урыннан файдалану хокукын раслый торган документларның күчермәләре (шартнамә, ордер, торак урын бирү турында карар һәм башка документлар);

5) мөрәҗәгать итүче гражданнарның гаилә составы турында документларның күчермәләре (туу турында таныклык, никахлашу турында таныклык, уллыкка (кызлыкка) алу турында карар, гаилә әгъзасы итеп тану турында суд карары һ.б.);

6) ТИБ нан техник паспортларның катлар буенча планы (булганда) һәм экспликация белән өземтәсе.

2.5.2. Гариза һәм теркәп бирелә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

1) КФҮ аша кәгазь йөрткечләрдә һәм Регламентның 2.5.3. пункты таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә;

2) Республика порталы аша электрон рәвештә.

3) Органда шәхсән яки кәгазь йөрткечтә почта элемтәсе ярдәмендә.

Гариза һәм теркәлә торган документлар почта элемтәсе аша җибәрелгәндә билгеләнгән тәртиптә таныклана.

2.5.3. Республика порталы аша җибәрелгәндә гариза мөрәҗәгать итүченең гади электрон култамгасы белән имзалана.

Гади электрон имза алу өчен гариза бирүчегә ЕСИА да теркәлү (аутентификацияләү) процедурасын узарга, шулай ук хисап язмасын рasларга кирәк.

Регламентның 2.5.1 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән электрон документлар (документларның электрон үрнәкләре) мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затлар, шул исәптән нотариуслар тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон култамга белән имзаланалар.

Гаризага теркәлеп бирелә торган электрон документлар (электрон документлар үрнәкләре), шул исәптән ышанычнамәләр pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf форматларында 50 Мбайттан да артмаган күләмдә файллар рәвешендә җибәрелә.

Электрон документларның (электрон документлар үрнәкләренең) сыйфаты документ текстын тулы күләмдә укырга һәм документ реквизитларын танырга мөмкинлек бирергә тиеш.

2.5.4. Мөрәҗәгать итүчедән таләп итү тыела:

1) муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшыру яисә гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыру яисә гамәлләр кылуны;

2) муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле һәм башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга мөрәҗәгать итү белән бәйле гамәлләрне, шул исәптән килештерүләрне гамәлгә ашыруны, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 9 маддәсенең 1 өлешендә күрсәтелгән исемлекләргә кертелгән мондый хезмәтләр (кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр) күрсәтү нәтиҗәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрне һәм документларны алудан гайре;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны башта кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәткәндә баш тартканда документларның һәм мәгълүматның булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүматны тапшыруны, түбәндәге очраклардан гайре:

а) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза башта бирелгәннән соң муниципаль хезмәт күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актлар таләпләренең үзгәрүе;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризада һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны баштагы кабул итүдән баш тартканнан соң мөрәҗәгать итүче биргән документларда яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдә элек бирелгән документлар комплектына кертелмәгән хаталар булу;

в) документларның гамәлдә булу вакыты чыгу яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән башта баш тартканнан соң яки муниципаль хезмәт күрсәтүдә мәгълүмат үзгәрү;

г) Органның вазыйфаи затының, КФҮ хезмәткәренең муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне баштагы кире какканда яисә муниципаль хезмәт күрсәткәндә хаталы яки хокукка каршы гамәл кылуының (гамәл кылмавының) документаль расланган факты (билгеләре) ачыклану, әлеге муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу очрагында Орган җитәкчесе имзасы белән язма рәвештә мөрәҗәгать итүчегә хәбәрнамә ирештерелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә;

4) электрон рәвешләре 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсендәге 1 өлешенең 7.2 пункты нигезендә элек расланган документларны һәм мәгълүматны кәгазь йөрткечтә тапшыру, мондый документларга тамга салу яисә аларны алу дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан гайре.

### 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә зарур булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хаклы документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә,

аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма.

2.6.1. Ведомствоара хезмәттәшлек (багланышлар) кысаларында алына:

12) күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан аерым затның булган күчемсез милек объектларына хокуклары турында өземтә (гариза биргәнгә кадәр биш ел эчендә мөрәҗәгать итүче гаиләсенең хокуктан файдалануга сәләтле һәр әгъзасына) - Росреестр;

13) гражданнарны теркәү турында мәгълүматлар;

14) Россия Федерациясе гражданының гамәлдәге паспорты турында мәгълүматлар – Россия ЭЭМ;

4) нотариаль ышанычнамә турында мәгълүматлар – Федераль нотариаль палата.

2.6.2. Мөрәҗәгать итүче Регламентның 2.6.1 пунктының 1-2 пунктчаларында күрсәтелгән документларны (мәгълүматларны) мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затларның көчәйтелгән квалификацияле култамгасы белән таныкланган электрон документлар рәвешендә гариза биргәндә тапшырырга хокуклы.

2.6.3. Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар тарафыннан документлар һәм мәгълүматларны тапшырмау (вакытында тапшырмау) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.6.4. Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән органнарның соралган һәм карамагында булган документларны яисә мәгълүматларны тапшырмаган (үзвакытында тапшырмаган) вазыйфаи заты һәм (яисә) хезмәткәре Россия Федерациясе законнары нигезендә административ, дисциплинар яисә башка җаваплылыкка тартылырга тиеш.

2.6.5. Гариза бирүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар карамагындагы документларны һәм мәгълүматларны, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәткән өчен гариза бирүче тарафыннан түләү кертүне раслый торган мәгълүматларны таләп итү тыела.

Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалар карамагында булган мәгълүматларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырмау мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

### 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

3) тапшырылган документларда текстның бетерелгән (сөртелгән) һәм Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланмаган төзәтмәләре бар.

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлардагы зарарланулар мәгълүматны тулы күләмдә кулланырга, текстны укырга һәм (яки) танырга мөмкинлек бирми;

3) тапшырылган документлар яисә мәгълүматлар муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итү вакытына үз көчләрен югалтканнар (вәкил муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклаучы документ);

4) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар билгеләнгән таләпләрне бозып, электрон формада бирү;

5) гариза формасындагы мәҗбүри кырларны, шул исәптән Республика порталындагы гаризаның интерактив рәвешендә, дөрес тутырмау (дөрес түгел, тулы булмаган яисә дөрес тутырылмаган);

6) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мәҗбүри булган регламентта каралган документларның тулы булмаган комплекты бирелгән;

7) хезмәт күрсәтү турында гариза муниципаль хезмәт күрсәтү вәкаләтләренә керми торган дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына яисә оешмага тапшырылган;

8) “Электрон имза турында” 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 маддәсендә билгеләнгән көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаның чынлыгын тану шартларын үтәмәү.

2.7.2. Муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге төгәл булып тора.

2.7.3. Гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү вакытында да, органның җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны (мәгълүматларны) ведомствоара мәгълүмати багланышны файдаланып алганнан соң да, гаризаны теркәгәннән соң 9 эш көненнән дә артмаган срокта кабул ителергә мөмкин.

2.7.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда, Республика порталында бастырылган муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

## 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр күздә тотылмый.

2.8.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге:

1) тәкъдим ителгән гаризада һәм (яисә) документларда тулы булмаган һәм (яисә) дөрес булмаган мәгълүмат бар;

2) әгәр тиешле документ мөрәҗәгать итүченең үз инициативасы белән күрсәтелмәгән булса, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында сөйләүче дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының яки дәүләт хакимиятенең ведомство буйсынуындагы органының яисә җирле үзидарә органының ведомствоара гарызнамәгә җавабы килеп ирешү;

3) алмаштырыла торган торак урынын яллаучыга торак урынның социаль наем шартнамәсен өзү яисә үзгәртү турында дәгъва белдерелгән;

4) алмаштырыла торган торак урыннан файдалану хокукы суд тәртибендә дәгъвалана;

5) алмаштырыла торган торак урыны билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган;

6) тиешле йортны сүтү яки аны башка максатларда куллану өчен яңадан җиһазландыру турында карар кабул ителде;

7) әлеге йортта торак урыннарны үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру белән йортны капиталь ремонтлау турында карар кабул ителде;

8) коммуналь фатирга алмаштыру нәтиҗәсендә Россия Федерациясе Торак кодексының 51 маддәсендә 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруларның авыр төрләренең берсе белән газап чигүче граждан кертелә.

2.8.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге төгәл булып тора.

2.8.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза Бердәм порталда, Республика порталында игълан ителгән (бастырылган) муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту тыела.

## 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алынучы дәүләт пошлинасы һәм бүтән түләүнең тәртибе, күләме һәм түләтү нигезе

Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә.

## 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында мәгълүматлар

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

## 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтүгә түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

### 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамә биргәндә, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәт күрсәтелгәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты

2.12.1. Муниципаль хезмәт алуга гариза биргәндә көтү вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.12.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

### 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең гарызнамәсен һәм хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтне теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон рәвештә

2.13.1. Гариза биргән көнне КФҮкә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүчегә гаризаның җибәрелүен раслаучы теркәлү номеры һәм электрон гаризаны бирү датасы белән КФҮ АМС ннан раслама бирелә.

2.13.2. Гаризаны Республика порталы ярдәмендә юллаганда мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Республика порталының шәхси кабинетында һәм электрон почта аша, гаризаның теркәлү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелеп, гаризаның җибәрелүен раслый торган хәбәрнамә ала.

2.13.3. Органга шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гариза биргән көнне вәкаләтле вазыйфаи зат Органга мөрәҗәгать итүчегә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан теркәү номеры, гариза бирү датасы һәм тапшырылган документлар исемлеге белән раслама бирә.

### 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, көтү залына, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамәләрне тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре һәм һәр муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге булган мәгълүмат стендларына карата, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыру һәм бизәүгә, шул исәптән әлеге объектларга инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвалидлар өчен үтү (керү) мөмкинлеген тәэмин итүгә таләпләр

2.14.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебельләр, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

2.14.2. Инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү (үтү) максатларында түбәндәгеләр тәэмин ителә:

18) инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына каршылыксыз керүе (үтә алуы) тәэмин ителә (бина-бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм алар эчендә күченү, хәрәкәт итү).

19) муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

20) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләренең ныклы тайпылышлары булган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

21) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм алардан чыгу, транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

22) инвалидларның хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөрткечләрне аларның тереклек эшчәнлегенең чикләнгәнлеген исәпкә алып тиешенчә урнаштыру;

23) инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук өсьязуларны, билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайль рельеф-нокталы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау;

24) сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчегә рөхсәт итү;

8) озатучы-этне махсус укыту-өйрәтүне раслаучы һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының “Озатучы-этне махсус укытуны раслый торган документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында” 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән билгеләнгән рәвештә һәм тәртиптә бирелгән документы булганда рөхсәт итү.

2.14.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектлардан һәм муниципаль хезмәт күрсәткәндә кулланыла торган Регламентның 2.14.2 пунктының 1 – 4 пунктчаларында күрсәтелгән чаралардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр, алар 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизацияләнгән объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

2.15. Муниципаль хезмәтнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән муниципаль хезмәт күрсәткәндә үзара багланышлары саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләрен кулланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы күләмдә), җирле үзидарәнең башкарма-боеру органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә муниципаль хезмәт алу мөмкинлеге яисә мөмкин түгеллеге, мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча (экстерриториаль принцип), 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 маддәсендә каралган

күпфункцияле үзәкләрдә берничә дәүләт һәм (яисә) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамә (комплекслы гарызнамә) ярдәмендә

2.15.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкинлеге (доступность) күрсәткечләре булып тора:

документлар кабул итү, бирү алып барыла торган бинаның җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итүне гамәлгә ашыра торган бүлмәләрнең кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, муниципаль районның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында муниципаль хезмәтне күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

инвалидларга башкалар белән бер үк дәрәҗәдә хезмәтләр алырга комачаулаучы киртәләрне җиңәргә ярдәм итү.

2.15.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләр:

1) документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;

2) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу срогын үтәү;

3) орган хезмәткәрләре тарафыннан Регламентны бозуга карата нигезле шикаятьләр булмау;

4) мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән багланышлары саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең КФҮ хезмәткәрләре белән багланышы барлык кирәкле документлар белән гариза биргәндә бер тапкыр гамәлгә ашырыла;

бер тапкыр Органда яки КФҮ тә электрон документның нөсхә рәвешендә кәгазь йөрткечтәге муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу кирәк булган очракта.

Муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бер мәртәбә багланышының дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.

Мөрәҗәгать итүче күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын Республика порталы, терминал җайланмалары аша бәяләргә хокуклы.

2.15.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүматны мөрәҗәгать итүче Бердәм порталда яисә Республика порталында шәхси кабинетта, Органда, КФҮ тә алырга мөмкин.

2.15.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча яшәү урынына яисә фактта яшәү (булу) урынына бәйсез рәвештә Татарстан Республикасы территориясендә экстерриториаль принцип буенча.теләсә кайсы КФҮ тә гамәлгә ашырыла.

Комплекслы гарызнамә составында муниципаль хезмәт күрсәтелми.

2.16. Башка таләпләр, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча (әгәр муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә икән) муниципаль

хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алып, һәм электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре

2.16.1. Муниципаль хезмәт электрон рәвештә күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хокуклы:

6) Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

7) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон рәвешләре 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсендәге 1 өлешенең 7.2 пункты нигезендә Республика порталыннан файдаланып таныкланган документлар һәм мәгълүмат бирүгә;

8) электрон рәвештә бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында мәгълүматлар алырга;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;

10) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә алырга;

6) Республика порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә кылынган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауларга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итүче федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Органның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирергә.

2.16.2. Гаризаны формалаштыру Республика порталында гаризаның электрон рәвешен тутыру юлы белән нинди дә булса башка рәвештә гариза бирү зарурлыгыннан башка гамәлгә ашырыла.

2.16.3. Гаризаны формалаштырганда түбәндәгеләр тәэмин ителә:

7) гаризаны һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны күчермәләү һәм саклау мөмкинлеге;

8) берничә мөрәҗәгать итүче тарафыннан уртак гариза җибәрүне күздә тоткан хезмәтләр сорап мөрәҗәгать иткәндә гаризаның бер электрон рәвешен берничә мөрәҗәгать итүченең бергә тутыру мөмкинлеге;

9) гаризаның электрон рәвеше күчермәсен кәгазь йөрткечтә бастыру мөмкинлеге;

10) кулланучы теләге буенча теләсә кайсы вакытта электрон рәвешкә элек кертелгән кыйммәтләрне саклап калу, шул исәптән кертү хаталары барлыкка килгәндә һәм кыйммәтләрне гаризаның электрон формасына кабат кертү өчен кире кайтару;

11) гаризаның электрон рәвеше кырларын гариза бирүче тарафыннан, ЕСИА да урнаштырылган мәгълүматлардан файдаланып, мәгълүматларны кертә башлаганчы тутыру һәм Бердәм порталда, Республика порталында бастырылган

мәгълүматларны идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасында булмаган мәгълүматларга кагылышлы өлешендә куллану;

12) элек кертелгән мәгълүматны югалтмыйча, гариза электрон формасын тутыруның теләсә кайсы этапларына кире кайту мөмкинлеге;

7) мөрәҗәгать итүченең республика Порталында элек бирелгән гаризаларга бер елдан да ким булмаган, шулай ук өлешчә формалаштырылган гаризаларга - кимендә 3 ай эчендә керә алу мөмкинлеге.

2.16.4. Мөрәҗәгать итүчеләрнең КФҮ кә кабул итүгә язылуы (алга таба – язылу) Республика порталы, КФҮнең контакт-үзәге телефоны аша башкарыла.

Мөрәҗәгать итүчегә кабул итү өчен теләсә нинди буш вакытка күпфункцияле үзәкнең кабул итү графигының билгеләнгән чикләрендә язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу бу датага кадәр бер тәүлек кала тәгәлләнә.

Республика порталы ярдәмендә алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә система тарафыннан соратыла торган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилия, исем, атасының исемен (булган сурәттә);

телефон номерын;

электрон почта адресын (теләк буенча);

теләгән кабул итү датасын һәм вакытын.

Мөрәҗәгать итүче алдан язылу вакытында хәбәр иткән мәгълүматларның шәхси кабул итү вакытында гариза бирүче биргән документлардагы мәглүматларга туры килмәве очрагында алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда мөрәҗәгать итүчегә талон-раслауның распечаткасын алу мөмкинлеге бирелә.

Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын хәбәр итсә, күрсәтелгән адреска, кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда гариза бирүчегә мәҗбүри рәвештә, билгеләнгән кабул итү вакытына килмәгән очракта кабул итү вакытыннан 15 минут узгач, алдан язылу гамәлдән чыгарылуы турында хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүчедән, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан гайре, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен броньларга кирәк булган вакытлыча интервал дәвамлылыгын исәпләү өчен зарури мәгълүматлар бирүдән башка гамәлләр кылуны таләп итү тыела.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәтләр күрсәткәндәге гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә (гариза бирүчегә) консультация (мәслихәт) бирү;

2) мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар комплектын (тупламын) кабул итү һәм карау;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара гарызнамәләр җибәрү;

4) документларны комиссиянең каравы;

4) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;

5) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

6) техник хаталарны төзәтү.

3.2. Гариза бирүче (мөрәҗәгать итүче) белән консультацияләр үткәрү (мәслихәт бирү)

3.2.1. Административ процедураны үтәүне башлауның нигезе – мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгате.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы урындагы кеше (хезмәткәр) булып тора:

мөрәҗәгать итүче КФҮ кә мөрәҗәгать иткәндә – КФҮ хезмәткәре;

мөрәҗәгать итүченең Органга мөрәҗәгатендә – Органның әйдәүче белгече (алга таба – консультация (мәслихәт) бирү өчен җаваплы урындагы кеше).

3.2.2. Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында консультация сорап КФҮ тә шәхсән һәм телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә консультация бирә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тапшырыла торган документациянең составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча.

Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүматны КФҮ нең http://mfc16.tatarstan.ru сайтыннан ирекле файдалану юлы белән алырга мөмкин.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелә торган документациянең составы, формасы һәм муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча консультация.

3.2.3. Мөрәҗәгать итүче телефон һәм электрон почта аша Органга мөрәҗәгать итәргә, шулай ук Республика порталында, Органның муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында сайтында консультация алырга хокуклы, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тапшырыла торган документациянең составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча.

мәгълүмат стендларында, муниципаль районның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында муниципаль хезмәтне күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

инвалидларга башкалар белән бер үк дәрәҗәдә хезмәтләр алырга комачаулаучы киртәләрне җиңәргә ярдәм итү.

2.15.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләр:

1) документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;

2) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу срогын үтәү;

3) орган хезмәткәрләре тарафыннан Регламентны бозуга карата нигезле шикаятьләр булмау;

4) мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән багланышлары саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең КФҮ хезмәткәрләре белән багланышы барлык кирәкле документлар белән гариза биргәндә бер тапкыр гамәлгә ашырыла;

бер тапкыр Органда яки КФҮ тә электрон документның нөсхә рәвешендә кәгазь йөрткечтәге муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу кирәк булган очракта.

Муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бер мәртәбә багланышының дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.

Мөрәҗәгать итүче күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын Республика порталы, терминал җайланмалары аша бәяләргә хокуклы.

2.15.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүматны мөрәҗәгать итүче Бердәм порталда яисә Республика порталында шәхси кабинетта, Органда, КФҮ тә алырга мөмкин.

2.15.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча яшәү урынына яисә фактта яшәү (булу) урынына бәйсез рәвештә Татарстан Республикасы территориясендә экстерриториаль принцип буенча.теләсә кайсы КФҮ тә гамәлгә ашырыла.

Комплекслы гарызнамә составында муниципаль хезмәт күрсәтелми.

### 2.16. Башка таләпләр, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча (әгәр муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә икән) муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алып, һәм электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре

2.16.1. Муниципаль хезмәт электрон рәвештә күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хокуклы:

11) Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

12) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон рәвешләре 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсендәге 1 өлешенең 7.2 пункты нигезендә Республика порталыннан файдаланып таныкланган документлар һәм мәгълүмат бирүгә;

13) электрон рәвештә бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында мәгълүматлар алырга;

14) муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;

15) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә алырга;

6) Республика порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә кылынган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауларга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итүче федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Органның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирергә.

2.16.2. Гаризаны формалаштыру Республика порталында гаризаның электрон рәвешен тутыру юлы белән нинди дә булса башка рәвештә гариза бирү зарурлыгыннан башка гамәлгә ашырыла.

2.16.3. Гаризаны формалаштырганда түбәндәгеләр тәэмин ителә:

13) гаризаны һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны күчермәләү һәм саклау мөмкинлеге;

14) берничә мөрәҗәгать итүче тарафыннан уртак гариза җибәрүне күздә тоткан хезмәтләр сорап мөрәҗәгать иткәндә гаризаның бер электрон рәвешен берничә мөрәҗәгать итүченең бергә тутыру мөмкинлеге;

15) гаризаның электрон рәвеше күчермәсен кәгазь йөрткечтә бастыру мөмкинлеге;

16) кулланучы теләге буенча теләсә кайсы вакытта электрон рәвешкә элек кертелгән кыйммәтләрне саклап калу, шул исәптән керту хаталары барлыкка килгәндә һәм кыйммәтләрне гаризаның электрон формасына кабат кертү өчен кире кайтару;

17) гаризаның электрон рәвеше кырларын гариза бирүче тарафыннан, ЕСИА да урнаштырылган мәгълүматлардан файдаланып, мәгълүматларны кертә башлаганчы тутыру һәм Бердәм порталда, Республика порталында бастырылган мәгълүматларны идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасында булмаган мәгълүматларга кагылышлы өлешендә куллану;

18) элек кертелгән мәгълүматны югалтмыйча, гариза электрон формасын тутыруның теләсә кайсы этапларына кире кайту мөмкинлеге;

7) мөрәҗәгать итүченең республика Порталында элек бирелгән гаризаларга бер елдан да ким булмаган, шулай ук өлешчә формалаштырылган гаризаларга - кимендә 3 ай эчендә керә алу мөмкинлеге.

2.16.4. Мөрәҗәгать итүчеләрнең КФҮ кә кабул итүгә язылуы (алга таба – язылу) Республика порталы, КФҮнең контакт-үзәге телефоны аша башкарыла.

Мөрәҗәгать итүчегә кабул итү өчен теләсә нинди буш вакытка күпфункцияле үзәкнең кабул итү графигының билгеләнгән чикләрендә язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу бу датага кадәр бер тәүлек кала төгәлләнә.

Республика порталы ярдәмендә алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә система тарафыннан соратыла торган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилия, исем, атасының исемен (булган сурәттә);

телефон номерын;

электрон почта адресын (теләк буенча);

теләгән кабул итү датасын һәм вакытын.

Мөрәҗәгать итүче алдан язылу вакытында хәбәр иткән мәгълүматларның шәхси кабул итү вакытында гариза бирүче биргән документлардагы мәглүматларга туры килмәве очрагында алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда мөрәҗәгать итүчегә талон-раслауның распечаткасын алу мөмкинлеге бирелә.

Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын хәбәр итсә, күрсәтелгән адреска, кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда гариза бирүчегә мәҗбүри рәвештә, билгеләнгән кабул итү вакытына килмәгән очракта кабул итү вакытыннан 15 минут узгач, алдан язылу гамәлдән чыгарылуы турында хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүчедән, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан гайре, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен броньларга кирәк булган вакытлыча интервал дәвамлылыгын исәпләү өчен зарури мәгълүматлар бирүдән башка гамәлләр кылуны таләп итү тыела.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә үтәү үзенчәлекләре

### 3.1. Муниципаль хезмәтләр күрсәткәндәге гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә (гариза бирүчегә) консультация бирү;

2) мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар комплектын кабул итү һәм карау;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара гарызнамәләр җибәрү;

4) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;

5) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

6) техник хаталарны төзәтү.

### 3.2. Гариза бирүче (мөрәҗәгать итүче) белән консультацияләр үткәрү (мәслихәт бирү)

3.2.1. Административ процедураны үтәүне башлауның нигезе – мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгате.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып тора:

мөрәҗәгать итүче КФҮ кә мөрәҗәгать иткәндә – КФҮ хезмәткәре;

мөрәҗәгать итүченең Органга мөрәҗәгатендә – Башкарма комитет сәркатибе (алга таба – консультация (мәслихәт) бирү өчен җаваплы вазыйфаи зат).

3.2.2. Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында консультация сорап КФҮ тә шәхсән һәм телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә консультация бирә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тапшырыла торган документациянең составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча.

Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүматны КФҮ нең http://mfc16.tatarstan.ru сайтыннан ирекле файдалану юлы белән алырга мөмкин.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелә торган документациянең составы, формасы һәм муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча консультация.

3.2.3. Мөрәҗәгать итүче телефон һәм электрон почта аша Органга мөрәҗәгать итәргә, шулай ук Республика порталында, Органның муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында сайтында консультация алырга хокуклы, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тапшырыла торган документациянең составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча.

Консультация бирү өчен җаваплы вазыйфаи зат Регламентның 1.3.4 пункты таләпләре нигезендә мөрәҗәгать итүчегә мәгълүмат бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать кергән көннән алып өч эш көне эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелә торган документациянең составы, формасы һәм муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча консультацияләр.

### 3.3. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар комплектын (тупламын) кабул итү һәм карау

3.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документларны КФҮ яки КФҮнең ераклашкан эш урыны аша кабул итү.

3.3.1.1. Мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамә белән КФҮкә мөрәҗәгать итә һәм Регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны тапшыра.

3.3.1.2. Гаризаларны кабул итүче КФҮ хезмәткәре:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый;

мөрәҗәгать предметын билгели;

документлар бирүче затның вәкаләтләрен тикшерә;

документларның Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен тикшерә;

КФҮнең АМС на гаризаның электрон формасын тутыра;

Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар кәгазь йөрткечтә тапшырылганда, тапшырылган документларны сканерлауны гамәлгә ашыра;

КФҮ нең АМС нан гаризаның распечаткасын ала;

мөрәҗәгать итүчегә тикшерүгә һәм кул куюга тапшыра;

имза салганнан соң кул куелган гаризаны КФҮ нең АМС нда сканерлый;

электрон формада яки электрон рәвештәге сканерланган тәкъдим ителгән документларны КФҮ нең АМС на кертә (йөкли), электрон дело (эш) формалаштыра;

имзаланган гаризаны һәм кәгазь документларның төп нөсхәләрен кире кайтара;

мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү хакында раслама бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: җибәрергә әзер гариза һәм документлар пакеты.

3.3.1.3 КФҮ хезмәткәре мөрәҗәгать итүчедән кабул ителгән документлар пакетын (электрон эшләр пакетлары составында) КФҮ нең структур бүлекчәсенә мөрәҗәгать иткән көннән бер эш көне эчендә электрон формада Органга җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: электрон багланыш системасы ярдәмендә Органга җибәрелгән гариза һәм документлар пакеты (электрон эш).

3.3.2. Республика порталы аша муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәтү өчен документлар кабул итү.

3.3.2.1. Гаризаны Республика порталы аша электрон рәвештә бирү өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

авторизацияне башкара;

электрон гариза формасын (рәвешен) ача;

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган мәгълүматларны үз эченә алган электрон гариза рәвешен тутыра;

документларны электрон формада яисә электрон документлар образларын электрон гариза формасына беркетә (зарурлык булганда);

электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтүнең шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамганы билгели);

хәбәр ителгән мәгълүматларның дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамганы билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасында тиешле төймәгә баса);

электрон гариза Регламентның 2.5.3 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаны җибәрү турында хәбәрнамә ала.

Формалаштырылган гаризаны формат-логик тикшерү гариза бирүче тарафыннан һәр кырның электрон формасы тутырылганнан соң гамәлгә ашырыла. Тиешенчә (дөрес) тутырылмаган электрон гариза кырын ачыклаганда, мөрәҗәгать итүче ачыкланган хатаның характеры һәм аны мәгълүмати хәбәр итү юлы белән турыдан-туры гаризаның электрон формасында бетерү тәртибе турында хәбәр итә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән административ процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә Органга юнәлтелгән электрон эш тора.

3.3.3. Орган тарафыннан документлар тупламын карау.

3.3.3.1. Административ процедураны үтәүне башлауга нигез булып муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм башка документлар килеп ирешү тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) – Башкарма комитет сәркатибе (алга таба – документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат).

3.3.3.2. Документлар кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат, мөрәҗәгать итүченең Органга гаризасы белән мөрәҗәгать иткән очракта:

мөрәҗәгать предметын билгели;

гариза бирүченең шәхесен тәгаенли;

документлар бирүче затның вәкаләтләрен тикшерә;

регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен тикшерә, тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү үткәрә (документлар күчермәләренең тиешенчә рәсмиләштерелүен, документларда бетереп төзәтүләр, припискалар, сызылган сүзләр һәм башка килешенмәгән төзәтмәләр булмауны тикшерә);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасында гаризаның электрон формасын тутыра;

регламентның 2.5 пунктында кәгазь йөрткечтәге документларны тапшырганда, тапшырылган документларны сканерлауны гамәлгә ашыра;

гаризаның распечаткасын ала;

мөрәҗәгать итүчегә тикшерү һәм имзалау өчен бирә;

кул куелганнан соң имзаланган гариза сканерлана;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасына электрон формада тәкъдим ителгән документларны яки электрон рәвештәге документларны йөкли, электрон эш формалаштыра;

имзаланган гаризаны һәм кәгазь документларның төп нөсхәләрен гариза бирүчегә кире кайтара;

гариза бирүчегә документларны кабул итү өчен раслама бирә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат мөрәҗәгать итүчегә

гаризаны кабул итү өчен киртәләр булу турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, аңа документларны кире кайтара.

3.3.3.3. Документлар кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат, документлар каралуга кергәннән соң:

гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә номер һәм “Документларны тикшерү” статусы бирелә;

килеп ирешкән электрон эшләрне, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан кушымта итеп бирелгән электрон формадагы документларны һәм документларның электрон рәвешләрен (образларын) өйрәнә;

документларның комплектлылыгын (тупланганлыгын), документларның электрон образларының (рәвешләренең) укылышын тикшерә;

Бердәм порталга мөрәҗәгать итү юлы белән электрон култамганың чын (дөрес) булу шартларының үтәлүен тикшерә (гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон култамга белән имзаланган электрон документлар рәвешләре тапшырылган очракта).

Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булганда, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын әзерли.

Көчәйтелгән квалификацияле электрон култамганы тикшерү нәтиҗәсендә аның чын булу шартларын үтәмәү ачыкланган очракта, баш тарту турындагы карар проектында аны кабул итүгә нигез булган 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 маддәсе пунктлары булырга тиеш.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проекты, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп (әгәр дә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуның нигезләре мондый документларга карата билгеләнгән таләпләрне бозу белән бәйле булса, документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрдә дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы белешмәләр булган, билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән алдан тәкъдим ителмәгән документлар (мәгълүмат, белешмәләр) исеме турында мәгълүмат булырга тиеш), билгеләнгән тәртиптә электрон документ әйләнеше системасы аша килештерүгә җибәрелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проектын килештерү Регламентның 3.5.3 пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат, гариза кергән көннән алып бер эш көне эчендә гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә гаризаның теркәү номеры, гаризаны алу датасы, файлларның исемнәре, аңа тәкъдим ителгән документлар исемлеге, муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу датасы булган гариза килеп ирешү турында хәбәрнамә җибәрә.

3.3.3.4. Регламентның 3.3.3.1, 3.3.3.3 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль

хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

3.3.3.5. Регламентның 3.3.3 пункты белән билгеләнә торган процедуралар гариза карауга кергән көннән бер эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: карауга кабул ителгән документлар тупламы яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты.

### 3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара гарызнамәләр җибәрү

3.4.1. Административ процедураны үтәүне башлау өчен нигез булып мөрәҗәгать итүчедән алынган документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи заттан (хезмәткәрдән) административ процедураны башкаруга вәкаләтле вазыйфаи затның (хезмәткәрнең) алуы тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып Башкарма комитет сәркатибе тора (алга таба – ведомствоара гарызнамәләр җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат).

3.4.2. Ведомствоара гарызнамәләр җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат ведомствоара электрон багланышлар системасы аша (техник мөмкинлек булмаганда – башка ысуллар белән) электрон рәвештә Регламентның 2.6.1 пунктында каралган документларны һәм мәгълүматларны тапшыруга гарызнамәләр формалаштыра һәм җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар карау өчен гариза кабул ителгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: хакимият органнарына һәм (яки) хакимият органнарына буйсынган оешмаларга юлланган гарызнамәләр.

3.4.3. Белешмәләр белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре, ведомствоара электрон багланыш системасы аша кергән гарызнамәләр нигезендә, соратыла торган документларны (мәгълүматны) тапшыралар яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмау турында хәбәрнамәләр юллыйлар (алга таба – кире кагу турында хәбәрнамә).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар документ һәм мәгълүмат бирә торган органга яки оешмага ведомствоара гарызнамә кергән көннән өч көн эчендә башкарыла, әгәр ведомствоара гарызнамәгә җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актларында һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында билгеләнмәсә.

Процедураларның нәтиҗәсе: муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар (мәгълүматлар) яки ведомствоара гарызнамәләр җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи затка юлланган баш тарту турында хәбәрнамә.

3.4.4. Ведомствоара гарызнамәләр җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле ведомствоара электрон багланышлар системасы аша соратыла торган документларны (мәгълүматларны) яки документ һәм (яки) мәгълүмат булмаганда баш тарту турында хәбәрнамә ала;

Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булганда, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын әзерли.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проекты, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп (әгәр дә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуның нигезләре мондый документларга карата билгеләнгән таләпләрне бозу белән бәйле булса, документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрдә дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы белешмәләр булган, билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән алдан тәкъдим ителмәгән документлар (мәгълүмат, белешмәләр) исеме турында мәгълүмат булырга тиеш) билгеләнгән тәртиптә электрон документ әйләнеше системасы аша килештерүгә җибәрелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проектын килештерү Регламентның 3.5.3 пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар ведомствоара гарызнамәләр буенча мәгълүматлар алган көнне башкарыла.

Административ процедураларның үтәлеш нәтиҗәләре булып тора: муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар (мәгълүматлар), муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты.

3.4.5. Регламентның 3.4.2, 3.4.4 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын, шул исәптән гаризаны Регламентның 2.13 пункты нигезендә теркәгән мизгелдән файдаланып, автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

3.4.6. Регламентның 3.4 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны үтәүнең максималь срогы өч эш көне тәшкил итә.

### 3.5. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү

3.5.1. Административ процедураны башкару өчен нигез булып, ведомствоара гарызнамәләр җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи заттан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның (мәгълүматларның) килеп ирешүе тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат – Башкарма комитет сәркатибе (алга таба – муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат).

3.5.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар тупламын карый;

регламентның 2.8.2 пунктында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрне ачыклаганда, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын әзерли;

Регламентның 2.8.2 пунктында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны карау йомгаклары буенча, Регламентның 2.3.1 пунктындагы 1 – 3 пунктчалары нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе проектын әзерли;

әзерләнгән карарлар проектларын билгеләнгән тәртиптә электрон документ әйләнеше системасы аша килештерүгә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән административ процедуралар бер эш көне дәвамында башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты, белешмәләр (өземтәләр).

3.5.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен (алга таба - документлар проектлары) проектын килештерү һәм имзалау муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе, Орган рәисе урынбасары, Орган рәисе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Замечаниеләре булган карарларның әзерләнгән проектлары муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы затка кире кайтарыла.

Замечаниеләрне бетергәннән соң, документлар проектлары кабат килештерү һәм кул кую өчен тапшырыла.

Орган җитәкчесе документлар проектларын имзалаганда, Регламентның административ процедураларны үтәү срокларын, аларның эзлеклелеген һәм тулылыгын, электрон документ әйләнеше системасында Органның вәкаләтле вазыйфаи затларының килешүләрен үтәүне тикшерә.

Административ процедураларны үтәү срокларын, аларның эзлеклелеген һәм тулылыгын ачыклау өлешендә тәртип бозулар ачыкланган очракта, Орган җитәкчесе регламентның 4.3 пункты нигезендә хокук бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту инициативасы белән чыга.

Административ процедуралар бер эш көне дәвамында башкарыла.

Административ процедураларның үтәлеше нәтиҗәләре булып тора: муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар, белешмә (өземтә).

3.5.4. Регламентның 3.5.2, 3.5.3 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.5 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны үтәүнең максималь срогы бер эш көнен тәшкил итә.

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү (җибәрү)

3.6.1. Административ процедураны башкару өчен нигез булып административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне раслаучы документ алу тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат булып Башкарма комитет сәркатибе тора (алга таба – документлар бирү (җибәрү, юнәлтү) өчен җаваплы вазыйфаи зат).

3.6.2. Документлар бирү (җибәрү, юнәлтү) өчен җаваплы вазыйфаи зат:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасы документациясен алып баруның ярдәмче системасында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләрне теркәүне һәм кертүне тәэмин итә;

мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән ысул белән, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында һәм Органда яки КФҮ тә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, автомат рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документка Органның вәкаләтле вазыйфаи заты кул куйган көннән алып бер эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: мәгълүмат системаларында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыру, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре һәм аны алу ысуллары турында хәбәрнамә ирештерү.

3.6.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү) тәртибе:

3.6.3.1. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт нәтиҗәсен сорап КФҮ кә мөрәҗәгать иткәндә, КФҮ хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә электрон документның кәгазь йөрткечтәге нөсхәсе рәвешендә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирә. Мөрәҗәгать итүче таләбе буенча аңа электрон документның кәгазь йөрткечтәге нөсхәсе белән бергә аны салдырыла торган йөрткечкә яздыру юлы белән электрон документның нөсхәсе бирелә яки мөрәҗәгать итүче адресына электрон почта аша электрон документның нөсхәсе җибәрелә.

Аның нигезендә электрон документның кәгазь йөрткечтәге нөсхәсе төзелгән мәгълүматны салдырыла торган йөрткечкә язганда яки электрон документ нөсхәсен электрон почта аша җибәргәндә мондый нөсхәнең электрон документның кәгазь йөрткечтәге нөсхәсенә тәңгәллеге көчәйтелгән квалификацияле электрон култамга кулланып вәкаләтле хезмәткәр тарафыннан таныклана.

Әлеге пункт белән билгеләнгән административ процедуралар мөрәҗәгать итүченең КФҮ регламентында билгеләнгән срокларда килү көнендә чиратлылык тәртибендә башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора: КФҮнең АМС да муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү фактын теркәү, мөрәҗәгать итүчегә бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе.

3.6.3.2 Мөрәҗәгать итүче Республика порталы аша муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен сорап мөрәҗәгать иткәндә, мөрәҗәгать итүчегә шәхси кабинетка автомат рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган, Органның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон култамгасы белән имзаланган документның электрон үрнәге җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслаучы документка Органның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан кул куелган көнне башкарыла.

Административ процедураларның үтәлеше нәтиҗәләре булып тора: гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүне раслаучы документның Республика порталыннан файдаланып җибәрү (бирү) (шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту).

3.6.3.3. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт нәтиҗәсен сорап Органга мөрәҗәгать иткәндә, документларны бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирә. Мөрәҗәгать итүче таләбе буенча аңа электрон документның кәгазь йөрткечтәге нөсхәсе белән бергә аны салдырыла торган йөрткечкә яздыру юлы белән электрон документның нөсхәсе бирелә яки мөрәҗәгать итүче адресына электрон почта аша электрон документның нөсхәсе җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар, мөрәҗәгать итүче килгән көнне, Органның Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре нигезендә, чират тәртибендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларның үтәлеше нәтиҗәләре булып тора: дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү фактын теркәү.

### 3.7. Техник хаталарны төзәтү

3.7.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып торган документта техник хата барлыгы беленгән очракта гариза бирүче (мөрәҗәгать итүче) Органга җибәрә:

техник хатаны төзәтү турында гариза (әлеге административ регламентка 5 нче кушымта);

муниципаль хезмәт нәтиҗәсе буларак гариза бирүчегә бирелгән техник хаталы документ;

техник хата булуны дәлилләүче юридик көчкә ия булган документлар.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән мәгълүматларда техник хатаны төзәтү турында гаризаны мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) почта аркылы (шул исәптән электрон почтаны кулланып) яки Республика порталы яисә КФҮ аша бирә.

3.7.2. Документлар кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, кушымта итеп теркәлгән документлар белән гаризаны терки һәм аларны документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гаризаны теркәү датасыннан бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка карауга юнәлтелгән кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.7.3. Документлар эшкәртүгә җаваплы вазыйфаи зат документларны карый һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм төзәтелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) техник хата булган документның төп нөсхәсен алып калып шәхсән кул куйдырып бирә яки гариза бирүче адресына почта аша (электрон почта ярдәмендә) Органга техник хата булган документның төп нөсхәсен тапшырганда документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хатаны ачыклаганнан яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң ике эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүгә контроль тәртибе һәм формалары

### 4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан регламент нигезләмәләрен һәм муниципаль хезмәт күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларны үтәүгә һәм башкаруга, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүгә агымдагы контрольне гамәлгә ашыру тәртибе

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгына һәм сыйфатына контроль мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуын ачыклау һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлүенә тикшерүләр уздыруны, җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешенә контроль формалары булып торалар:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү.

2) делопроизводствоны алып баруны билгеләнгән тәртиптә уздырылучы тикшерүләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларын үтәүгә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Агымдагы контроль максатларында электрон мәгълүматлар базасында булган белешмәләр, хезмәт урыны корреспонденциясе, административ процедураларны үтәүче вазыйфаи затларның телдән һәм язма мәгълүматы, тиешле документларны исәпкә алу журналлары һәм башка мәгълүматлар файдаланыла.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм җирле үзидарә органы җитәкчесенә карарлар кабул иткәндә гамәлләрнең башкарылуын тикшереп тору өчен муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр бирелә.

Административ процедураларның срокларын, эзлеклелеген һәм эчтәлеген бозу очраклары һәм сәбәпләре турында вазыйфаи затлар кичекмәстән муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенә хәбәр итәләр, шулай ук бозуларны бетерү буенча ашыгыч чаралар күрәләр.

Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контроль муниципаль хезмәт күрсәтү эшен оештыруга җаваплы җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары, муниципаль хезмәт күрсәтү эшен оештыручы бүлек башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге җирле үзидарә органының структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

## 4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфаты буенча планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне гамәлгә ашыру тәртибе һәм периодиклыгы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.2.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору түбәндәгеләр рәвешендә гамәлгә ашырыла:

1) тикшерүләр уздыру;

2) мөрәҗәгать итүчеләрнең органның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләрен карау.

4.2.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору максатларында планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрелә. Планлы тикшерүләрне уздыру тәртибе һәм ешлыгы (периодиклыгы) Органның эш планы белән билгеләнә. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле барлык мәсьәләләр (комплекслы тикшерүләр) яисә мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча каралырга мөмкин. Тикшерү шулай ук мөрәҗәгать итүченең конкрет шикаяте буенча үткәрелергә мөмкин.

4.2.3. Планнан тыш тикшерүләр алдан ачыкланган хокук бозуларны бетерү белән бәйле рәвештә үткәрелә, шулай ук Орган гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүчеләрнең шикаятьләре алынган очракта, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең.

4.2.4. Тикшерү нәтиҗәләре тикшерү акты рәвешендә рәсмиләштерелә, анда ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәр күрсәтелә.

## 4.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында үзләре тарафыннан кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен муниципаль хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затларының җаваплылыгы

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылган очракта гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

Җирле үзидарә органы җитәкчесе гариза-мөрәҗәгатьләрне вакытында тикшермәгән өчен җаваплы.

Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (җитәкче урынбасары) Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яисә) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә торган (гамәлгә ашырыла торган) карар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр законнарда билгеләнгән тәртиптә җаваплы булалар.

4.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне тикшереп тору тәртибенә һәм рәвешләренә таләпләрне сыйфатлаучы нигезләмәләр, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан да.

Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне тикшереп тору (контроль) муниципаль хезмәт күрсәткәндә җирле үзидарә органы эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәт алучылар муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган хезмәткәренең, җитәкчесенең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр тәртиптә шикаять бирү хокукына ия.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 маддәсендә күрсәтелгән гарызнамәне, муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гарызнамәне теркәү срокларын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, аның хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять

белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда тапшыру яисә гамәлгә ашыру каралмаган документларны яки мәгълүматны яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гамәлләр кылуны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда баш тарту нигезләре күздә тотылмаган булуга карамастан муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, аның хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин;

6) муниципаль хезмәт күрсәтүдә гариза бирүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, муниципаль район норматив хокукый актларында күздә тотылмаган түләүне таләп итү;

7) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмалар яисә аларның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хата һәм ялгышларны төзәтүне кире кагуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, аның хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирүнең срогын яисә тәртибен бозу;

9) федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары, муниципаль районның норматив хокукый

актларында муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатуга нигезләр күздә тотылмаган булуга карамастан, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату (туктатып тору);

Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, аның хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин;

10) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны баштагы кабул итүдәге кире кагуда юклыгы һәм (яки) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүматны муниципаль хезмәт күрсәтүдә, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ Федераль законның 7 маддәсе 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан гайре, мөрәҗәгать итүчедән таләп итү.

Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, аның хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин.

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазь йөрткечтә, электрон рәвештә муниципаль хезмәтне күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә яки күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы тиешле дәүләт хакимияте органына (алга таба – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы), шулай ук 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларга тапшырыла. Муниципаль хезмәтне күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр югарырак органга (ул булган очракта) бирелә яки ул булмаган очракта турыдан-туры муниципаль хезмәтне күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала. Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр шушы күпфункцияле үзәк җитәкчесенә бирелә. Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәкне оештыручыга яисә Татарстан Республикасының норматив хокукый акты белән вәкаләтле вазыйфаи затка тапшырыла. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр әлеге оешмалар җитәкчеләренә бирелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аркылы, күпфункцияле үзәк аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайтыннан, Бердәм порталдан яисә республика порталыннан, судка кадәр шикаять бирү мәгълүмат

системасыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта аша, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәкнең, Бердәм порталның яисә Республика порталының рәсми сайтыннан, судка шикаять бирүнең мәгълүмат системасы аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1 өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта аша, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, әлеге оешмаларның, Бердәм порталның яисә Республика порталының рәсми сайтларыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесе һәм (яисә) хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның җитәкчеләре һәм (яисә) хезмәткәрләренең исемнәрен (аталышларын);

2) мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), гариза бирүченең – физик затның яшәү урыны турында мәгълүматлар, гариза бирүченең – юридик затның урнашу урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (булган очракта) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы (булганда);

3) муниципаль хезмәтне күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүче алар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешми торган дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аның дәлилләрен раслаучы документлар (булганда) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.4. Килеп ирешкән шикаять кергән көннән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш.

5.5 Муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларга яисә югарырак органга (ул булганда) кергән шикаять теркәлгән көннән алып унбиш эш көне эчендә каралырга тиеш, ә муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларга карата шикаять белдерелгән очракта мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдә яки җибәрелгән хата һәм ялгышларны төзәтүдә яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылган очракта – аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.6.Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның кайсы да булса берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә түләтү Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартырга.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.7. Шикаятьнең канәгатьләндерелергә тиешле дип танылу очрагында мөрәҗәгать итүчегә шикаятьне карау нәтиҗәләре турындагы җавапта муниципаль хезмәт күрсәткәндә беленгән бозуларны кичекмәстән бетерү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмалар тарафыннан тормышка ашырылучы гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук күрсәтелгән уңайсызлыклар өчен кичерү сорала һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне алу максатларында гариза бирүчегә кылу зарур булган алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаятьнең канәгатьләндерелергә тиешле түгел дип табылу очрагында мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре хакында дәлилле аңлатмалар бирелә, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат китерелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре табылу очрагында шикаятьләрне карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрәләр.

Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кушымта №1

Рәвеш

(Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган бланкы)

БЕЛЕШМӘ

Электрон имза турында мәгълүматлар

Вазыйфаи зат (ФИАи) ______________________________________

(органның вәкаләтле вазыйфаи заты имзасы)

Белешмә (өземтә) бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
кушымта №2

Рәвеш

(Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган бланкы)

Кемгә: ___________________________
________________ ________________
Контакт мәгълүматлары:
______________ ________________
Вәкил: _________________
________________ ________________
Вәкилнең контакт мәгълүматлары:
________________ ________________

Белешмә (өземтә) бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында
КАРАР

20 ___ елның ____ _________ № _____

Сезнең 20 ___ елның ____ ______________ ____номерлы гаризагызны һәм аңа теркәлгән документларны карау нәтиҗәләре буенча
_________________________
вәкаләтле орган тарафыннан түбәндәге нигез буенча белешмә (өземтә) бирүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

Өстәмә мәгълүмат: ________________________________________.

| Электрон имза турында мәгълүматлар |
| --- |

Вазыйфаи зат (ФИАи) ____________________________________

(органның вәкаләтле вазыйфаи заты имзасы)

Белешмә (өземтә) бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
кушымта №3

Рәвеш

(Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган бланкы)

Кемгә: ___________________________
_________________ _________________
Контакт мәгълүматлары:
______________ _________________
Вәкил: __________________
_________________ _________________
Вәкилнең контакт мәгълүматлары:
_________________ _________________

Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында
КАРАР

20 ___ елның ____ __________ № _____

Сезнең 20 ___ елның ____ ______________ ____номерлы гаризагызны һәм аңа теркәлгән документларны карау нәтиҗәләре буенча
_________________________
вәкаләтле орган тарафыннан түбәндәге нигезләр буенча белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

1. ______________________________________________________________________
2. ______________________________________________________________________

Кире кагу сәбәпләренә аңлатма: ________________________________________
Өстәмә мәгълүмат: ___________________________________________

Күрсәтелгән (хокук) бозулар бетерелгәннән соң хезмәт күрсәтү турында гариза белән сез вәкаләтле органга кабаттан мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Әлеге кире кагу судка кадәр шикаятьне вәкаләтле органга җибәрү юлы белән, шулай ук суд тәртибендә шикаять ителергә мөмкин.

| |
|---|
| Электрон имза турында мәгълүматлар |

Вазыйфаи зат (ФИАи)

______________________________

(органның вәкаләтле вазыйфаи заты имзасы)

Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кушымта №4

Рәвеш

(җирле үзидарә органының исеме (аталышы))

______________________________

______________________________

______________________________

______________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт мәгълүматлары, яшәү урыны буенча теркәлү, электрон почта адресы, телефон)

белешмә (өземтә) бирү турында
ГАРИЗА

Сездән ______________________________ белешмә (өземтә)
(белешмәнең төрен күрсәтергә)
бирүегезне үтенәм.

Гаризага теркәлә:

______________________________

______________________________

______________________________

______________________________

______________________________

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирүегезне үтенәм:

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталының шәхси кабинетына;

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә;

☐ ***Органда.***

______________ ________________ ( ________________)

(дата) (имза) (Ф.И.А.и.)

Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кушымта №5

Башкарма комитет җитәкчесе
______________________________
____________________________

техник хатаны төзәтү турында
ГАРИЗА.

______________________________________________муниципаль хезмәт
(күрсәтелгән хезмәтнең исеме)
күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.
Язылган:______________________________________________________________
___________________________________________________________________________
Дөрес мәгълүматлар:____________________________________________________________
_______________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып торган документка тиешле үзгәрешләрне кертүне үтенәм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.
3.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кире кагу хакында карар кабул иткән очракта андый карарны җибәрүне үтенәм:

электрон документны E-mail________________адресына җибәрү ярдәмендә; почта аша кәгазь йөрткечтә расланган күчермә рәвешендә түбәндәге адрес буенча: _________________________________________________________________ ___

Әлеге гариза белән раслыйм: гаризадагы минем шәхескә һәм минем тарафтан тәкъдим ителүче затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры киләләр, гаризаны бирү моментына бу документлар чын һәм дөрес мәгълүматларны үз эчләренә алалар.

_______________ __________________ ( _________________)
(дата) (имза) (Ф.И.А.и.)

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Балык Бистәсе шәһәр
җирлеге Башкарма комитетының
2022 елның 31 мартындагы
29 номерлы карарына
кушымта №8

# Элегрәк хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

### 1.1. Административ регламентны җайга салу предметы

1.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – административ регламент) элегрәк хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең (алга таба – муниципаль хезмәт) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.1.2. Административ регламент нигезләмәләре Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге территориясендә урнашкан элегрәк хосусыйлаштырылган торак урыннарга (биналарга) карата кулланыла.

### 1.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре

1.2.1. Муниципаль хезмәт алуга хокукы булган затлар – физик затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

1.2.2. Гариза белән мөрәҗәгать итүченең үз вәкаләтләрен таныклый торган документ нигезендә эш итүче вәкиле яки физик затның законлы вәкиле мөрәҗәгать итәргә хокуклы (алга таба – мөрәҗәгать итүче вәкиле).

### 1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мәгълүмат бирү (хәбәр итү) тәртибе

1.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат урнаштырыла:

1) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре биналарында урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендларында;

2) муниципаль районның “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге https://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru/ рәсми сайтында;

3) Татарстан Республикасының https://uslugi.tatarstan.ru дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр Порталында (алга таба – Республика порталы);

4) http:// www.gosuslugi.ru Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләр) порталында (алга таба – Бердәм портал);

5) “Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры” дәүләт мәгълүмат системасында (http://frgu.tatar.ru) (алга таба – Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры).

1.3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча консультация (мәслихәт) бирү гамәлгә ашырыла:

1) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яисә телефон буенча;

2) Республика порталының интерактив рәвешендә;

3) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетында (алга таба – Орган):

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яисә телефон буенча;

язма рәвештә (шул исәптән электрон документлар рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә – кәгазь йөрткечтә почта аша, электрон рәвештә электрон почта аша.

1.3.3. Бердәм порталда, Республика порталында Республика реестрындагы мәгълүматлар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат гариза бирүчегә бушлай бирелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка мөрәҗәгать итүченең нинди дә булса таләпләр үтәмичә генә, шул исәптән, мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштыру гариза бирүчедән түләү алуны, теркәүне яисә авторизацияне күздә тотучы программа тәэмин ителешенең хокук иясе белән лицензияле яисә башка килешү төзүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча яисә аларга шәхси мәгълүматлар бирмичә керү мөмкинлеге гамәлгә ашырыла.

1.3.4. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә телефон аша мөрәҗәгать иткәндә кергән мөрәҗәгать нигезендә түбәндәге мәгълүмат бирелә:

19) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, Органның урнашкан урыны турында (адресы, эш графигы, белешмә телефоннары);

20) муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында, гаризалар бирү ысуллары һәм сроклары турында;

21) муниципаль хезмәт күрсәтелә торган гражданнар категорияләре турында; муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләрен җайга сала торган норматив хокукый актлар турында;

22) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны карау өчен кирәкле документлар исемлеге турында, гаризаны кабул итү һәм теркәү сроклары турында;

23) муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында;

24) муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүматның рәсми сайтында урнашу урыны турында;

7) Органның вазыйфаи затларының (урындагы кешеләренең) гамәлләренә яисә гамәл кылмауларына карата шикаять белдерү тәртибе турында.

Язма мөрәҗәгать буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы бүлекнең вазыйфаи затлары мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен һәм регламентның әлеге пунктында күрсәтелгән мәсьәләләрне язма рәвештә аңлаталар һәм мөрәҗәгатьне теркәгәннән соң өч эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрәләр. Җаваплар мөрәҗәгать иткән телдә бирелә. Мөрәҗәгать иткән телдә җавап бирү мөмкин булмаган очракта Татарстан Республикасы дәүләт телләре кулланыла.

1.3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат муниципаль районның рәсми сайтында һәм Орган бүлмәләрендәге гариза бирүчеләр белән эшләү өчен куелган мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

“Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге муниципаль районның рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларында урнаштырылган Татарстан Республикасы Дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге Регламентның 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы үзидарәлек хезмәте турындагы мәгълүматларны, Органның урнашу урыны, белешмә телефоннары, эш вакыты, муниципаль хезмәт күрсәтүгә гаризалар кабул итү графигы турында мәгълүматны үз эченә ала.

## 1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге

1.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актлар реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп) Бердәм порталда, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта, Республика реестрында урнаштырылган.

1.4.2. Гамәлдәге редакциядә административ регламент тексты Бердәм порталда, Республика реестрында, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштырылырга тиеш.

## 1.5. Административ регламентта кулланыла торган терминнар һәм аларның билгеләмәләре

1.5.1. Регламентта түбәндәге атамалар (терминнар) һәм билгеләмәләр файдаланыла:

дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтү күпфункцияле үзәгенең ераклашкан эш урыны – 2012 елның 22 декабрендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтү күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләрен раслау турында” 1376 номерлы

карары белән расланган дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтү күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районының шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында төзелгән дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтү күпфункцияле үзәгенең территория ягыннан аерымланган структура бүлекчәсе (офисы);

техник хата – үзидарәлек хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка кертелгән (үзидарәлек хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсенә) мәгълүматларга тәңгәл булмауга, алар нигезендә кертелгән мәгълүматларның документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китерүче ялгыш (ялгышлык белән җибәрелгән хәреф, сүз хатасы, грамматик яки арифметик хата яисә шуларга охшаш ялгышлыклар).

Электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик үзара хезмәттәшлеген (багланышын) тәэмин итүче инфраструктурада идентификацияләүнең (бердәйләштерүнең, тәңгәлләштерүнең) һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы (алга таба – ЕСИА (Единая система идентификации и аутентификации)) – дәүләт мәгълүмат системаларында һәм башка мәгълүмат системаларында булган мәгълүматны идентификацияләү һәм аутентификацияләү системасында мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучыларның санкцияләнгән файдалана алуын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы;

КФҮ – “Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге” дәүләт бюджет учреждениесе;

КФҮ нең АМС – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы.

1.5.3. Регламентта муниципаль (үзидарәлек) хезмәте күрсәтү турындагы гариза дигәндә (алга таба – гариза) үзидарәлек хезмәте күрсәтү турында “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 маддәсенең 3 пункты (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә бирелгән гарызнамә (рәсми таләп) аңлашыла.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

### 2.1. Муниципаль хезмәтнең аталышы

Элегрәк хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү

### 2.2 Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарәнең башкарма-боеручы органының исеме (аталышы)

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты

### 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау

2.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып тора:

1) хосусыйлаштырылган торак урыннарын муниципаль милеккә кабул итү турында карар;

2) торак урынны муниципаль милеккә түләүсез тапшыру шартнамәсе;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар (әлеге административ регламентка 1 нче кушымта);

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар (әлеге административ регламентка 2 нче кушымта).

2.3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе “Электрон имза турында” 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә мөрәҗәгать итүчегә Бердәм порталның шәхси кабинетына Органның вәкаләтле вазыйфаи затының (яисә Органның) көчәйтелгән квалификацияле электрон култамгасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә. Гариза Республика порталы ярдәмендә җибәрелгән очракта муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе Республика порталының шәхси кабинетына да җибәрелә.

2.3.3. Мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе Органда яки КФҮтә кәгазьдә йөрткечтәге электрон документ нөсхәсе рәвешендә бирелә, ул тиңдәшле рәвештә Органның вәкаләтле вазыйфаи заты яисә КФҮ хезмәткәре имзасы һәм мөһер белән таныкланган була.

2.3.4. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәтне күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең гамәлдә булу срогы дәвамында алырга хокуклы.

### 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы

2.4.1. Муниципаль хезмәт 12 эш көне эчендә күрсәтелә.

2.4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктату каралмаган.

2.4.3. Электрон документ рәвешендә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документны җибәрү муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

### 2.5. Үзидарәлек хезмәте күрсәтү өчен законнар яки башка норматив хокукый актлар нигезендә гариза бирүче тапшырырга тиешле зарури документларның, шулай ук үзидарәлек хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган

хезмәтләрнең тулы исемлеге, аларны гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Муниципаль хезмәт алу өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тапшыра:

1) шәхесне таныклаучы документ (Республика порталы ярдәмендә мөрәҗәгать иткәндә таләп ителми);

2) мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ;

3) гариза:

кәгазь йөрткечтәге документ рәвешендә (әлеге административ регламентка 3 нче кушымта);

электрон рәвештә (тиешле мәгълүматларны гаризаның электрон рәвешенә кертү юлы белән тутырыла), ул Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә Регламентның 2.5.3 пункты таләпләре нигезендә имзалана.

4) гаиләнең һәр әгъзасының шәхесен таныклаучы документлар;

5) торак урынга милек хокукын раслаучы документ (әгәр милек Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында теркәлмәгән булса);

6) яшәү урыныннан белешмә;

7) торак урынның техник паспорты күчермәсе;

8) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты опека һәм попечительлек бүлегенең торак урынны муниципаль милеккә түләүсез тапшыру турындагы рөхсәтнамәсе (әгәр хосусыйлаштыруда балигъ булмаган балалар катнашкан булса).

2.5.2 Гариза һәм теркәп бирелә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

1) КФҮ аша кәгазь йөрткечләрдә һәм Регламентның 2.5.3 пункты таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә;

2) Республика порталы аша электрон рәвештә.

3) Органда шәхсән яки кәгазь йөрткечтә почта элемтәсе ярдәмендә.

Гариза һәм теркәлә торган документлар почта элемтәсе аша җибәрелгәндә билгеләнгән тәртиптә таныклана.

2.5.7. Республика порталы аша җибәрелгәндә гариза мөрәҗәгать итүченең гади электрон култамгасы белән имзалана.

Гади электрон имза алу өчен гариза бирүчегә ЕСИА да теркәлү (аутентификацияләү) процедурасын узарга, шулай ук хисап язмасын расларга кирәк.

Регламентның 2.5.1 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән электрон документлар (документларның электрон үрнәкләре) мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затлар, шул исәптән нотариуслар тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон култамга белән имзаланалар.

Гаризага теркәлеп бирелә торган электрон документлар (электрон документлар үрнәкләре), шул исәптән ышанычнамәләр pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc,

docx, rtf форматларында 50 Мбайттан да артмаган күләмдә файллар рәвешендә җибәрелә.

Электрон документларның (электрон документлар үрнәкләренең) сыйфаты документ текстын тулы күләмдә укырга һәм документ реквизитларын танырга мөмкинлек бирергә тиеш.

2.5.8. Мөрәҗәгать итүчедән таләп итү тыела:

1) муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшыру яисә гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыру яисә гамәлләр кылуны;

2) муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле һәм башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга мөрәҗәгать итү белән бәйле гамәлләрне, шул исәптән килештерүләрне гамәлгә ашыруны, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 9 маддәсенең 1 өлешендә күрсәтелгән исемлекләргә кертелгән мондый хезмәтләр (кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр) күрсәтү нәтиҗәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрне һәм документларны алудан гайре;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны башта кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәткәндә баш тартканда документларның һәм мәгълүматның булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүматны тапшыруны, түбәндәге очраклардан гайре:

а) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза башта бирелгәннән соң муниципаль хезмәт күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актлар таләпләренең үзгәрүе;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризада һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны баштагы кабул итүдән баш тартканнан соң мөрәҗәгать итүче биргән документларда яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдә элек бирелгән документлар комплектына кертелмәгән хаталар булу;

в) документларның гамәлдә булу вакыты чыгу яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән башта баш тартканнан соң яки муниципаль хезмәт күрсәтүдә мәгълүмат үзгәрү;

г) Органның вазыйфаи затының, КФҮ хезмәткәренең муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне баштагы кире какканда яисә муниципаль хезмәт күрсәткәндә хаталы яки хокукка каршы гамәл кылуының (гамәл кылмавының) документаль расланган факты (билгеләре) ачыклану, әлеге муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу очрагында Орган җитәкчесе имзасы белән язма рәвештә мөрәҗәгать итүчегә хәбәрнамә ирештерелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә;

4) электрон рәвешләре 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсендәге 1 өлешенең 7.2 пункты нигезендә элек расланган документларны һәм мәгълүматны кәгазь йөрткечтә тапшыру, мондый документларга тамга салу яисә аларны алу дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан гайре.

2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә зарур булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хаклы документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма.

2.6.1. Ведомствоара хезмәттәшлек (багланышлар) кысаларында алына:

17) гражданнарны теркәү турында мәгълүматлар – ЗАГС органнары;

18) Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан аерым затның хәзерге (элек булган) күчемсез мөлкәт объектларына хокуклары турында өземтә – Росреестр;

19) Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан күчемсез мөлкәт объектына төп сыйфатламалар һәм теркәлгән хокуклар турында өземтә – Росреестр;

20) Россия Федерациясе гражданының гамәлдәге паспорты турында мәгълүматлар – Россия ЭЭМ;

5) нотариаль ышанычнамә турында мәгълүматлар - Федераль нотариаль палата.

2.6.2. Мөрәҗәгать итүче Регламентның 2.6.1 пунктының 1-3 пунктчаларында күрсәтелгән документларны (мәгълүматларны) мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затларның көчәйтелгән квалификацияле култамгасы белән таныкланган электрон документлар рәвешендә гариза биргәндә тапшырырга хокуклы.

2.6.3. Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар тарафыннан документлар һәм мәгълүматларны тапшырмау (вакытында тапшырмау) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.6.4. Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән органнарның соралган һәм карамагында булган документларны яисә мәгълүматларны тапшырмаган (үзвакытында тапшырмаган) вазыйфаи заты һәм (яисә) хезмәткәре Россия Федерациясе законнары нигезендә административ, дисциплинар яисә башка җаваплылыкка тартылырга тиеш.

2.6.5. Гариза бирүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар карамагындагы документларны һәм мәгълүматларны, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәткән өчен гариза бирүче тарафыннан түләү кертүне раслый торган мәгълүматларны таләп итү тыела.

Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалар карамагында булган мәгълүматларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырмау мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

## 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

7) тапшырылган документларда текстның бетерелгән (сөртелгән) һәм Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланмаган төзәтмәләре бар.

8) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлардагы зарарланулар мәгълүматны тулы күләмдә кулланырга, текстны укырга һәм (яки) танырга мөмкинлек бирми;

3) тапшырылган документлар яисә мәгълүматлар муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итү вакытына үз көчләрен югалтканнар (вәкил муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклаучы документ);

4) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар билгеләнгән таләпләрне бозып, электрон формада бирү;

5) гариза формасындагы мәҗбүри кырларны, шул исәптән Республика порталындагы гаризаның интерактив рәвешендә, дөрес тутырмау (дөрес түгел, тулы булмаган яисә дөрес тутырылмаган);

6) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мәҗбүри булган регламентта каралган документларның тулы булмаган комплекты бирелгән;

7) хезмәт күрсәтү турында гариза муниципаль хезмәт күрсәтү вәкаләтләренә керми торган дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына яисә оешмага тапшырылган;

8) “Электрон имза турында” 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 маддәсендә билгеләнгән көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаның чынлыгын тану шартларын үтәмәү.

2.7.2. Муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге төгәл булып тора.

2.7.3. Гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү вакытында да, органның җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны (мәгълүматларны) ведомствоара мәгълүмати багланышны файдаланып алганнан соң да, гаризаны теркәгәннән соң 9 эш көненнән дә артмаган срокта кабул ителергә мөмкин.

2.7.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда, Республика порталында бастырылган муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

## 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр күздә тотылмый.

2.8.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге:

1) гариза бирүче документларны тулы күләмдә тапшырмаган яки тәкъдим ителгән гаризада һәм (яисә) документларда тулы булмаган һәм (яисә) дөрес булмаган мәгълүмат бар;

2) әгәр тиешле документ мөрәҗәгать итүченең үз инициативасы белән күрсәтелмәгән булса, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында сөйләүче дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының яки дәүләт хакимиятенең ведомство буйсынуындагы органының яисә җирле үзидарә органының ведомствоара гарызнамәгә җавабы килеп ирешү.

2.8.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге төгәл булып тора.

2.8.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза Бердәм порталда, Республика порталында игълан ителгән (бастырылган) муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту тыела.

## 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алынучы дәүләт пошлинасы һәм бүтән түләүнең тәртибе, күләме һәм түләтү нигезе

Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә.

## 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында мәгълүматлар

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

## 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтүгә түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

## 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамә биргәндә, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәт күрсәтелгәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты

2.12.1. Муниципаль хезмәт алуга гариза биргәндә көтү вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.12.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең гарызнамәсен һәм хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтне теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон рәвештә

2.13.1. Гариза биргән көнне КФҮкә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүчегә гаризаның җибәрелүен раслаучы теркәлү номеры һәм электрон гаризаны бирү датасы белән КФҮ АМС ннан раслама бирелә.

2.13.2. Гаризаны Республика порталы ярдәмендә юллаганда мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Республика порталының шәхси кабинетында һәм электрон почта аша, гаризаның теркәлү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелеп, гаризаның җибәрелүен раслый торган хәбәрнамә ала.

2.13.3. Органга шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гариза биргән көнне вәкаләтле вазыйфаи зат Органга мөрәҗәгать итүчегә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан теркәү номеры, гариза бирү датасы һәм тапшырылган документлар исемлеге белән раслама бирә.

2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, көтү залына, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамәләрне тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре һәм һәр муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге булган мәгълүмат стендларына карата, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыру һәм бизәүгә, шул исәптән әлеге объектларга инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвалидлар өчен үтү (керү) мөмкинлеген тәэмин итүгә таләпләр

2.14.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебельләр, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

2.14.2. Инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү (үтү) максатларында түбәндәгеләр тәэмин ителә:

32) инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына каршылыксыз керүе (үтә алуы) тәэмин ителә (бина-бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм алар эчендә күчену, хәрәкәт итү).

33) муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

34) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләренең ныклы тайпылышлары булган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

35) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм алардан чыгу, транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

36) инвалидларның хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөрткечләрне аларның тереклек эшчәнлегенең чикләнгәнлеген исәпкә алып тиешенчә урнаштыру;

37) инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук өсьязуларны, билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайль рельеф-ноктaлы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау;

38) сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчегә рөхсәт итү;

8) озатучы-этне махсус укыту-өйрәтүне раслаучы һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының “Озатучы-этне махсус укытуны раслый торган документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында” 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән билгеләнгән рәвештә һәм тәртиптә бирелгән документы булганда рөхсәт итү.

2.14.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектлардан һәм муниципаль хезмәт күрсәткәндә кулланыла торган Регламентның 2.14.2 пунктының 1 – 4 пунктчаларында күрсәтелгән чаралардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр, алар 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизацияләнгән объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

2.15. Муниципаль хезмәтнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән муниципаль хезмәт күрсәткәндә үзара багланышлары саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләрен кулланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы күләмдә), җирле үзидарәнең башкарма-боеру органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә муниципаль хезмәт алу мөмкинлеге яисә мөмкин түгеллеге, мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча (экстерриториаль принцип), 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 маддәсендә каралган күпфункцияле үзәкләрдә берничә дәүләт һәм (яисә) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамә (комплекслы гарызнамә) ярдәмендә

2.15.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкинлеге (доступность) күрсәткечләре булып тора:

документлар кабул итү, бирү алып барыла торган бинаның җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итүне гамәлгә ашыра торган бүлмәләрнең кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, муниципаль районның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында муниципаль хезмәтне күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

инвалидларга башкалар белән бер үк дәрәҗәдә хезмәтләр алырга комачаулаучы киртәләрне җиңәргә ярдәм итү.

2.15.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләр:

1) документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;

2) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу срогын үтәү;

3) орган хезмәткәрләре тарафыннан Регламентны бозуга карата нигезле шикаятьләр булмау;

4) мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән багланышлары саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең КФҮ хезмәткәрләре белән багланышы барлык кирәкле документлар белән гариза биргәндә бер тапкыр гамәлгә ашырыла;

бер тапкыр Органда яки КФҮ тә электрон документның нөсхә рәвешендә кәгазь йөрткечтәге муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу кирәк булган очракта.

Муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бер мәртәбә багланышының дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.

Мөрәҗәгать итүче күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын Республика порталы, терминал җайланмалары аша бәяләргә хокуклы.

2.15.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүматны мөрәҗәгать итүче Бердәм порталда яисә Республика порталында шәхси кабинетта, Органда, КФҮ тә алырга мөмкин.

2.15.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча яшәү урынына яисә фактта яшәү (булу) урынына бәйсез рәвештә Татарстан Республикасы территориясендә экстерриториаль принцип буенча.теләсә кайсы КФҮ тә гамәлгә ашырыла.

Комплекслы гарызнамә составында муниципаль хезмәт күрсәтелми.

## 2.16. Башка таләпләр, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча (әгәр муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә икән) муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алып, һәм электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре

2.16.1. Муниципаль хезмәт электрон рәвештә күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хаклы:

16) Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

17) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон рәвешләре 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсендәге 1 өлешенең 7.2 пункты нигезендә Республика порталыннан файдаланып таныкланган документлар һәм мәгълүмат бирүгә;

18) электрон рәвештә бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында мәгълүматлар алырга;

19) муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;

20) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә алырга;

6) Республика порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә кылынган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауларга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итүче федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Органның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирергә.

2.16.2. Гаризаны формалаштыру Республика порталында гаризаның электрон рәвешен тутыру юлы белән нинди дә булса башка рәвештә гариза бирү зарурлыгыннан башка гамәлгә ашырыла.

2.16.3. Гаризаны формалаштырганда түбәндәгеләр тәэмин ителә:

19) гаризаны һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны күчермәләү һәм саклау мөмкинлеге;

20) берничә мөрәҗәгать итүче тарафыннан уртак гариза җибәрүне күздә тоткан хезмәтләр сорап мөрәҗәгать иткәндә гаризаның бер электрон рәвешен берничә мөрәҗәгать итүченең бергә тутыру мөмкинлеге;

21) гаризаның электрон рәвеше күчермәсен кәгазь йөрткечтә бастыру мөмкинлеге;

22) кулланучы теләге буенча теләсә кайсы вакытта электрон рәвешкә элек кертелгән кыйммәтләрне саклап калу, шул исәптән кертү хаталары барлыкка килгәндә һәм кыйммәтләрне гаризаның электрон формасына кабат кертү өчен кире кайтару;

23) гаризаның электрон рәвеше кырларын гариза бирүче тарафыннан, ЕСИА да урнаштырылган мәгълүматлардан файдаланып, мәгълүматларны кертә башлаганчы тутыру һәм Бердәм порталда, Республика порталында бастырылган мәгълүматларны идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасында булмаган мәгълүматларга кагылышлы өлешендә куллану;

24) элек кертелгән мәгълүматны югалтмыйча, гариза электрон формасын тутыруның теләсә кайсы этапларына кире кайту мөмкинлеге;

7) мөрәҗәгать итүченең республика Порталында элек бирелгән гаризаларга бер елдан да ким булмаган, шулай ук өлешчә формалаштырылган гаризаларга - кимендә 3 ай эчендә керә алу мөмкинлеге.

2.16.4. Мөрәҗәгать итүчеләрнең КФҮ кә кабул итүгә язылуы (алга таба – язылу) Республика порталы, КФҮнең контакт-үзәге телефоны аша башкарыла.

Мөрәҗәгать итүчегә кабул итү өчен теләсә нинди буш вакытка күпфункцияле үзәкнең кабул итү графигының билгеләнгән чикләрендә язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу бу датага кадәр бер тәүлек кала төгәлләнә.

Республика порталы ярдәмендә алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә система тарафыннан соратыла торган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилия, исем, атасының исемен (булган сурәттә);

телефон номерын;

электрон почта адресын (теләк буенча);

теләгән кабул итү датасын һәм вакытын.

Мөрәҗәгать итүче алдан язылу вакытында хәбәр иткән мәгълүматларның шәхси кабул итү вакытында гариза бирүче биргән документлардагы мәглүматларга туры килмәве очрагында алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда мөрәҗәгать итүчегә талон-раслауның распечаткасын алу мөмкинлеге бирелә.

Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын хәбәр итсә, күрсәтелгән адреска, кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда гариза бирүчегә мәҗбүри рәвештә, билгеләнгән кабул итү вакытына килмәгән очракта кабул итү вакытыннан 15 минут узгач, алдан язылу гамәлдән чыгарылуы турында хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүчедән, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан гайре, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен броньларга кирәк булган вакытлыча интервал дәвамлылыгын исәпләү өчен зарури мәгълүматлар бирүдән башка гамәлләр кылуны таләп итү тыела.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәтләр күрсәткәндәге гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә (гариза бирүчегә) консультация (мәслихәт) бирү;

2) мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар комплектын (тупламын) кабул итү һәм карау;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара гарызнамәләр җибәрү;

4) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;

5) мөлкәтне муниципаль милеккә түләүсез тапшыру шартнамәсен төзү;

6) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

7) техник хаталарны төзәтү.

.

### 3.2. Гариза бирүче (мөрәҗәгать итүче) белән консультацияләр үткәрү (мәслихәт бирү)

3.2.1. Административ процедураны үтәүне башлауның нигезе – мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгате.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы урындагы кеше (хезмәткәр) булып тора:

мөрәҗәгать итүче КФҮ кә мөрәҗәгать иткәндә – КФҮ хезмәткәре;

мөрәҗәгать итүченең Органга мөрәҗәгатендә – Органның әйдәүче белгече (алга таба – консультация (мәслихәт) бирү өчен җаваплы урындагы кеше).

3.2.2. Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында консультация сорап КФҮ тә шәхсән һәм телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә консультация бирә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тапшырыла торган документациянең составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча.

Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүматны КФҮ нең http://mfc16.tatarstan.ru сайтыннан ирекле файдалану юлы белән алырга мөмкин.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелә торган документациянең составы, формасы һәм муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча консультация.

3.2.3. Мөрәҗәгать итүче телефон һәм электрон почта аша Органга мөрәҗәгать итәргә, шулай ук Республика порталында, Органның муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында сайтында консультация алырга хокуклы, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тапшырыла торган документациянең составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча.

Консультация бирү өчен җаваплы вазыйфаи зат Регламентның 1.3.4 пункты таләпләре нигезендә мөрәҗәгать итүчегә мәгълүмат бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать кергән көннән алып өч эш көне эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелә торган документациянең составы, формасы һәм муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча консультацияләр.

### 3.3. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар комплектын (тупламын) кабул итү һәм карау

3.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документларны КФҮ яки КФҮнең ераклашкан эш урыны аша кабул итү.

3.3.1.1. Мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамә белән КФҮкә мөрәҗәгать итә һәм Регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны тапшыра.

3.3.1.2. Гаризаларны кабул итүче КФҮ хезмәткәре:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый;

мөрәҗәгать предметын билгели;

документлар бирүче затның вәкаләтләрен тикшерә;

документларның Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен тикшерә;

КФҮнең АМС на гаризаның электрон формасын тутыра;

Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар кәгазь йөрткечтә тапшырылганда, тапшырылган документларны сканерлауны гамәлгә ашыра;

КФҮ нең АМС нан гаризаның распечаткасын ала;

мөрәҗәгать итүчегә тикшерүгә һәм кул куюга тапшыра;

имза салганнан соң кул куелган гаризаны КФҮ нең АМС нда сканерлый;

электрон формада яки электрон рәвештәге сканерланган тәкъдим ителгән документларны КФҮ нең АМС на кертә (йөкли), электрон дело (эш) формалаштыра;

имзаланган гаризаны һәм кәгазь документларның төп нөсхәләрен кире кайтара;

мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү хакында раслама бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: җибәрергә әзер гариза һәм документлар пакеты.

3.3.1.3. КФҮ хезмәткәре мөрәҗәгать итүчедән кабул ителгән документлар пакетын (электрон эшләр пакетлары составында) КФҮ нең структур бүлекчәсенә мөрәҗәгать иткән көннән бер эш көне эчендә электрон формада Органга җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: электрон бәйләныш системасы ярдәмендә Органга җибәрелгән гариза һәм документлар пакеты (электрон эш).

3.3.2. Республика порталы аша муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәтү өчен документлар кабул итү.

3.3.2.1. Гаризаны Республика порталы аша электрон рәвештә бирү өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

авторизацияне башкара;

электрон гариза формасын (рәвешен) ача;

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган мәгълүматларны үз эченә алган электрон гариза рәвешен тутыра;

документларны электрон формада яисә электрон документлар образларын электрон гариза формасына беркетә (зарурлык булганда);

электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтүнең шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамганы билгели);

хәбәр ителгән мәгълүматларның дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамганы билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасында тиешле төймәгә баса);

электрон гариза Регламентның 2.5.3 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаны  җибәрү турында хәбәрнамә ала.

Формалаштырылган гаризаны формат-логик тикшерү гариза бирүче тарафыннан һәр кырның электрон формасы тутырылганнан соң гамәлгә ашырыла. Тиешенчә (дөрес) тутырылмаган электрон гариза кырын ачыклаганда, мөрәҗәгать итүче ачыкланган хатаның характеры һәм аны мәгълүмати хәбәр итү юлы белән турыдан-туры гаризаның электрон формасында бетерү тәртибе турында хәбәр итә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән административ процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә Органга юнәлтелгән электрон эш тора.

3.3.3. Орган тарафыннан документлар  тупламын карау.

3.3.3.1. Административ процедураны үтәүне башлауга нигез булып муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм башка документлар килеп ирешү тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы урындагы кеше (хезмәткәр) –  әйдәүче белгеч (алга таба – документларны кабул итү өчен җаваплы урындагы кеше).

3.3.3.2. Документлар кабул итү өчен җаваплы урындагы кеше, мөрәҗәгать итүченең Органга гаризасы белән мөрәҗәгать иткән очракта:

мөрәҗәгать предметын билгели;

гариза бирүченең шәхесен тәгаенли;

документлар бирүче затның вәкаләтләрен тикшерә;

регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен тикшерә, тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү үткәрә (документлар күчермәләренең тиешенчә рәсмиләштерелүен, документларда бетереп төзәтүләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм башка килешенмәгән төзәтмәләр булмауны тикшерә);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасында гаризаның электрон формасын тутыра;

регламентның 2.5 пунктында кәгазь йөрткечтәге документларны тапшырганда, тапшырылган документларны сканерлауны гамәлгә ашыра;

гаризаның распечаткасын ала;

мөрәҗәгать итүчегә тикшерү һәм имзалау өчен бирә;

кул куелганнан соң имзаланган гариза сканерлана;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасына электрон формада тәкъдим ителгән документларны яки электрон рәвештәге документларны йөкли, электрон эш формалаштыра;

имзаланган гаризаны һәм кәгазь документларның төп нөсхәләрен гариза бирүчегә кире кайтара;

гариза бирүчегә документларны кабул итү өчен раслама бирә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат мөрәҗәгать итүчегә гаризаны кабул итү өчен киртәләр булу турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, аңа документларны кире кайтара.

3.3.3.3. Документлар кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат, документлар каралуга кергәннән соң:

гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә номер һәм “Документларны тикшерү” статусы бирә;

килеп ирешкән электрон эшләрне, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан кушымта итеп бирелгән электрон формадагы документларны һәм документларның электрон рәвешләрен (образларын) өйрәнә;

документларның комплектлылыгын (тупланганлыгын), документларның электрон образларының (рәвешләренең) укылышын тикшерә;

Бердәм порталга мөрәҗәгать итү юлы белән электрон култамганың чын (дөрес) булу шартларының үтәлүен тикшерә (гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон култамга белән имзаланган электрон документлар рәвешләре тапшырылган очракта).

Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булганда, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын әзерли.

Көчәйтелгән квалификацияле электрон култамганы тикшерү нәтиҗәсендә аның чын булу шартларын үтәмәү ачыкланган очракта, баш тарту турындагы карар проектында аны кабул итүгә нигез булган 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 маддәсе пунктлары булырга тиеш.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проекты, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп (әгәр дә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуның нигезләре мондый документларга карата билгеләнгән таләпләрне бозу

белән бәйле булса, документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрдә дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы белешмәләр булган, билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән алдан тәкъдим ителмәгән документлар (мәгълүмат, белешмәләр) исеме турында мәгълүмат булырга тиеш), билгеләнгән тәртиптә электрон документ әйләнеше системасы аша килештерүгә җибәрелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проектын килештерү Регламентның 3.5.3 пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат, гариза кергән көннән алып бер эш көне эчендә гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә гаризаның теркәү номеры, гаризаны алу датасы, файлларның исемнәре, аңа тәкъдим ителгән документлар исемлеге, муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу датасы булган гариза килеп ирешү турында хәбәрнамә җибәрә.

3.3.3.4. Регламентның 3.3.3.1, 3.3.3.3 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

3.3.3.5. Регламентның 3.3.3 пункты белән билгеләнә торган процедуралар гариза карауга кергән көннән бер эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: карауга кабул ителгән документлар тупламы яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты.

### 3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара гарызнамәләр юллау

3.4.1. Административ процедураны үтәүне башлау өчен нигез булып мөрәҗәгать итүчедән алынган документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи заттан (хезмәткәрдән) административ процедураны башкаруга вәкаләтле вазыйфаи затның (хезмәткәрнең) алуы тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы урындагы кеше (хезмәткәр) булып җитәкче урынбасары тора (алга таба – ведомствоара гарызнамәләр җибәрү өчен җаваплы урындагы кеше).

3.4.2. Ведомствоара гарызнамәләр җибәрү өчен җаваплы урындагы кеше ведомствоара электрон багланышлар системасы аша (техник мөмкинлек булмаганда – башка ысуллар белән) электрон рәвештә Регламентның 2.6.1 пунктында каралган документларны һәм мәгълүматларны тапшыруга гарызнамәләр формалаштыра һәм җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар карау өчен гариза кабул ителгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: хакимият органнарына һәм (яки) хакимият органнарына буйсынган оешмаларга юлланган гарызнамәләр.

3.4.3. Белешмәләр белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре, ведомствоара электрон багланыш системасы аша кергән гарызнамәләр нигезендә, соратыла торган документларны (мәгълүматны) тапшыралар яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмау турында хәбәрнамәләр юллыйлар (алга таба – кире кагу турында хәбәрнамә).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар документ һәм мәгълүмат бирә торган органга яки оешмага ведомствоара гарызнамә кергән көннән өч көн эчендә башкарыла, әгәр ведомствоара гарызнамәгә җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актларында һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында билгеләнмәсә.

Процедураларның нәтиҗәсе: муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар (мәгълүматлар) яки ведомствоара гарызнамәләр җибәрү өчен җаваплы урындагы кешегә юлланган баш тарту турында хәбәрнамә.

3.4.4. Ведомствоара гарызнамәләр җибәрү өчен җаваплы урындагы кеше:

ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар (мәгълүматлар) яисә документ һәм (яисә) мәгълүмат булмаганда баш тарту турында хәбәрнамә ала;

Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булганда, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын әзерли.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проекты, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп (әгәр дә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуның нигезләре мондый документларга карата билгеләнгән таләпләрне бозу белән бәйле булса, документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрдә дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы белешмәләр булган, билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән алдан тәкъдим ителмәгән документлар (мәгълүмат, белешмәләр) исеме турында мәгълүмат булырга тиеш) билгеләнгән тәртиптә электрон документ әйләнеше системасы аша килештерүгә җибәрелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проектын килештерү Регламентның 3.6.3 пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар ведомствоара гарызнамәләр буенча мәгълүматлар алган көнне башкарыла.

Административ процедураларның үтәлеш нәтиҗәләре булып тора: муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар (мәгълүматлар), муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты.

3.4.5. Регламентның 3.4.2, 3.4.4 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын, шул исәптән гаризаны

Регламентның 2.13 пункты нигезендә теркәгән мизгелдән файдаланып, автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

3.4.6. Регламентның 3.4 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны үтәүнең максималь срогы биш эш көне тәшкил итә.

3.5. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү

3.5.1. Административ процедураны үтәүне башлап җибәрүгә нигез булып ведомствоара гарызнамәләр җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи заттан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның (мәгълүматларның) килеп ирешүе тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы урындагы кеше – Орган җитәкчесенең урынбасары (алга таба – муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы урындагы кеше).

3.5.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы урындагы кеше:

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның формалаштырылган комплектын карый;

административ регламентның 2.8.2 пунктында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту нигезләре ачыкланганда, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын әзерли;

муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен административ регламентның 2.8.2 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны карау йомгаклары буенча элегрәк хосусыйлаштырылган торак урынны муниципаль милеккә кабул итү турындагы карар проектын әзерли;

муниципаль хезмәт күрсәтүнең әзерләнгән проектын билгеләнгән тәртиптә электрон документлар әйләнеше системасы ярдәмендә килештерүгә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән административ процедуралар бер эш көне дәвамында башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре: муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты, элегрәк хосусыйлаштырылган торак урынны муниципаль милеккә кабул итү турында карар проекты.

3.5.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе (алга таба - документлар проектлары) проектын килештерү һәм имза салу муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе, Орган җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән административ процедуралар бер эш көне дәвамында башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып тора: муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар, расланган карар.

3.5.4. Регламентның 3.5.2, 3.5.3 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен

билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

Административ регламентның 3.5 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны үтәүнең максималь срогы ике эш көне тәшкил итә.

3.6. Мөлкәтне муниципаль милеккә түләүсез тапшыру шартнамәсен төзү

3.6.1. Элек хосусыйлаштырылган торак урынны муниципаль милеккә кабул итү турындагы карарны раслау административ процедураны башкара башлауның нигезе булып тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат - Орган җитәкчесе урынбасары (алга таба - муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы урындагы кеше).

3.6.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы урындагы кеше мөлкәтне муниципаль милеккә түләүсез тапшыру шартнамәсе проектын (алга таба - шартнамә) әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнгән административ процедуралар мөрәҗәгать итүчегә карар бирелгән вакыттан алып бер эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: килештерүгә юнәлтелгән шартнамә.

3.6.3.Шартнамәне килештерү һәм имзалау муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе, Орган җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Искәртүләре булган карарларның әзерләнгән проектлары муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы затка кире кайтарыла.

Искәртүләрне бетергәннән соң, документлар проектлары кабат килештерү һәм кул кую өчен тапшырыла.

Орган җитәкчесе документлар проектларын имзалаганда, Регламентның административ процедураларны үтәү срокларын, аларның эзлеклелеген һәм тулылыгын, электрон документ әйләнеше системасында Органның вәкаләтле вазыйфаи затларының килешүләрен үтәүне тикшерә.

Административ процедураларны үтәү срокларын, аларның эзлеклелеген һәм тулылыгын ачыклау өлешендә тәртип бозулар ачыкланган очракта, Орган җитәкчесе регламентның 4.3 пункты нигезендә хокук бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту инициативасы белән чыга.

Административ процедуралар бер эш көне дәвамында башкарыла.

Административ процедураларның үтәлеше нәтиҗәләре булып тора: муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар, имзаланган шартнамә.

3.6.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат гаризада күрсәтелгән ысул белән шартнамәне имзалау кирәклеге, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе һәм Органда яисә КФҮ тә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу мөмкинлеге турында мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) хәбәр итә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән административ процедуралар Орган җитәкчесе шартнамәгә кул куйган көнне башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре: мөрәҗәгать итүчегә юлланган хәбәрнамә.

3.6.5. Регламентның 3.6.2, 3.6.3 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

Административ регламентның 3.6 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны үтәүнең максималь срогы ике эш көне тәшкил итә.

3.7. Мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү (җибәрү)

3.7.1. Административ процедураны башкару өчен нигез булып административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне раслаучы документ алу тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы урындагы кеше булып Органның әйдәүче белгече (алга таба - документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы урындагы кеше) тора.

3.7.2. Документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы урындагы кеше:
дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен аталган автоматлаштырылган мәгълүмат системасы документациясен алып бару ярдәмче системасына муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турындагы мәгълүматларны теркәүне һәм кертүне тәэмин итә;

мөрәҗәгать итүчегә кул куйдырып шартнамәне бирә.

Мөрәҗәгать итүче өч нөсхәдә шартнамәгә кул куя һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы урындагы кешегә тапшыра.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат, Имзаланган шартнамәләрне алып, мөрәҗәгать итүчегә имза салу өчен шартнамәнең өч нөсхәсен бирә. Шартнамәләрне имзалаганнан соң, мөрәҗәгать итүчегә шартнамәнең бер нөсхәсен бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән административ процедуралар мөрәҗәгать итүче килгән көнне башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән шартнамә.

3.7.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү) тәртибе:

3.7.3.1. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт нәтиҗәсен сорап КФҮ кә мөрәҗәгать иткәндә, КФҮ хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә электрон документның кәгазь йөрткечтәге нөсхәсе рәвешендә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирә. Мөрәҗәгать итүче таләбе буенча аңа электрон документның кәгазь йөрткечтәге нөсхәсе белән бергә аны салдырыла торган йөрткечкә яздыру юлы белән электрон документның нөсхәсе бирелә яки мөрәҗәгать итүче адресына электрон почта аша электрон документның нөсхәсе җибәрелә. Аның нигезендә электрон документның кәгазь йөрткечтәге нөсхәсе төзелгән мәгълүматны салдырыла

торган йөрткечкә язганда яки электрон документ нөсхәсен электрон почта аша җибәргәндә мондый нөсхәнең электрон документның кәгазь йөрткечтәге нөсхәсенә тәңгәллеге көчәйтелгән квалификацияле электрон култамга кулланып вәкаләтле хезмәткәр тарафыннан таныклана.

Әлеге пункт белән билгеләнгән административ процедуралар мөрәҗәгать итүченең КФҮ регламентында билгеләнгән срокларда килү көнендә чиратлылык тәртибендә башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора: КФҮнең АМС да муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү фактын теркәү, мөрәҗәгать итүчегә бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе.

3.7.3.2. . Мөрәҗәгать итүче Республика порталы аша муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен сорап мөрәҗәгать иткәндә, мөрәҗәгать итүчегә шәхси кабинетка автомат рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган, Органның вәкаләтле урындагы кешесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон култамгасы белән имзаланган документның электрон үрнәге җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслаучы документка Органның вәкаләтле урындагы кешесе (Орган) тарафыннан кул куелган көнне башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: Республика порталыннан файдаланып мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүне раслый торган документ юллау (бирү) (шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту).

3.7.3.3. . Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт нәтиҗәсен сорап Органга мөрәҗәгать иткәндә, документларны бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирә. Мөрәҗәгать итүче таләбе буенча аңа электрон документның кәгазь йөрткечтәге нөсхәсе белән бергә аны салдырыла торган йөрткечкә яздыру юлы белән электрон документның нөсхәсе бирелә яки мөрәҗәгать итүче адресына электрон почта аша электрон документның нөсхәсе җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар, мөрәҗәгать итүче килгән көнне, Органның Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре нигезендә, чират тәртибендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү фактын теркәү.

### 3.8. Техник хаталарны төзәтү

3.8.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып торган документта техник хата барлыгы беленгән очракта гариза бирүче (мөрәҗәгать итүче) Органга җибәрә:

техник хатаны төзәтү турында гариза (әлеге административ регламентка 5 нче кушымта);

муниципаль хезмәт нәтиҗәсе буларак гариза бирүчегә бирелгән техник хаталы документ;

техник хата булуны дәлилләүче юридик көчкә ия булган документлар.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән мәгълүматларда техник хатаны төзәтү турында гаризаны мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) почта аркылы (шул исәптән электрон почтаны кулланып) яки Республика порталы яисә КФҮ аша бирә.

3.8.2. Документлар кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, кушымта итеп теркәлгән документлар белән гаризаны терки һәм аларны документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гаризаны теркәү датасыннан бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка карауга юнәлтелгән кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.8.3. Документлар эшкәртүгә җаваплы вазыйфаи зат документларны карый һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм төзәтелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) техник хата булган документның төп нөсхәсен алып калып шәхсән кул куйдырып бирә яки гариза бирүче адресына почта аша (электрон почта ярдәмендә) Органга техник хата булган документның төп нөсхәсен тапшырганда документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хатаны ачыклаганнан яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң ике эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүгә контроль тәртибе һәм формалары

### 4.1. Җаваплы урындагы кешеләр тарафыннан регламент нигезләмәләрен һәм муниципаль хезмәт күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларны үтәүгә һәм башкаруга, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүгә агымдагы контрольне гамәлгә ашыру тәртибе

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгына һәм сыйфатына контроль мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуын ачыклау һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлүенә тикшерүләр уздыруны, җирле үзидарә органнары урындагы кешеләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешенә контроль формалары булып торалар:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү.

2) делопроизводствоны алып баруны билгеләнгән тәртиптә уздырылучы тикшерүләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларын үтәүгә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Агымдагы контроль максатларында электрон мәгълүматлар базасында булган белешмәләр, хезмәт урыны корреспонденциясе, административ процедураларны үтәүче урындагы кешеләрнең телдән һәм язма мәгълүматы, тиешле документларны исәпкә алу журналлары һәм башка мәгълүматлар файдаланыла.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм җирле үзидарә органы җитәкчесенә карарлар кабул иткәндә гамәлләрнең башкарылуын тикшереп тору өчен муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр бирелә.

Административ процедураларның срокларын, эзлеклелеген һәм эчтәлеген бозу очраклары һәм сәбәпләре турында урындагы кешеләр кичекмәстән муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенә хәбәр итәләр, шулай ук бозуларны бетерү буенча ашыгыч чаралар күрәләр.

Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контроль муниципаль хезмәт күрсәтү эшен оештыруга җаваплы җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары, муниципаль хезмәт күрсәтү эшен оештыручы бүлек башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы урындагы кешеләр исемлеге җирле үзидарә органының структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

### 4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфаты буенча планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне гамәлгә ашыру тәртибе һәм периодиклыгы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.2.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору түбәндәгеләр рәвешендә гамәлгә ашырыла:

1) тикшерүләр уздыру;

2) мөрәҗәгать итүчеләрнең органның, шулай ук аларның урындагы кешеләрнең, муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләрен карау.

4.2.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору максатларында планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрелә. Планлы тикшерүләрне уздыру тәртибе һәм ешлыгы (периодиклыгы) Органның эш планы белән билгеләнә. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле барлык мәсьәләләр (комплекслы тикшерүләр) яисә мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча каралырга мөмкин. Тикшерү шулай ук мөрәҗәгать итүченең конкрет шикаяте буенча үткәрелергә мөмкин.

4.2.3. Планнан тыш тикшерүләр алдан ачыкланган хокук бозуларны бетерү белән бәйле рәвештә үткәрелә, шулай ук Орган гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүчеләрнең шикаятьләре алынган очракта, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең.

4.2.4. Тикшерү нәтиҗәләре тикшерү акты рәвешендә рәсмиләштерелә, анда ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәр күрсәтелә.

## 4.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында үзләре тарафыннан кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен муниципаль хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затларының (урындагы кешеләренең) җаваплылыгы

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылган очракта гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

Җирле үзидарә органы җитәкчесе гариза-мөрәҗәгатьләрне вакытында тикшермәгән өчен җаваплы.

Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (җитәкче урынбасары) Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яисә) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә торган (гамәлгә ашырыла торган) карар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр законнарда билгеләнгән тәртиптә җаваплы булалар.

## 4.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне тикшереп тору тәртибенә һәм рәвешләренә таләпләрне сыйфатлаучы нигезләмәләр, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан да.

Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне тикшереп тору (контроль) муниципаль хезмәт күрсәткәндә җирле үзидарә органы эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның урындагы кешеләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәт алучылар муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган хезмәткәренең, җитәкчесенең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр тәртиптә шикаять бирү хокукына ия.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 маддәсендә күрсәтелгән гарызнамәне, муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гарызнамәне теркәү срокларын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, аның хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда тапшыру яисә гамәлгә ашыру каралмаган документларны яки мәгълүматны яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гамәлләр кылуны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда баш тарту нигезләре күздә тотылмаган булуга карамастан муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, аның хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин;

6) муниципаль хезмәт күрсәтүдә гариза бирүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, муниципаль район норматив хокукый актларында күздә тотылмаган түләүне таләп итү;

7) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә

каралган оешмалар яисә аларның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хата һәм ялгышларны төзәтүне кире кагуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, аның хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирүнең срогын яисә тәртибен бозу;

9) федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары, муниципаль районның норматив хокукый актларында муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатуга нигезләр күздә тотылмаган булуга карамастан, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату (туктатып тору);

Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, аның хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин;

10) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны баштагы кабул итүдәге кире кагуда юклыгы һәм (яки) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүматны муниципаль хезмәт күрсәтүдә, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ Федераль законның 7 маддәсе 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан гайре, мөрәҗәгать итүчедән таләп итү.

Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, аның хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин.

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазь йөрткечтә, электрон рәвештә муниципаль хезмәтне күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә яки күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы тиешле дәүләт хакимияте органына (алга таба – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы), шулай ук 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларга тапшырыла. Муниципаль хезмәтне күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр югарырак органга (ул булган очракта) бирелә яки ул

булмаган очракта турыдан-туры муниципаль хезмәтне күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала. Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр шушы күпфункцияле үзәк җитәкчесенә бирелә. Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәкне оештыручыга яисә Татарстан Республикасының норматив хокукый акты белән вәкаләтле вазыйфаи затка тапшырыла. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр әлеге оешмалар җитәкчеләренә бирелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аркылы, күпфункцияле үзәк аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайтыннан, Бердәм порталдан яисә республика порталыннан, судка кадәр шикаять бирү мәгълүмат системасыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәкнең, Бердәм порталның яисә Республика порталының рәсми сайтыннан, судка шикаять бирүнең мәгълүмат системасы аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1 өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, әлеге оешмаларның, Бердәм порталның яисә Республика порталының рәсми сайтларыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесе һәм (яисә) хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның җитәкчеләре һәм (яисә) хезмәткәрләренең исемнәрен (аталышларын);

2) мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), гариза бирүченең – физик затның яшәү урыны турында мәгълүматлар, гариза бирүченең – юридик затның урнашу урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (булган очракта) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы (булганда);

3) муниципаль хезмәтне күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле

үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүче алар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешми торган дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аның дәлилләрен раслаучы документлар (булганда) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.4. Килеп ирешкән шикаять кергән көннән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш.

5.5 Муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларга яисә югарырак органга (ул булганда) кергән шикаять теркәлгән көннән алып унбиш эш көне эчендә каралырга тиеш, ә муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларга карата шикаять белдерелгән очракта мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдә яки җибәрелгән хата һәм ялгышларны төзәтүдә яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылган очракта – аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.6.Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның кайсы да булса берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә түләтү Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартырга.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.7. Шикаятьнең канәгатьләндерелергә тиешле дип танылу очрагында мөрәҗәгать итүчегә шикаятьне карау нәтиҗәләре турындагы җавапта муниципаль хезмәт күрсәткәндә беленгән бозуларны кичекмәстән бетерү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмалар тарафыннан тормышка ашырылучы гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук күрсәтелгән уңайсызлыклар өчен кичерү сорала һәм муниципаль хезмәт

күрсәтүне алу максатларында гариза бирүчегә кылу зарур булган алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаятьнең канәгатьләндерелергә тиешле түгел дип табылу очрагында мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре хакында дәлилле аңлатмалар бирелә, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат китерелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре табылу очрагында шикаятьләрне карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрәләр.

Элегрәк хосусыйлаштырылган
торак урыннарны муниципаль
милеккә кабул итү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
кушымта №1

Рәвеш

(Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган бланкы)

Кемгә: __________________________
_________________ _________________
Контакт мәгълүматлары:
______________ _________________
Вәкил: _________________
_________________ _________________
Вәкилнең контакт мәгълүматлары:
___________________________________

________________________________________________________________буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында
КАРАР

20 ___ елның ____ _________ № _____

Сезнең 20 ___ елның ____ _____________ ____номерлы гаризагызны һәм аңа теркәлгән документларны карау нәтиҗәләре буенча _______________________

вәкаләтле орган тарафыннан түбәндәге нигезләр буенча элегрәк хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

5. ____________________________________________
6. ____________________________________________

Өстәмә мәгълүмат: ______________________________

Күрсәтелгән (хокук) бозулар бетерелгәннән соң хезмәт күрсәтү турында гариза белән сез вәкаләтле органга кабаттан мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Әлеге кире кагу судка кадәр шикаятьне вәкаләтле органга җибәрү юлы белән, шулай ук суд тәртибендә шикаять ителергә мөмкин.

| Электрон имза турында мәгълүматлар |
|---|

Вазыйфаи зат (урындагы кеше) (ФИАи) ______________________

(органның вәкаләтле вазыйфаи заты имзасы)

Элегрәк хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
кушымта №2

Рәвеш

(Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган бланкы)

Кемгә: ___________________________
_________________ _________________
Контакт мәгълүматлары:
______________ _________________
Вәкил: ___________________
_________________ _________________
Вәкилнең контакт мәгълүматлары:
__________________________________

_______________________________________________________________буенча
муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында
КАРАР

20 ___ елның ____ _________ № _____

Сезнең 20 ___ елның ____ _____________ ____номерлы гаризагызны һәм аңа теркәлгән документларны карау нәтиҗәләре буенча ________________________ вәкаләтле орган тарафыннан түбәндәге нигезләр буенча элегрәк хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

1. _________________________________________________________________
2. _________________________________________________________________

Кире кагу сәбәпләренә аңлатма: ______________________________________
Өстәмә мәгълүмат: ________________________________________

Күрсәтелгән (хокук) бозулар бетерелгәннән соң хезмәт күрсәтү турында гариза белән сез вәкаләтле органга кабаттан мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Әлеге кире кагу судка кадәр шикаятьне вәкаләтле органга җибәрү юлы белән, шулай ук суд тәртибендә шикаять ителергә мөмкин.

| Электрон имза турында мәгълүматлар |
|---|

Вазыйфаи зат (урындагы кеше) (ФИАи) __________________________________

(органның вәкаләтле вазыйфаи заты имзасы)

Элегрәк хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
кушымта №3

Рәвеш

______________________________________________
(муниципаль берәмлекнең
______________________________________________
җирле үзидарә органы исеме (аталышы))

______________________________________________
______________(алга таба — мөрәҗәгать итүче)

(физик затлар өчен - фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт мәгълүматлары, яшәү урыны буенча теркәлү, телефон)

## Элегрәк хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү турында гариза.

Элегрәк хосусыйлаштырылган мәйданы ______ кв.м булган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итүегезне сорыйм.

Торак урынның адресы: _______________________муниципаль районы (шәһәр округы), торак пункт_____________________урам_________________ йорт_________

Гаризага түбәндәге сканерланган документлар теркәлә:

1) Гаиләнең һәр әгъзасының шәхесен таныклаучы документлар;

2) Вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил эш йөртсә);

3) Торак урынга милек хокукын раслаучы документ (әгәр милек Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында теркәлмәгән булса);

4) Яшәү урыныннан белешмә;

5) Торак урынның техник паспортының күчермәсе;

6) __________________________муниципаль район Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлегенең торак урынны муниципаль милеккә тапшыру турында рөхсәтнамәсе (хосусыйлаштыруда балигъ булмаган балалар катнашса)

7) Йорт кенәгәсеннән өземтә (документ коммерция оешмасы тарафыннан бирелгән очракта).

Гарызнамә булганда сканерланган документларның төп нөсхәләрен бирүне үз өстемә алам.

________________ ____________ ____________________________________________
(дата) (имза) (ФИАи)

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирүегезне үтенәм:

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталының шәхси кабинетына;

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә;

☐ ***Органда.***

_______________ __________________ ( ________________)
(дата) (имза) (Ф.И.А.и.)

Элегрәк хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
кушымта №4

техник хатаны төзәтү турында
ГАРИЗА.

__________________________________________муниципаль хезмәт
(күрсәтелгән хезмәтнең исеме)
күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

Язылган:________________________________________________________
_____________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар:______________________________________________________
_________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып торган документка тиешле үзгәрешләрне кертүне үтенәм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.
3.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кире кагу хакында карар кабул иткән очракта андый карарны җибәрүне үтенәм:

электрон документны E-mail______________адресына җибәрү ярдәмендә;
почта аша кәгазь йөрткечтә расланган күчермә рәвешендә түбәндәге адрес буенча: _________________________________________________________ ___

Әлеге гариза белән раслыйм: гаризадагы минем шәхескә һәм минем тарафтан тәкъдим ителүче затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры киләләр, гаризаны бирү моментына бу документлар чын һәм дөрес мәгълүматларны үз эчләренә алалар.

______________ ________________ ( _______________)
(дата) (имза) (Ф.И.А.и.)